ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ
Ш. МӘРҖАНИ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

*Э.К. Сәлахова*

# ТӘТЕШ ӨЯЗЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ КӨНКҮРЕШЕ ҺӘМ РУХИ ТОРМЫШЫ (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы)

МОНОГРАФИЯ

Казан – 2023

УДК 297(17)
ББК 63.3(2)51
С 94

*«Татарстан республикасының торак пунктлары тарихы» сериясеннән*

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни редакторлар:**

*А.И. Ногманов*, тарих фәннәре кандидаты,
*Х.М. Абдуллин*, тарих фәннәре кандидаты

**Рецензентлар:**

*Ф.Н. Шәкүров*, тарих фәннәре кандидаты,
*Л.Р. Мортазина*, педагогика фәннәре кандидаты

***Сәлахова Э.К.***

С 94 **Тәтеш өязе татарларының көнкүреше һәм рухи тормышы (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы):** монография. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2023. – 296 б.; ил.

ISBN 978-5-94981-396-6

Монография XVIII йөз ахыры – XX йөз башында Казан губернасы Тәтеш өязендә гомер иткән татарларның көнкүрешенә һәм рухи тормышына багышланган. Киңкырлы чыганаклар базасында өязнең иҗтимагый-сәяси, икътисадый, рухи тормышы яктыртыла. Шулай ук төбәкнең тарихи истәлекләренә, күренекле нәсел-ләренә, үзенчәлекле гореф-гадәтләренә, аш-су традицияләренә игътибар ителә. Монография галимнәргә, төбәк, нәсел тарихлары белән кызыксынучыларга адреслана.

ISBN 978-5-94981-396-6

УДК 297(17)
ББК 63.3(2)51

© Сәлахова Э.К., 2023
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2023

# Э Ч Т Ә Л Е К

Кереш ........................................ 5

**I бүлек.**
**Тәтеш төбәгендәге тарихи һәйкәлләр**

§ 1. Археологик истәлекләр ........................................ 11
§ 2. Нумизматик истәлекләр ........................................ 23
§ 3. Борынгы зиратлар һәм кабер ташлары ........................................ 29

**II бүлек.**
**Тәтеш төбәге авылларының социаль-икътисадый үсеше**

§ 1. Татар авылларының икътисадый халәте
һәм социаль каршылыклар ........................................ 40
§ 2. Тәтеш ягы халкының кәсепләре, һөнәрләре ........................................ 50
§ 3. Сәүдә ........................................ 57
§ 4. Ат үрчетү һәм Тау ягында ат караклыгы ........................................ 65
§ 5. Нефтьле төбәк ........................................ 69
§ 6. Беренче Бөтендөнья сугышы чорында
Тәтеш төбәге халкы: тыл һәм фронт ........................................ 73

**III бүлек.**
**Тәтеш төбәгенең рухи тормышы һәм традицион мәдәнияты**

§ 1. Төбәкнең күренекле дин әһелләре ........................................ 82
§ 2. Тау ягының язма мирасы ........................................ 98
§ 3. Тәтеш төбәгендә халык бәйрәмнәре,
аш-су гадәтләре ........................................ 104

## IV бүлек.
## XIX–XX йөз башында Тәтеш өязендә мәгариф

§ 1. XIX–XX йөз башында өяз авылларында
мәгариф торышы ........ 114
§ 2. Тәтеш шәһәрендә татар мәгарифенең халәте ........ 127
§ 3. Мулла белән укытучы: заман көрәше ........ 133
§ 4. Л.Н. Толстой белән аралашкан Тәтеш мөгаллиме ........ 138

## V бүлек.
## XVIII йөз ахыры – XX йөз башында
## Тәтеш өязендә иҗтимагый хәрәкәтләр

§ 1. Чукындыру һәм иманга кайту хәрәкәте ........ 142
§ 2. Чуашларның исламга килүе ........ 156
§ 3. Халык санын алу вакыйгасы белән бәйле хәрәкәтләр ........ 159
§ 4. Күчеш хәрәкәте һәм Тәтеш ягы халкының башка
төбәкләр белән тарихи бәйләнеше ........ 166

## VI бүлек.
## Тау ягының атаклы нәселләре һәм шәхесләре

§ 1. Галишаһ морза нәселе ........ 176
§ 2. Мортазиннар – имамнар һәм галимнәр биргән нәсел ........ 183
§ 3. Тәтеш төбәгенең мәшһүр хатын-кызлары ........ 190

Йомгак ........ 197
Чыганаклар һәм әдәбият ........ 200
Кыскартулар ........ 208
Кушымта ........ 209

# К Е Р Е Ш

Халыкларның зур тарихы кечкенә тарихлар җыелмасыннан тора, тарихтагы глобаль проблемаларны өйрәнгәндә дә аерым җирлекләрдә барган вакыйгаларны ачыклау, аларны анализлау мәсьәләгә киңрәк караш булдырырга ярдәм итә. Кызганычка каршы, аерым төбәк тарихлары профессиональ тарихчыларның күз уңыннан читтә калып килде, әмма төбәкчеләр авыллар тарихына багышланган хезмәтләр иҗат иттеләр. Шулай да, төбәкләрдә барган тарихи процессларга, иҗтимагый халәткә комплексы карап, аның Россия тарихындагы ролен күрсәтү актуаль проблема булуын дәвам итә. Тәкъдим ителәсе хезмәттә Тәтеш төбәгенең социаль-икътисадый халәтен һәм рухи үсешен өйрәнү, төбәкнең үзенчәлеген күрсәтү, аның Россия тарихында тоткан урынын ассызыклау максат ителде. XIX йөздә Казан губернасы 12 өяздән торган. Алар арасында Тәтеш өязенең үз үзенчәлеге булган, ул әлеге җирлектә барган вакыйгалар, бу җир биргән шәхесләре белән данлыклы.

Тәтеш өязе Казан губернасының административ-территориаль берәмлеге, ул 1781 елда Казан наместниклыгы составында оеша һәм кантон булып үзгәртелгәнче, 1920 елга кадәр, шушы исем белән йөри. XIX йөзнең 60 нчы елларында өязнең зурлыгы 340000 дисәтинә булган. Хезмәтнең хронологик рамкалары да шушы факт белән бәйле, ягъни бу төбәк халкының Тәтеш өязе административ берәмлеге чорындагы яшәгәндәге хәлләре һәм халәтләре өйрәнеләчәк.

Өязнең баш шәһәре буларак Тәтеш шәһәре билгеләнә. XX гасыр башында Тәтеш өязе составына 18 волость кергән. Алар – Әлки, Богородский, Олы Кариле, Олы Таяба, Олы Фролово, Олы Шәмәк, Олы Яңасала, Ильинск-Шонгат, Кызыл Алан (Чинчурин), Никифоровка, Яңа Шимкус, Пролей-Каша, Урта Балтай, Иске Барыш, Сөйки, Черки-Килдураз, Шәмбалыкчы, Яшевская волостьлары. Кайбер волостьлар бары тик татар-мөселман авылларыннан гына торганнар. Мисал өчен, Черки-Килдураз, Олы Кариле волостьлары, ә кайберләре чуаш авыллары белән күршедә гомер иткәннәр. Шулай ук мисал өчен, волость үзәге татар авылы Әлкидә булса да, бу волостька шактый гына чуаш авыллары да караган. Тәтеш өязенең төп халкын татарлар һәм чуашлар, бик азын гына мордвалар (мисал өчен, Мордва Каратае авылы) тәшкил иткән. Тәтеш өязендә шулай ук руслар да гомер кичергән. Волость үзәге булган Олы Фролово авылында тирә-яктагы православие динен тотучыларны җыеп тора торган зур чиркәү эшләп килгән. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча өяздә 185865 кеше гомер кичергән, шуларның зур күпчелеген – 49,1 %ын татарлар, 31,6 % – руслар, 16,6 % – чуашлар, 2,7 % – мордвалар тәшкил

иткән. Тәтеш шәһәрендә 4754 кеше яшәгән. Социаль составы ягыннан карағанда, әлбәттә, күпчелек өлеш крестьяннарга туры килгән, аларның саны 180000, 514 мещан, 367 рухани, 106 дворян, 48 почетлы гражданин, 3 сәүдәгәр, 18 башка сословие кешеләре, сословиесен күрсәтмәгән 3 кеше, хәтта 1 чит ил кешесе дә булган[1]. Өязнең 264 авылында 26582 хуҗалык исәпләнгән. Тәтеш өязендә бары тик татарлар, чуашлар, руслар гына яшәгән авыллар белән беррәттән катнаш авыллар да шактый булган. Мисал өчен, руслар белән чуашлар, татарлар белән чуашлар, руслар белән татарлар, мордвалар белән татарлар яшәгән авыллар да аз булмаган[2].

Өяз халкының төп кәсебе җир эшкәрү, игенчелек була, һөнәрчелек буенча Тәтеш төбәге Казан артыннан нык калыша, һөнәрчелек бар, әмма ул бу якта әлләни үсеш алмый. 1875 елгы мәгълүмат буенча, Тәтеш өязе территориясендә 3 завод – бер сыра заводы, 2 тукыма җитештерү заводы эшли. XX гасыр башында, заман таләпләренә җавап буларак, заводлар саны арта, монда 34 кечерәк заводларның булуы билгеле.

Өязнең баш шәһәре Тәтеш Идел елгасының сул як ярында урнашкан. Шәһәрнең тарихын XVI йөзнең 70 нче елларыннан башлыйлар, XIX йөзнең урталарында шәһәрнең 81 дисәтинә 1468 квадрат сажин сөрү җире, 42 дисәтинә печәнлекләре, 1350 дисәтинә 1290 сажин урманы булган. Шәһәрдә 1831 христиан, бары тик 200 мөселман кешесе гомер кичергән. Бу вакытта шәһәр халкының зур күпчелеген христианнар тәшкил иткәнгә, шәһәрдә бер чиркәү эшләгән. Тәтештә, нигездә, йортлар агачтан төзелгән, алар – 285, бары тик 8 йорт кына таштан салынган. Шәһәрдә бер җәмәгать йорты, шулай ук 3 хастаханә, казначылык, өяз училищесы, төрмә булган[3].

Хәзерге вакытта Тәтеш өязе җирләре Татарстан республикасының Тәтеш, Апас, Кама Тамагы һәм Буа районының бер өлешенә карый. Шунлыктан, хезмәттә шушы төбәкләрдә урнашкан торак пунктлары хакында, аның халкы, әлеге төбәктә барган иҗтимагый хәрәкәтләр турында сүз барачак.

Инкыйлабка кадәрге чорда аерым өязләргә, андагы демографик, социаль халәткә шактый игътибар ителгән. Тәтеш турындагы материалларны, статистик мәгълүматларны төрле белешмәлек формасындагы хезмәтләрдән ачыклау мөмкинлеге бар[4]. Шулай ук XIX–XX йөз башы галимнәре, аерым

[1] Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. / Под ред. Н. А. Тройницкого. – Казанская губерния. – СПб.: Изд-е Центр. стат. комитета МВД, 1904. – 284 с.

[2] Список селений Казанской губернии. Вып. 7. Тетюшский уезд. – Казань: Литотипография И. Н. Харитонова, 1910. – 23 с.

[3] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 126–127.

[4] Список селений Казанской губернии. Вып. 7. Тетюшский уезд. – Казань: Литотипография И. Н. Харитонова, 1910. – 23 с.; Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального

алганда, Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзаларының фәнни экспедиция нәтиҗәләре, Тәтеш төбәгенең борынгы тарихын яктырта[5]. Тау ягының бай рухи мирасы Ш. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә дә урын алган, чыгышлары белән шушы төбәктән булган атаклы шәхесләре Р. Фәхреддиннең «Асар» исемендәге берничә томлы хезмәтенә кертелгәннәр. К. Насыйри[6] һәм Г. Әхмәрев[7] хезмәтләре дә шушы төбәк тарихына караган күп кенә проблемаларны үз эченә сыйдырган. Икесе дә тумышлары белән хәзерге Яшел Үзән районыннан булып, Тау ягы хакында күп язган атаклы галимнәр. Әлеге авторлар үз хезмәтләрендә тулы бер төбәк – Тау ягын бербөтен итеп карадылар. Соңгы елларда җирлек тарихына, нигездә, төбәкчеләр игътибар итәләр. Һәр якның үз кызыксынучысы бар. Апас районы авыллар тарихын танылган журналист, төбәкче Азат Сункишев өйрәнеп, күпсанлы китаплар тәкъдим итте[8]. Шәмбалыкчы авылында укытучы булып эшләгән, якташы – опера җырчысы Фәхри Насретдиновка музей оештырган Бөек Ватан сугышы ветераны Зиннәт Хәйруллинның хезмәтен аерым билгеләү кирәк, ул әле олы яшьтә булса да, тарих белән кызыксынуын дәвам итә[9]. Китапка авыл тарихына караган кызыклы мәгълүматлар, җирле халык нәсел шәҗәрәләре кертелгән. Шулай ук Апас төбәгенең мөһим тарихи проблемалары хакында журналист

---

штаба, 1850. – С. 126–127; Конская перепись 1882 года. – СПб.: Главное Управление Государственного коневодства, 1884. – 183 б.; Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в. /под ред. Д. А. Корсакова. – Казань: Типо-лит Императорского ун-та, 1908. – 367 с.; Список населенных мест по сведениям 1859 г. /обработан А. Артемьевым. – СПб.: Центральный статистический комитет Мин. Внутр. Дел, 1866. – С. 96–108.

[5] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 498; Приволжские города и селения в Казанской губернии с картой р. Волги и рисунками. Репринтное издание. Казань: ТаРИХ, 2008. – 202 с.; Ахмаров Г. Отчет о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // ИОАИЭ, 1910. – Т.XXVI. – Вып.4. – С. 398–408.

[6] Насыйри К. Избранные произведения. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1977. – 254 с.

[7] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – 384 б.

[8] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, – 2013. – 232 с.; Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, 2013. – 232 с.; Сункишев А. Истәлекле биналар, истәлекле урыннар. Беренче кисәк. – Казан: Школа, 2009. – 171 б.

[9] Хәйруллин З., Хәйруллин И. Тукмаш – олы бабабыз. – Казан: «Школа» редакциянәшрият үзәге, 2020. – 192 б.

Х. Бәдретдинев тә хезмәтләр иҗат итте[10]. Т. Вафинның үз бабасы язмышы белән кызыксынудан башлаган эзләнү эше шул төбәктәге чукындыру хәлләре, иман өчен көрәшне яктырткан бик сыйфатлы хезмәт дәрәҗәсенә үсеп китап буларак дөньяга чыкты[11]. Буа районының элек Тәтеш өязе кысаларында булган җирләр тарихы буенча да шактый хезмәтләр бар, шулардан арасыннан гомер буе укытучы булып хезмәт куйган Н. Бикмуллин китапларын аерым билгеләү мөһим[12]. Шушы ук рәткә гомерен Зөя өязе авыллары тарихын өйрәнүгә багышлаган К. Галимовны да кертергә кирәк[13], чөнки талантлы төбәкченең хезмәтләре аша Зөя өязе авыллары белән Тәтеш өязе (хәзерге Буа районына карый торган өлеше) авылларының тарихи бәйләнеше аның тарафыннан башлап өйрәнелә, аларның килеп чыгышларында уртак тарих барлыгы күренә. Чынлап та, тарихи документлар буенча, Зөя өязеннән күчкән нәселләрнең Тәтеш, Буа өязе җирләрендә авыллар нигезләве билгеле. Тәтеш районы тарихы буенча төбәкчеләрнең дә, профессиональ тарихчыларның да хезмәтләре шактый. Шулар арасыннан П. А. Чекмарев[14], Е. В. Миронова[15] хезмәтләрен аерым билгеләү кирәк. Алар Тәтеш өязенең баш шәһәре – Тәтешнең үткәне турында тарихи документларга нигезләнгән фәнни хезмәтләр бастырып чыгадылар. Соңгы елларда Тәтеш төбәге тарихына җәмәгатьчелек игътибарын юнәлтү, аны популярлаштыруда «Шонгаты» җәмгыятенең роле аеруча зур. Алар эшчәнлеге нигезендә төрле чаралар уздырыла, ел саен «Әтрәч укулары» галимнәрне дә, тарих белән кызыксынучыларны да бер мәйданга җыя. Шушы чара Тәтеш төбәгенең борынгы тарихын өйрәнүгә этәргеч тә бирде.

Историографик анализ нәтиҗәсе буларак, аерым юнәлешләр, аерым проблемалар каралган булса да, Тәтеш өязенең тарихы, аның тарихи процесстагы үзенчәлекле урыны комплекслы өйрәнелмәгәнлеге ачыкланды. Бу хезмәтнең әлеге өлкәдәге яңалыгы – ул Тәтеш төбәге халкының тормышы аша чорның тарихи процессларын күрсәтү, аның әчтәлеген ачу, үзенчәлекле якларын билгеләү. Хезмәттә Россия тарихында барган вакыйгаларны

---

[10] Бәдретдинов Х. Дөньядагы бердәнбер Сатмыш, яки бүгенгедән авылның үткәндәге онытылган билгесезлегенә таба сәяхәт. – Йошкар-Ола: Мар.полиграф.-изд. комб., 1998. – 188 б.

[11] Вафин Т. Отпавшие или насильственное крещение татар. – Казань, 2011. – 158 б.

[12] Туган туфрак җылысы /Төз.Н.Бикмуллин. – Казан: Матбугат йорты. – 2000. – 326 б.; Бикмуллин Н. Яңа Чәчкап авылы: ата-баба нигезе. – Казан, 2021. – 248 б.

[13] Галимов К. Макулово авылы тарихы. – Казан: Алма-мет., 2006. – 186 б.; Галимов К. Эзле Чәчкаб. – Казан, 2004. – 330 б.

[14] Чекмарев П. А. Есть на Волге городок (из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана). – Казань: Изд-во «По городам и весям», 2004. – 400 с.; Миронова Е. В. Уездный город Тетюши во второй половине XIX – начале XX века. – Казань: Институт истории Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 151 с.

[15] Миронова Е. В. Уездный город Тетюши во второй половине XIX – начале XX века. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 151 с.

гомумиләштереп күрсәтү дә, шул ук вакытта бу төбәкнең үзенчәлеге дә игътибар үзәгенә куелды. Төбәкне дәүләт тарихының аерылгысыз бер өлеше икәнен һәм аның тарихтагы урынын билгелү дә бурыч ителде. Хезмәттә сюжет сызыклары буларак, әлегә кадәр өйрәнелмәгән аспектларга басым ясалды һәм автор тарафыннан тарихны тасвирлау аның халкы тормышы аша алып бару отышлы юл буларак кабул ителде.

Куелган максатка ирешү һәм бурычларны үтәү өчен күпсанлы тарихи чыганаклар комплексы кулланылды. Беренчедән, архив чыганаклары үткән тарихны күзалларга мөмкинлек бирә торган материал саклый. Россия дәүләт тарихи архивы, Татарстан республикасы дәүләт архивы, хәтта Әстерхан өлкәсе дәүләт архивының фондлары Тәтеш төбәге тарихын өйрәнү өчен җирлек булдырды. Әлбәттә, архивларда сакланган эш кәгазьләре, җирле халык белән дәүләт органнарының бер-берсенә булган тәэсире, язышулары, Тәтеш өязенә караган документларны туплаган өяз идарәсе фонды һ.б. шул чорда Тәтеш өязенең территориаль берәмлек буларак яшәү рәвешен, аның җирендә барган сәяси-иҗтимагый вакыйгаларны өйрәнү мөмкинлеген булдыра. Халык мәгарифе белән бәйле вакыйгалар, тикшерү органнары белән язышулар Татарстан республикасы дәүләт архивының иң бай материалларыннан санала. Алар ярдәмендә Тәтеш өязендә эшләгән уку йортлары, атаклы мөгаллимнәр турында комплекслы тикшерү тәкъдим итү мөмкин булды.

Өязнең социаль-экономик үсеше картинасын реконструкцияләүдә инкыйлабка кадәр үк дөнья күргән статистик материаллар җыентыклары ярдәм итә[16]. Бары тик саннардан гына торган чыганаклар булса да, чагыштыру методы нигезендә тулы картина тудыру, үсеш, үзгәрешне күрсәтү мөмкин.

Аерым бер чыганаклар комплексы – ул инкыйлабка кадәрге чор вакытлы матбугаты. Бу чыганаклар архив документларындагы рәсмилеккә тормышчан төсмер бирә торган мәгълүматлар белән бай. Алар аша халыкның көндәлек тормышын да, иҗтимагый хәлләрне дә күзаллау мөмкинлеге арта. «Казан мөхбире», «Йолдыз» газеталары Казан губернасындагы вакыйгаларны яктыртса, «Тәтеш оешмасы» газетасы Тәтеш өязенең җирле матбугаты булып, Тәтеш төбәгендә барган вакыйгалар хакында тәфсилле мәгълүмат чыганагы булып тора.

Беренче Бөтендөнья сугышының җәмгыять тормышына салган тирән трагик эзләре мәгълүм, Тәтеш халкы тарихының бу сәхифәсенә дә аерым игътибар итү мөһим. Бу вакыйгаларны чагылдыруда чыганак буларак архив мате-

---

[16] Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. / Под ред Н. А. Тройницкого. – Казанская губерния. – СПб.: Изд-е Центр. стат. комитета МВД, 1904. – 284 с.; Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в. /под ред. Д. А. Корсакова. – Казань: Типо-лит Императорского ун-та, 1908. – 367 с.; Материалы для исследования промыслов населения Казанской губернии. Казань: Казанская Губернская Земская Управа, 1887. – 303 с.; Конская перепись 1882 года. – СПб.: Главное Управление Государственного коневодства, 1884. – 183 б.

риаллары, Л. Р. Габдрафикова һәм Х. М. Абдуллин авторлыгындагы монографиянең кыйммәте зур[17].

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үткәргән экспедиция материаллары төбәк халкының көндәлек тормышын, аларның үзенчәлеген, халык авыз иҗатын күзаллау өчен кыйммәтле чыганак булуын аерым билгеләп үти кирәк[18].

Югарыдагы чыганаклар комплексы нигезендә Тәтеш төбәге тарихы берничә юнәлештә каралды: төбәкнең бай археологик, эпиграфик, нумизматик истәлекләрен өйрәнү историографиясе, аның социаль-икътисадый үсеше, төбәкнең рухи тормышы, мәгарифе, иҗтимагый вакыйгалар һәм хәрәкәтләр өйрәнелде. Шулай ук төбәкне аның атаклы нәселләре аша өйрәнү җирлекнең үзенчәлеген ачу, аның ил тарихындагы ролен күрсәтүдә отышлы бер алым итеп саныйбыз. Моннан кала, хезмәттә мөһим иҗтимагый күренешләр, әлегә кадәр өйрәнелмәгән өлкәләргә игътибар бирелде, ул – чукындыру һәм киредән исламга кайту хәрәкәте, хезмәттә Туруханга сөрелгән иман сагында торган шәхесләр язмышына аерым урын бирелде. Моннан кала, халыкларның бер урыннан икенче урынга күчүе, шуның нәтиҗәсендә, авыллар белән аерым өлкәләр арасындагы тарихи бәйләнешне ачыклау фәнни тикшерүнең яңалыкларының берсе.

Тикшерү өчен Тәтеш өязе алынган булса да, бу хезмәт кысаларында күп кенә вакыйгаларны, проблемаларны территориаль яктан киңрәк карау таләп ителә, чөнки вакыйгалар аерым өяз кысалары белән генә чикләнә алмый. Шуңа күрә күп кенә мәсьәләләрне яктыртканда зур төбәк – Тау ягы турында да барачак. Хезмәтнең үзәк сызыгы булып «җанлы» тарих тора, зур тарихи вакыйгалар кеше язмышы, аерым кешеләрнең эшчәнлеге аша күрсәтелә. Китап «төбәк, нәсел тарихы» – «милләт тарихы» – «ил тарихы» чылбырына корыла.

Китапта бирелгән кушымта төбәк тарихына караган мөһим документларны үз эченә алды. Алар аша тарих белән кызыксынучылар да, шул ук вакытта галимнәр дә нәсел, төбәк тарихыннан архив материаллары белән таныша һәм куллана ала. Шулай ук автор тарафыннан төзелгән нәсел шәҗәрәләре бирелә.

Әлеге хезмәткә материал туплауда архив һәм күпсанлы язма чыганаклардан кала, шушы төбәкнең тарихы белән кызыксынучыларның зур ярдәмен билгеләп, рәхмәт җиткерәбез. Аерым алганда, Тәтеш районы Олы Әтрәч авылында гомер итүче, данлыклы төбәкче – Мөнир Вәлиевка зур ихтирам белдерәбез.

[17] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 396 с.

[18] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – 421 б.

# I бүлек

# ТӘТЕШ ТӨБӘГЕНДӘГЕ ТАРИХИҺӘЙКӘЛЛӘР

Тау ягы, аерым алганда, Тәтеш өязе җирләре, зур тарихка ия, бу хакта төрле тарихи чыганаклар сөйли: археологик истәлекләр, нумизматик материаллар, эпитафияләр һәм башкалар. Бу истәлекләрне өйрәнү инкыйлабка кадәрге чорда ук башлана.

## § 1. *Археологик истәлекләр*

Казан университеты каршында 1878 елдан башлап эшләп килгән, үзенә шул заманның атаклы галимнәрен, төбәк белән кызыксынучыларны туплаган Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте 1909 елда Казан губернасының археологик һәм этнографик картасын төзи башлый. Бу эш буенча төзелгән комиссиягә 13 кеше керә. Тумышы белән Тау ягыннан, Яшел Үзән районының Татар Наратлысыннан, 1903 елга кадәр Тәтеш шәһәрендә укытучы булып эшләгән, һәм шул вакытларда Тау ягының төбәк тарихын, аның тарихи истәлекләрен җыйган, өйрәнгән галим Г. Әхмәрев шул комиссия составында бердәнбер татар кешесе була. Аңа татарча текстлар белән эшләү бурычы йөкләнә. Археологик истәлекләрне өйрәнү С. М. Шпилевскийның «Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии»[1] хезмәтеннән башлана. Аның тарафыннан 186 тарихи һәйкәл тасвирлана, шуларның 110 сы – шәһәр җирлекләре (городище). Бу хезмәттә Тәтеш өязенең Болгар чорына караган урыннары тасвирланган. Шундый зур, мөһим тикшерүләрнең берсе итеп, Г. Әхмәревнең «1894 һәм 1895 елларда Казан губернасының Тәтеш һәм Спас өязләренә археологик һәм этнографик максат белән ясалган сәяхәте» дип исемләнгән 74 биттән торган тәфсилле отчеты тора[2]. Бу хисапны Н. Ф. Катанов Археология, тарих һәм этнографик җәмгыяте утырышында укый. Зур хезмәтнең төп моментлары җыелыш протоколларында бик кыска рәвештә генә теркәлеп кала, кызганычка каршы, тулы

[1] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – 585 с.

[2] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 330.

тексты сакланмаган. Н. Ф. Катанов Г. Әхмәревнең экспедиция нәтиҗәләренә югары бәя бирә, аның күп кенә тарихи кыйммәтле әйберләр алып кайтуын билгеләп үтә. Ул алып кайткан 52 тарихи истәлек халыкка күрсәтелә һәм музейга тапшырыла. Аның тагын бер мөһим хезмәте – Спас һәм Тәтеш өязе җирлекләрен өйрәнгәннән соң барлыкка килгән «Болгар ханлыгы турындагы татар риваятьләрен тикшерү» дигән хезмәте дә сакланмаган[3]. Г. Әхмәрев экспедицияләрдән алып кайткан тарихи истәлекләр коллекциясе хәзерге вакытта Санкт-Петербургтагы этнография музеенда саклана[4].

Хәзерге вакытта Тәтеш өязе җирлегендәге тарихи һәйкәлләрнең ачыкланганнары, тарихка билгеле булганнары шактый. Тәтеш районы буенча гына да 134 археологик объект исәпләнелә. Вакыт ягыннан караганда палеолит чорыннан Җүчи Олысы чорының Болгар истәлекләренә кадәр сакланган, ә зур күпчелекне урта гасыр археологик объектлары алып тора. Иң беренчеләрдән булып, җәмгыть, галимнәреннән дә алданрак, бу төбәкнең археологик истәлекләрен татар галиме Х. Фәезханов барлый[5]. Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте галимнәре тарафыннан аларның кайберләре карала. 1882 елда җәмгыять тарафыннан түбәндәге шәһәрлекләр күрсәтелә: Чудовка, Большое Нечасово, Малое Нечасово, Удельное Нечасово, Богдашкино, Пролей-Каши, Урюм, Тетюш, Юматово шәһәрлекләре[6].

1882 елда И. А. Износков «Заметки о городках, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии и о встречающих в них находках»[7] дигән тикшерү хезмәтендә Тәтеш өязендәге Чудовка, Яшевка (Малый Кият), Бишево авылларын тасвирлый. Болар – археологик объект буларак игътибарга лаеклы урыннар. Монда балчыктан ясалган савыт кисәкләре табылу – борынгы торак урыны булуы хакында сөйли. Борынгы чордан калган кое бүрәнәләре кисәкләре дә сакланган. Аннан бу урынга Е. Т. Соловьев экспедиция үткәрә[8]. Ул монда Чудовкадан 2 км читтәрәк татар авыл урыны бар,

---

[3] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 332.

[4] Лойко Я. Российский этнографический музей Санкт-Петербурга=Россия этнография музее. Санкт-Петербург // Древняя Казань – Борынгы Казан: Каталог выставки. – СПб.: Славия, 1999. – С. 64–65.

[5] Файзханов Х. Три булгарских надгробных надписи // Известия императорского археологического общества. Т. IV. – СПб., 1863. – С 339, 402.

[6] Износков И. А. Заметки о городках, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии и о встречающихся в них находках // Известия и ученые записки Императорского Казанского университета. – 1882. – 1/2. – С. 125–136.

[7] Износков И. А. Заметки о городах, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии и о встречающихся в них находках // ИОАИЭ при Императорском университете. Т. III. 1880–1882. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 73–84.

[8] Соловьев Е. Т. Одно из древних булгаро-татарских городищ в Тетюшском уезде с. Чудовка (Колунец, Архангельское) Тетюшского уезда // ИОАИЭ при Императорском

җирле халык бу авылның исемен хәтерләми ди, әмма риваятьләрдә дә татар авылы турында сөйләнә, ә авылга бара торган юлны – «Татар юлы» дип атаганнар, дип яза. Борынгы татар зиратыннан калган фрагментлар да билгеле. С. М. Шпилевский үз хезмәтендә 1325 елга караган бер татар кешесе кабере хакында әйтә. Торакның кайсы чорныкы икәнен әйтү авыр, әмма ул, Е.Т. Соловьев фикеренчә, шәһәрлек саклану пункты (передовое укрепление) булырга тиеш: «Есть возможность допустить предположение, что его роль заключалась в службе в качестве наблюдательного военного поста и хорошего стратегического пункта»[9]. Әгъза-хезмәткәр Е. Т. Соловьев Чудовка шәһәрлегенең планын да эшли, ул «этот план может, нам кажется, принести свою долю пользы тому исследователю, который пожелал бы подробно ознакомиться с этою любопытного в археологическом отношении частью Тетюшского уезда»[10], дип яза. Тәтештән алып Өрем (Урюм) авылына кадәр булган өлешне төшергән план җәмгыять документлары җыентыгында сакланмаган, аның язмышы билгесез.

Моннан кала, Тәтеш өязе территориясендәге түбәндәге авыл урыннарындагы шәһәрлек җирлекләре дә И. А. Износков тарафыннан каралган, тасвирланган. Яшевка авылы (чуаш авылы) янында да борынгы торак урыны булуы күренә, монда яшен ташлары күп табылган, халык яшен ташын уып яңгыр суы белән кушып, балаларны дәвалый торган булган. Бишево (Ивановское) авылына Зөя өязенең Ивановское авылыннан XVII гасырда рус крестьяннары күчеп килеп утыра, аңа кадәр бу урында татарлар яшәгән. Авыл исеме дә «биш» сүзеннән алынган, дип аңлатыла. Авыл 5 йорттан торган булырга тиеш. Бу авылда «Татар очы» дигән урынның булуы, риваятьләрдә дә татарлар турында сөйләнүе татар авылы турында уйларга мөмкинлек бирә[11].

Рус авылы Ямбухтино урынында кайчандыр татар шәһәре булуын Тәтеш өязе татарларыннан ишетеп, Е. Т. Соловьев 1884 елны җәмгыять җыелышында бу шәһәрлек турында чыгыш ясый[12]. Яз көне бу урынга барып мәгълүмат җыеп, җәмгыять җыелышында сөйләргә вәгъдә итә, әмма бу җирлек тари-

---

университете. Том III. 1880–1882. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 281–284.

[9] Соловьев Е. Т. Одно из древних булгаро-татарских городищ в Тетюшском уезде с. Чудовка (Колунец, Архангельское) Тетюшского уезда // ИОАИЭ при Императорском университете. Том III. 1880–1882. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 281–284.

[10] Шунда ук. – С. 291–295.

[11] Износков И. А. Заметки о городах, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии и о встречающихся в них находках // ИОАИЭ при Императорском университете. Том III. 1880–1882 г. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 73–84.

[12] Соловьев Е. Т. Археологические сведения о селе Ямбухтине Тетюшского уезда Казанской губернии // ИОАИЭ при Императорском университете. Том III. 1880–1882 г. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 296–297.

хына багышланган аерым хезмәте «Известия»дә юк. Ямбухта авылы татар риваятьләрендә сөйләнгән «Мең өйле Шонгаты» шәһәре булырга тиеш. Г. Әхмәрев бу урыннарны археолог буларак карый. Ул зиратының зурлыгы, мәһабәт кабер ташлары булудан чыгып, җирле халык риваятьләре буенча да зур шәһәр булган булырга тиеш[13], ди. Е. Т. Соловьев биргән мәгълүмат буенча да, шәһәр зур, 1400 йортлы булган диелә[14]. Борынгы зиратлары Олы Әтрәч авылыннан 100 сажин төньяк-көнгыгыш якта урнашкан була. Зират урыны икәне беленгәч, ул кырны сукаламый башлыйлар, зират аша уза торган юлны да читкәрәк күчерәләр. Бу хакта Г. Әхмәрев тә язган[15]. Бу урында бик күпләп балчыктан ясалган савыт-сабалар һәм тәнкәләр табылуы хакында Е. Т. Соловьев яза. Япанчино шәһәрлек урыны булса, шәһәрлектән Олы Әтрәчкә таба барган юлда курганнар булу хакында риваятьләрдә дә әйтелә. Бу шәһәр язмышын Е. Т. Соловьев та татар риваятьләре буенча яза[16]. Руслар шәһәрне алгач, мондагы татарлар буйсынудан баш тартып, шәһәрдән китәргә мәҗбүр булалар. Бер өлеш татар Спас өязенә китеп шәһәр исеме белән Янбухта авылын нигезлиләр. Бу авыл XVIII гасырдан билгеле. Ямбухтадагы шәһәр җирлегендә руслар яши башлый. Тәтешнең Олы һәм Кече Әтрәч авылы халкы Ямбухта шәһәрлеге татарларының нәселе. Бу авыллар тирәсендә бик күп тәңкәләр табыла, Кече Әтрәч тәңкәләре коллекциясе билгеле. Бу җирлек Болгар дәүләтенең акча сугу урыны булган. 1882 елда җәмгыятьнең казначысы В. К. Савельев 1881 елның җәендә Кече Әтрәч авылы янында табылган хәзинә составындагы борынгы 47 золотник авырлыгындагы көмеш тәнкәне җәмгыятьнең минц-кабинеты өчен сатып алырга тәкъдим итә һәм аны 19 сум 20 тиенгә сатып алалар.

Тәтеш җирләренең борынгы Болгар чорыннан ук үзләштерелгән булуы, бу җирләр дәүләтнең мөһим бер өлешен тәшкил итүенә тагын бер дәлил буларак Е. Т. Соловьев Зеленовское городище һәм Льяшевское городище җирләрен карый. Болар икесе дә Тәтеш районы авыллары: Зеленовка руслар яшәгән XVIII гасырда нигезләнгән торак, ә Льяшево Казан ханлыгы чоры авылы итеп күрсәтелә, андагы халыкның 78 %ы руслар. Әмма XIX гасыр ахыры галимнәре фикеренчә, болар икесе дә Болгар кальгалары [крепость] булган. Зеленовка: «оно служило одной из крепостей Булгарского царства»

[13] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 75–80.

[14] Соловьев Е. Т. Археологические сведения о селе Ямбухтине Тетюшского уезда Казанской губернии // ИОАИЭ при Императорском университете. Том III. 1880–1882 г. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 296–297.

[15] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 75–80.

[16] Соловьев Е. Т. Археологические сведения о селе Ямбухтине Тетюшского уезда Казанской губернии // ИОАИЭ при Императорском университете. Том III. 1880–1882 г. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 296–297.

диелә, Льяшево да «служило военной крепостью», дип билгеләнә. Шәһәрлек җирләренең территориясе шактый зур: Зеленовка – 9900 кв.сажин (4 1/8 дисәтинә), Льяшево – 6700 кв.сажин. Биредә савыт-саба кисәкләре, бронза әйберләр, тәңкәләр табыла. Шулай ук 1883 елда Е.Т. Соловьев тарафыннан эшләнгән «Булгарское городище на Юматихе в Тетюшском уезде» дигән докладны И. А. Износков укый, ул бары җәмгыять протоколларында И. А. Износков комментарияләре белән төп өлешләре генә билгеле[17]. Хезмәт үзе басылмаган.

Хәзерге Буа районына карый торган Олы Фролово янында, Зөя елгасының уңъяк кушылдыгы булган Черки елгасының уң як тарафында шәһәрлек булуы билгеле, бу урын конус формасындагы калкулыкта урнашкан. 1637 елга караган патша грамотасында Зөянең йомышлы татары Бикбулат Колчуринга шушы урында җир кишәрлеге бүленеп бирелү турында сүз бара[18].

Фролово һәм Степановка шәһәрлекләре 1884 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте тарафыннан тикшерелә: Фролово территориясе – 4000 сажин, Степановка – 4400 сажин. Алар бик тәфсилләп сурәтләнә, әмма бу шәһәрлекләрнең нинди корылма булуы турында кисәк кенә бер җөмлә әйтелә дә, бик үк нигезле булмаган нәтиҗә чыгарыла. «Историческое значение Фролововской, Степановкой городища одинаково со значением Зеленовского и Льяшевского. Принимая во внимание, что до XVI века в Тетюшском уезде жили черемисы, можно предположить, что описанные четыре городища принадлежат последним»[19]. С. М. Шпилевский да С. Мельниковка сылтама белән бу урында билгесез бер халык яшәгән һәм бу аларның шәһәрлек җире булган, дип яза. Җирле халык аны Мари-төбәк дип атап йөрткән, XVII гасырның беренче яртысында биредә Мяри-Төбәк дигән кечкенә генә бер авыл да булган. С. Мельников фикеренчә, чуаш һәм мари телендә «төбәк» дигән сүз нигез (төп йорт) дигән мәгънәдә йөри, ә «мяри» мари дигән халыкны аңлатуы мөмкин[20]. Топоним исемнәре дә бу халыкның әлеге төбәккә мөнәсәбәте барлыкны күрсәтә, әмма

[17] Протоколы XX заседания Совета, 17 декабря 1880 г. // ИОАИЭ при Императорском университете. Том IV. – Казань: Типография Императорского университета, 1883. – С. 55–56.

[18] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 497.

[19] Соловьев Е. Т. О Зеленовском, Льяшевском, Фроловском и Степановском городищах // ИОАИЭ при Императорском университете. Том V. – Казань: Типография Императорского университета, 1884. – С. 13–16.

[20] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 497–498.

хәзерге вакытта Фроловода да, Степановкада да руслар яши, икесе дә XVII гасырда нигезләнгән авыллар булып санала[21].

Хәзерге Апас районы үзәгенә бик якын урнашкан Иске Энәле авылыннан 3 чакырым читтәрәк Табар елгасы ярында да шәһәрлек булуы билгеле, ул елга ярының биек өлешендә урнашкан булган, сакланып калган өлеше тигезлектәге түгәрәк сыман формада[22].

1892 елда җәмгыять галимнәре тарафыннан хәзерге Кама Тамагы районына карый торган Сөйки (Сюкеево) дигән рус авылы тирәсендә татар тарихи истәлеге – татар шәһәрлеге җире табыла[23]. Бу шәһәрлек җирле халык телендә «Кызлар уйный торган җир» дип аталып йөргән, аның мәйданы 125000 кв.м, ике бик биек булмаган вал белән әйләндереп алынган. Бу – аның соңгырак чорда да, Казан ханлыгы вакытында да, яшәгәнлеген күрсәтә торган билге[24]. Монда 1384 ел белән билгеләнгән Хызр хан тәнкәсе табыла. «Татарское жилище» дип аталган урын Сөйки (Сюкеево) авылыннан көньяк-көнчыгыштан 3 чакырым тирәсендә, шунда ук тагын башка шәһәрлек тә булган, анысы – шул ук юнәлештә 5 чакырым тирәсе ераклыкта. Шәһәрлекнең саклану тирәлеге, ныгытмалары булмый, чөнки аның тирә-ягы болай да чокырлы, үзе тау башына салынган булган. Шәһәрлектән бераз читтәрәк зират урыны. Бу зират шул шәһәрлек зираты булырга тиеш. XVI–XVII гасырга кадәр монда татарлар яшәгән. Хәтта аларның мәчетләре дә булган. XIX гасыр ахырында да Сюкеево янында морза нәселе җирләре булган, бу морза нәселләре вәкилләре хәзерге вакытта Тәтеш өязенең төрле татар авылларында гомер иткән. Сюкеево тирәсендә имәннәр үскәнгә аны Дубрава (имәнлек) дип тә атаганнар. Сюкеевоны Сюкей исемле татар кешесе нигезләгән, ул монда гаиләсе белән килеп урнаша. Бу җирдә борынгы чорның мәгарәсе дә сакланган.

Бу җирнең тарихи бер шәһәрлек булуы бәхәссез. Чөнки монда табылган тәңкәләр нумизматлар билгеләве буенча, Мәңге каган, Бәркә хан, Мәңге Тимер, Хызр хан исеменнән сугылган, ягъни алар XIII гасыр уртасы – XIV гасыр ахырына карыйлар. Е.Т. Соловьев бу шәһәрлекне XII гасыр шәһәре дип саный, «когда описываемая местность была в пределах Булгарского царства и господствующая народность, которой они принадлежали, были, чуваши, как

[21] Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1997. – С. 95, 100.

[22] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 498.

[23] Соловьев Е. Т. Памятники татарской старины в даче села Сюкеева Тетюшского уезда // ИОАИЭ при Императорском университете. Том X. Вып. 4. – Казань: Типография Императорского университета, 1892. – С. 449–451.

[24] Халиков А. Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. – Казань: Фэн, 1994. – С. 70–72.

главнейшая часть населения Булгарии»[25] дигән шактый бәхәсле нәтиҗә чыгара. Кама Тамагы җирлегендә тагын бер археологик объект Кирильское авылы янында булган. Бу урын турында археологлар тарафыннан каршылыклы фикерләр әйтелә. Бер фикер буенча, монда болгарның Ашлы шәһәре булган урын булырга тиеш, мәйданы 5000 кв. сажин. Табылган әйберләр биредә җир эшкәртүчеләр яшәгәнлегенә ишарә итә[26].

Хәзерге Чувашстанга керә торган Олы Таяба дигән җирдә дә шәһәрлек билгеле. Шәһәрлек туфрактан өелгән валлар белән әйләндерелгән. Валлар картлар сөйләве буенча, бик биек булган, аның биеклеге, хәтта кәҗәләр дә менә алмаслык булган дип тасвирлана. Территориясе 26 дисәтинә җирне биләгән. Анда яшәгән чуашлар сөйләве буенча, бу җирдә бик бай татар морзасы гомер иткән, ул үз утарын саклау өчен хәтта кечерәк кенә гаскәр дә тоткан, ә биек валларны Казан яулап алынган вакытта үз утарын саклау өчен корган[27]. Бу шәһәрлек тирәсендә курганнар да булган. Халыкта Пугачевка каршы торган гаскәриләр тарафыннан төзелгән шәһәрлек буларак та сөйләнә. Җирлектә археологик табылдыклар чыкканы булмаган[28].

Соңгырак чорда галимнәр тарафыннан башка бик күп кенә торак урыннары өйрәнелде. Зөя елгасының түбән агымына таба монгол чорына кадәр булган тарихи объектлар саны нык кими. Н. Ф. Калинин бу районда бары Алтын Урда чорына караган истәлекләр генә бар, дип яза. Әмма 1949–1950 елларда Т. А. Хлебникова Зөянең түбән агымындагы, аның уң як кушылдыгы Үләмә елгасы бассейнындагы тораклар Болгар тарихының ике чорына да карый диелә. Алар: Чүри Бураш шәһәрлеге һәм авылы, Льяшево, Зеленовка, Зөядәге Городищинское шәһәрлеге. 1960 елгы экспедициядә Р. Фәхретдинов Олы Кариле шәһәрлеге (Коры Үләмә елгасы, Зөянең уңъяк яры) монгол чорына караган керамика таба. Аннан соң монгол чорына кадәрге урыннар – Рус Макылы, Улан шәһәрлеге ачыклана. 1967 елда Р. Фәхретдинов тарафыннан Иске Энәле, Тауиле, Апас шәһәрлеге – болар монгол явына кадәр булган Болгар чорына карый торган һәйкәлләр. Бәйрәш, Олы Тормы, Атабай, Күлбаш, Коры Үләмә авылы тирәсендәге табылдыклар да Болгар чорының әлеге дәверенә карый. Димәк, Зөя елгасының түбән агымы

---

[25] Соловьев Е. Т. Памятники татарской старины в даче села Сюкеева Тетюшского уезда // ИОАИЭ при Императорском университете. Том X. Вып. 4. – Казань: Типография Императорского университета, 1892. – С. 451.

[26] Пономарев П. Данные о городах Камско-Волжско Булгарии. (Археологические заметки). Ошель и его следы // ИОАИЭ при Императорском университете. Том X. Вып. 3. – Казань: Типография Императорского университета, 1892. – С. 273–288.

[27] Зайцев И. Городище в даче села Б. Таяба // ИОАИЭ при Императорском университете. Том X. Вып. 1. – Казань: Типография Императорского университета, 1892. – С. 112–113.

[28] Заметки о городищах, курганах и древних земляных насыпях в Казанской губернии. – Казань: в губернской типографии, 1874. – С. 33.

болгарлар тарафыннан монгол чорына кадәр үзләштерелгән җирләр икәне ачыклана. Болгарларның бу якка килүе монгол чорына кадәр булган вакытның икенче өлешендә барган булырга тиеш һәм бу сәяси хәлләр катлаулану белән аңлатыла. 1220 елда Ашлы шәһәренә рус гаскәрләренең һөҗүме билгеле, ягъни бу җирләрнең үзләштерелүе килеп туган куркыныч хәлләр белән бәйле.

Хәзерге Кама Тамагы Олы Кариле авылы янында овал формасында шәһәрлек җире сакланган, зурлыгы 327 сажин, ул тау итәгендә, елга буенда урнашкан, вал һәм чокыр белән әйләндереп алынган, әмма яз көне су килгәндә бу җир юыла торган була, ул урын тора-бара чәчүлек җиренә әйләнгән[29].

Татар авылы Танай Турайдан 100 сажин ераклыкта урнашкан җирдә шулай ук 300 сажин мәйдандагы түгәрәк формадагы урын вал һәм чокыр белән әйләндерелгән, Иске Энәле янында да якынча шундый ук зурлыкта шәһәрлек урыннары булган. Дәүеш авылы янындагы шәһәрлек биегрәк җирдә урнашкан һәм аның да формасы түгәрәк формасында 900 сажин мәйданны били. Бу җирләр инде күп еллар басу булып кулланыла, сөреләә[30]. Хәзерге Тәтеш районына карый торган Олы Тормы авылы янында өч курган булган, татарлар аларны Алан Аяк дип атап йөрткәннәр, инде алар югалган, шулай ук сөрү җиренә әйләнгән. Бу җирләрдә тарихи әйберләрнең табылганы булмаган[31]. Кама Тамагы районына керә торган Уразлы авылы янында да 270 сажин җирлектә түгәрәк сыман формада шәһәрлек җирләре сакланган була, әмма тора-бара ул җирлек сулык белән юылып беткән, шулай ук югалган шәһәрлек урыны Олы Таяба волостена караган Андреевка авылы янында да булган.

Халык тыгыз урнашкан Кама аръягы җирләре Болгар чорының икенче дәверендә дә үз әһәмиятен саклап кала алса, Идел алды җирләрендә хәл башкарак. Халык тыгыз урнашкан дип саналган Кильна һәм Цильна арасындагы җирләрдә дә бары тик берничә генә тарихи истәлек билгеле. Нигездә, алар эпиграфик истәлекләре сакланган зиратлар һәм алар XIV гасырның беренче яртысына карыйлар. Тау ягында монгол явына кадәрге чорга караган тарихи истәлекләр Зөя елгасының урта агымында тупланган, икенче төркем археологик истәлекләр Зөя елгасының түбәнрәк агымына – аңа Бола елгасы кушылган өлешкә карый: Дәүеш, Олы Таяба, Тигәш, Иске Янаш шәһәрлекләре. Бола елгасы бассейнында 15 Болгар чоры истәлеге табыла, шуларның 7 се монгол явына кадәр булган чорга туры килә. Рельефның тигез

---

[29] Заметки о городищах, курганах и древних земляных насыпях в Казанской губернии. – Казань: в губернской типографии, 1874. – С. 30–31.

[30] Шунда ук.

[31] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 500.

булуы, кара туфраклы уңдырышлы җирләрнең күп булуы да болгарларның төпләнү урынын сайлауда хәлиткеч роль уйнаган. Зөя елгасының түбән агымына, Үләмә елгасының уңъяк агымындагы археологик истәлекләр Болгар чорының ике этабына да карый. Өйрәнелә торган территория, хәзерге Тәтеш, Апас районы җирлекләрендә Болгар тарихының монгол явына кадәр дә, монгол явыннан соңгы чорына караган тарихи истәлекләр билгеле. Чүри-Бураш, Иске Энәле, Апас, Бәйрәш, Олы Тормы, Атабай, Коры Үләмә, Күлбаш җирлекләре шундыйлардан. Чүри Бураш җирлеге 1949 елда ук Н. Ф. Калинин тарафыннан өйрәнелә. Керамика табыла һәм дә монда, галим билгеләве буенча, металл эшкәртү үзәге дә булганлыгы ачыклана. Танай Турай, Шонгаты җирләре бу җирлектә табылган керамик материаллар нигезендә Болгар чоры торак пунктлары булуы раслана. Болгар чорында гына түгел, Үләмә елгасы бассейны Алтын Урда чорында да икътисадый үзәк булып торган.

Хәзерге Тәтеш шәһәре тирәлегендә халык шактый тыгыз яшәгәнлеге хакында археологик табылдыклар да раслый. 1847 елда «Казанские губернские ведомости» (№ 21) газетасында билгесез автор Тәтеш шәһәре урынында, һичшиксез, борынгы Болгар торак пукты булуын яза. С. Шпилевский фикеренчә, шәһәр урыны булган җир югарылыкта урнашкан, бу урын Иделнең икенче ягындагы Болгар белән элемтә тоту, саклану максатында күзәтү урыны булуы ихтимал. Аның фикеренчә, Тәтеш шәһәре буш урында нигезләнмәгән, монда Болгар чорында ук торак урыны булуга дәлилләр бар. Тәтешнең төньягында ниндидер ныгытмалар, бина калдыкларының фрагментлары очрый. Җирле халык хәтере буенча, бу урында татар бие яшәгән, шәһәр чиркәве янында табылган бинаның таш нигезе фрагметлары аның йортыныкы булырга тиеш, диелә. С. Шпилевский язуынча, чиркәү өчен фундамент казыганда берничә каберлек ачыла, көмеш тәңкәләр, хатын-кыз бизәнү әйберләре табыла. Шәрәфетдин Болгари хезмәте буенча, Тәтешнең нигезләнүе Тимер яуларыннан соң булган, ислам таратучы Бадам бине Шаһ Сәлимнең биредә җирләнүе шул хакта сөйли. Халык риваятьләре буенча, борынгы Тәтешнең урыны хәзерге Тәтештән 7 чакырым читтәрәк «Богородицкий базары» дигән урында булырга тиеш, әмма С. Шпилевский бу версияне кабул итеп бетерми, чөнки ул шактый тар урын, су ташу вакытында су белән юылып территория тагын да кечерәя. 1949 елда «Богородицкий базары» дигән урында XIV гасырга караган керамика табыла. Колунец авылы җирлегендәге торак пункты Тәтештән бераз соңрак нигезләнгән[32].

Хәзерге вакытта Хельсинкида саклана торган коллекция составында Тау ягы районнары авылларында табылган тарихи археологик истәлекләр бар. Шундыйлардан, Апас районы территориясендә табылган археологик истәлекләр: Иске Кырбашта табылган көмеш каеш каптыргычлары, Урта Бал-

[32] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 322–323.

тайда тимер, бронза һәм тимер эш, сугыш кораллары, Кызыл Тау (Коллар) авылындагы ерткыч орнаметы ясалган бронза, тимердән эшләнгән ук очлары, Дәүештәге тимер ук очлары, сөяктән ясалган әйберләр, керамика фрагментлары, Колгына авылындагы тимер балта, Буа районы Бәбки авылындагы бронза йозаклар, тимер балталар, Тәтеш районының Бәйрәш авылындагы сөңгенең тимер очы, Олы Тормының тимер балта, Кама тамагы районының Иске Барыш авылындагы бронза эшләнмәләре һ.б. Шулай ук Дәүләки авылында тимердән эшләнгән эш, сугыш кораллары, Каратун авылында бакыр мөһер фрагментлары, Югары Балтайда укның тимердән ясалган очы, Каргалыда сөяктән ясалган ук очы табыла[33].

Әтрәч (хәзерге Тәтеш районы) авылы җирлеге, борынгы Шонгаты шәһәре җирләре булган урыннар тарихи табылдыкларга аеруча бай, халык бу урыннарда борынгыдан калган тарихи әйберләрне даими рәвештә табып торган. Монда табылган борынгы тәңкәләр хакында язманың алдагы өлешендә сүз барыр, тәңкәләрдән кала, яңгыр явып үткәннән соң, туфрак юылгач бик күпләп керамика кисәкләре чыккан. Зираттан ерак булмаган сөзәклектә керамика кисәкләренең күпләп табылуы бу җирдә халык хәтере буенча, чүлмәкчеләр бистәсе урнашкан булу хакында сөйли. Еш кына халык тапканны үзенә алып киткән, тарихчы Г. Әхмәрев язуынча, татарлар борынгыдан калган әйберләрне яраталар, алар аны изге итеп саныйлар, бирмиләр, хәтта сатып бирергә дә ашкынып тормыйлар[34]. Бу җирләрдә халык тарафыннан кирпеч ватыклары, кремнийләшкән известьташ кисәкләре, орнаментсыз гына эшләнгән түгәрәк чүлмәкләр, кувшин кисәкләре табыла. Нигездә, эшләнмәләр сыйфатлы, яндырылган кызыл, хәтта миләүшә төсендәге балчыктан ясалган, сирәк кенә соры төстәге ватыклар да очрап куя. Галимнәр билгеләвенчә, аларның кайберләре «лощение» ысулы белән эшләнгән, ягъни булачак савыт стеналарын көзге кебек шомарталар, кайберләре сызыкча оргамент һәм тараксыман штамп оттисигы белән бизәлә. Табылдыкларның берничә фрагменты түгәрәк сосуд төбеннән таҗчык белән бизәлгән булган, шундый таҗчыкның булуы савытлар Алтын Урда чорында ясалуга ишарә итә[35]. Әтрәч җирлегендә табылган әйберләр арасында X гасырның соңгы чорына, XI гасырның беренче яртысына караган бронзадан эшләнгән табылдыклар, хәтта VIII–IX гасырларга караган ат сбруеның бер детале, XI–XIII гасырның беренче яртысына караган икенче төркем ак металлдан бөртекләп

[33] Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С.167–190.

[34] Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии // ИОАИЭ при Императорском университете. Том XV. Вып. 4 – Казань: Типо-литография Императорского университета, 1899. – С. 446–447.

[35] Руденко К. А., Бугарчёв А. И. Археологические и нумизматические находки из окрестностей села Большие Атряси (Тетюшский район РТ) // Поволжская археология. – 2015. – № 3 (13). – С. 156–175.

һәм сканлап эшләнгән муенга тагыла торган бизәкле диск формасындагы әйбер табыла.

Бу төбәкне археологик яктан өйрәнү совет елларында да алып барыла: Л. М. Тамбовцев тарафыннан Зеленовский, Льяшев шәһәрлекләре һәм Красно-Полянскийдагы әрмән язулы caберташы тикшерелә[36]. Максатчан археологик фәнни экспедиция бу төбәккә 1949[37], 1950[38] елларда Н. Ф. Калинин җитәкчелегендә оештырыла, 1957 елда СССРның Фәннәр академиясенең Казан филиалыннан А. Х. Халиков һәм В. Ф. Генинг җитәкчелегендәге экспедиция эшли[39]. 1957 һәм 1960 еллар аралыгында А. Х. Халиков һәм В. Ф. Генинг экпедицияләре Олы Тарханда 358 каберлекне ачалар[40]. 1961 елда Р. Г. Фәхретдинев җитәкчелегендә фәнни тикшерүләр алып барыла[41]. 1963–1965 елларда А. П. Смирнов һәм В. Ф. Каховский җитәкчелегендәге казу эшләре бара[42]. 1966 елда М. Г. Косменко[43], 1969 елда Р. С. Габяшев[44], шул ук елны Е. П. Казаковның[45] ачышлары билгеле. 1970 елда Е. А. Халикова Олы Тарханның 7 каберлеген тикшерә[46]. 1980 елларда Тәтеш төбәген Е. П. Каза-

[36] Тамбовцев Л. М. На поиски болгарских городов // ЗТМ. – Казань, 1928. – № 3. – С. 14–16.

[37] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.5, оп.32, д.1. Калинин Н.Ф. Отчет об археологической экспедиции КФАН СССР по западным районам Татарской Республики в 1949 г. – Казань, 1949. – 72 л.

[38] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.5, оп.33. д.1. Калинин Н.Ф. Отчет о работах археологической экспедиции Казанского филиала Академии наук СССР в 1950 г. по западным районам ТАССР. – Казань, 1950. – 61 л.

[39] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.5, оп.40, д.1. Халиков А.Х., Генинг В.Ф. Отчет о полевых работах археологической экспедиции КФАН СССР в 1957 г. в юго-западных районах Тат. АССР. – Казань, 1957. – 180 л.

[40] Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. – М., 1964. – С.67–69.

[41] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.5, оп.2, д.18. Фахрутдинов Р.Г. Отчеты о работе III, IV и VI разведочных отрядов Татарской археологической экспедиции 1961 г. – Казань, 1961. – 79 л.

[42] Каховский В.Ф. Смирнов А.П. Болгарский город «Хулаш» // Тезисы доклада на заседаниях, посвященных итогам полевых исследований 1965 г. – М., 1966; Каховский В.Ф. Смирнов А.П. Хулаш // Городище Хулаш и памятники средневековья Чувашского Поволжья. – Чебоксары, 1972.

[43] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.5, оп.2, д.207. Косменко М.Г. Дневник археологических разведок по р. Свияге, Волге и Каме в 1966 г. 27 л.

[44] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.11, оп.2, д.9. Габяшев Р.С. Археологические памятники города Тетюши – 5 л. Машинопись.

[45] Казаков Е. П. О характере связей поволжских финно-угров с населением ранней Волжской Болгарии // Вопросы финно-угроведения. – Йошкар-Ола, 1970. – С.158–159.

[46] НФ МА РТ ИА АН РТ. Ф.7, оп.1, д.9. Халикова Е.А. Материалы к отчету по Тетюшам: чертежи – 158, фото – 30, фотонегативы – 3. 1970.

ков, В. С. Патрушев, А. А. Чижевскийлар[47], 2000 нче елларда А. А. Борханов, К. А. Руденко, А. С. Губиннар өйрәнәләр.

Тәтеш төбәгенең борынгы археологик истәлекләре инкыйлабка кадәрге чорда ук тикшерелә башланып, совет елларында да игътибар үзәгендә булган, соңгы вакытта да бу төбәкнең археологик истәлекләре галимнәрнең күз уңыннан читтә калмый. Шунлыктан, бу төбәкнең бик күп объектлары фәнни әдәбиятта тасвирланган. Бай археологик истәлекләре булу бу төбәк тарихын тирәнрәк өйрәнү һәм киңкырлы карарга мөмкинлек бирә. Галимнәр тикшерүеннән аңлашылганча, Тәтеш төбәге Идел буеның мөһим бер үзәге була. Бу территориядә яшәгән халыкның матди мәдәният үсеше югарылыгы чагыла. Кызганычка каршы, аларның инде күбесенең хәзерге вакытта урыны да калмаган, әмма билгеле булганнарын саклау, аларга игътибарлы булу хәзерге чорның бурычы булырга тиеш.

[47] Казаков Е.П., Патрушев В.С. Раскопки Тетюшского могильника // АО – 1980. – М., 1981. – С.135–136; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар кн. Изд-во, 1987. – 238 с.

## § 2. *Нумизматик истәлекләр*

Борынгы Болгар шәһәре Шонгаты Болгар дәүләтенең акча сугу үзәге булган. Хәзерге вакытта бу җирлек Әтрәч авыллары җирлегенә туры килә. Фәнгә билгеле тарихи истәлекләр арасында «Әтрәч хәзинәсе» дигән акча коллекциясе бар. Фәнни әдәбиятта Олы һәм Кече Әтрәч тирәлегендә табылган 4 хәзинә билгеле. 1891 елда көмеш тәңкәләр хәзинәсе А. Ф. Лихачев тарафыннан хәбәр ителә. Ул үз хезмәтендә 13 см зурлыгындагы, хәзерге үлчәү берәмлеге белән 203,7 г (47 ¾ золотник) авырлыгындагы көмеш коелмасының рәсемен бирә. Бу табылган хәзинәне авыл кешеләре бер читтән килгән сәүдәгәргә 700 сумга сатып җибәргәннәр. 1856 елда табылган хәзинәдә XIII–XIV йөз ахырына караган 10000 нән артык көмеш тәңкәләр бар, 1282–1393 елларга караган (һиҗри ел исәбе белән 681–795 еллар) 2297 тәңкә тасвирланган. Бу хакта археолог, шәрык белгече, нумизмат П. С. Савельев яза. 1932 елда Кече Әтрәч авылында 200 г бакыр тәңкәләр табылган, бу хәзинә Д.М. Мөхәммәтшин мәкаләсендә генә искә алына[1], кызганычка каршы, бу махсус тикшерелгән хәзинә түгел. Ә. Булатов, А. Халиков язмаларында бу вакытта табылган бакыр акчаларның авырлыгы 5 кг дип күрсәтелә[2]. 1954 елда табылган хәзинә күләме ягыннан иң зурысы, монда XIV йөзгә караган 20 мең Җүчи чоры көмеш тәңкәләре бар. Коллекциядә Токта хан чорыннан башлап Бик-Булат чорына кадәрге (710–793 еллар – һиҗри ел исәбе буенча, милади ел исәбе белән якынча 1332–1415 еллар) тәңкәләр. Бу хәзинәнең табылу тарихы да кызыклы, «Әтрәч хәзинәсе» дигәндә дә шушы табышны күздә тоталар. Бу хәзинә тарихчы, тәңкәләр өйрәнүче галим Әзһәр Мөхәммәдиев тарафыннан тәфсилләп тикшерелгән[3].

Олы Әтрәч тирәлегеннән табылган тәңкәләр турында 2003 елда С. В. Гумаюнов, И. В. Евстратов тарафыннан мәкалә язылды, анда 42 көмеш тәңкә, 144 бакыр акча турында сүз бара[4]. Бу акчаларның иң борынгысы XIV йөз башына караса, иң соңгылары 1371–1372 (773 ел һиҗри ел исәбе белән) елгы тәңкә һәм 1383–1384 (785 ел) елларга карый торган дөя рәсеме төшерелгән пул. Әтрәч хәзинәсенең тулы тасвирламасы белән нумизматика белгечләре

---

[1] Мухаметшин Д. Г. Клады Тетюшской округи // Исследования по средневековой археологии Евразии. – Казань: Школа, 2012. – С. 197–217.

[2] Халиков А. Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. – Казань: Фэн, 1994. – С. 70–72.

[3] Мухаммадиев А. Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. – М.: Наука, 1983. – 168 с.

[4] Гумаюнов С. В., Евстратов И. В. Шонгат – неизвестный монетный двор Золотой Орды // Одиннадцатая Всероссийская нумизматическая конференция. Тез. док. и сообщ. – СПб.: Гос. Эрмитаж, 2003. – С. 79–81.

хезмәтләрендә яктыртылган[5]. Шулай да, кызганычка каршы, бу хәзинәдәге барлык акчалар әлегә кадәр нумизматлар тарафыннан өйрәнелеп бетмәгән.

Борынгы тәңкәләргә халыкның изге әйбер итеп каравы билгеле, гомумән, татарлар борынгы әйберләрне кадерләгәннәр, аларда ниндидер тылсым барлыкка инанганнар, шуңа күрә дә, борынгы әйберләрне кеше күзеннән яшеребрәк, талисман итеп сакларга тырышканнар. Бу хакта тарихчы Г. Әхмәрев тә яза, ул археологик экспедиция белән чыккач, тарихи ядкәрләрне халыктан сатып алу максатын да куя, әмма халык андый әйберләрне, ничек кенә акча кирәк булса да, сатмаска тырышкан. Татар кызлары борынгы тәңкәләрдән чулпы ясатып такканнар, яисә бизәнү әйберләре буларак кулланганнар. Х. Фәезханов Тәтеш өязе Әлки авылының имамы Баһаветдин хәзрәтнең дүрт-биш яшьлек кызының күлмәк якасында 15 тиенлек зурлыгында ике тәңкә күреп ала. Тәңкәгә чокып 3 юллык текст язылган. Текст тулысы белән укылырлык булмый, Х. Фәезханов укылган өлешен китерә: 1) «гакан әлх...»; 2) «солтан ә...»; 3) бары бер «әлиф» хәрефе генә күренә. Икенче тәңкәнең беренче ягы: «л әд-дин Әбүбәкер хан», икенче ягында: «әс-с әл-хәдир син»[6] дигән сүзләрне, яисә сүз фрагментларын гына аерып була.

*Каратун хәзинәсе* – Тау ягының иң мөһим хәзинәләренең берсе. Җүчи Олысы чорына караган көмеш тәңкәләр хәзинәсе 1986 елның 26 маенда хәзерге Апас районына карый торган Каратун тимер юл станциясе янында табылган. Зур бронза чүлмәк бульдозер «теше»нә эләгеп ватыла, бу вакыйга турында эшчеләр милициягә хәбәр итәләр, ә алга таба инде бу хәзинә галимнәр карамагына күчә. Чистартылмаган көе, табылган гына вакытында 35 кг авырлыкта булган тәңкәләрне Р. Фәхретдинов кабул итеп ала, аннан күренекле нумизмат, археолог, тарихчы, Мәскәү университеты профессоры Г.А. Федоров-Давыдовка өйрәнү өчен өлешләп тапшыра. Г.А. Федоров-Давыдов әлеге Каратун хәзинәсен 11 ел дәвамында өйрәнә, әмма вафат булу сәбәпле ахырына кадәр барып җитә алмый, аның эшен күренекле нумизмат Җ. Г. Мөхәммәтшин дәвам итә. Нәтиҗәдә бу хәзинәгә багышланган зур күләмдәге китап дөнья күрә[7]. Каратун хәзинәсе 24200 тәңкәдән гыйбарәт, шуларның күпчелеген Җүчи Олысы чорына караган көмеш тәңкәләр, 4 се бакыр акча. Җүчи Олысы чорына караган шулкадәр көмеш тәңкәләрдән торган хәзинәнең Россия күләмендә дә, Алтын Урда тәңкәләре табылган башка төбәкләрдә дә (Иран, Молдова һ.б.) тиңнәре юк. Тәңкәләрнең сыйфаты бик югары, белгечләр әйтүе буенча алар 90 % чиста көмештән тора. Сыйфат

[5] Руденко К. А., Бугарчёв А. И. Археологические и нумизматические находки из окрестностей села Большие Атряси (Тетюшский район РТ) // Поволжская археология. – 2015. – № 3 (13). – С. 156–175.

[6] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.254.

[7] Федоров-Давыдов Г.А., Мухаметшин Д.Г. Каратунский клад джучидских монет XIV века. Том. I. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, «Палеограф», 2018. – 307 с.

ягыннан гына түгел, хәзинә социаль-сәяси яктан да зур әһәмияткә ия. Бу хәзинәнең 78,8 %ы Туктамыш чорында сугылган тәңкәләр булуы белән дә уникаль, 1856 елда табылган Кече Әтрәч хәзинәсендәге 10000 тәңкәнең зур күпчелеге Туктамыш чорыныкы булганын да искәртү кирәк. Тагын бер мөһим факт – ул хәзинәдә Алтын Урда ханнарының барысының да диярлек тәңкәләре булуы. Каратун янында табылган тәңкәләрне өйрәнгән Г. А. Федоров-Давыдов үз язмаларында бу хәзинәнең фәнгә билгеле булган Алтын Урда чорының иң уникаль хәзинәсе дип бәяли. Алга таба Г. А. Федоров-Давыдов эшен дәвам итеп, тәңкәләрне тасвирлаган Җ. Г. Мөхәммәтшин Каратун хәзинәсе «урта гасыр тарихы өчен генә түгел, ә барлык Алтын Урда нумизматикасы өчен зур әһәмияткә ия»[8], дип белдерә.

Бу хәзинә 1395 еллар тирәсендә Тимер явы килүдән куркып яшерелгән булырга тиеш. Г.А. Федоров-Давыдов бу хәзинәгә кыскача гына биргән характеристикасында хәзинә составын күрсәтә: хәзинәнең төп өлешен Җүчи чоры дирһәмнәре алып тора, 700 экземпляр Алтын Урда тәңкәләренә охшатып эшләнелгән акчалар, бер өлеш тәңкә Иранның Җәларид династиясенеке, бер өлеше Тимер акчалары. Шунда ук рус акчалары – Дмитрий Донской, Василий I неке бар һ.б.[9] Хәзинә төрле төбәк акчаларын үз эченә алган. Хәзерге вакытта Каратун хәзинәсе ике музейда саклана. Бер өлеше «Казан» Милли-мәдәни үзәгенә тарихчы Р.Г. Фәхретдинов аша керә (тапшыру акты 1997 елның 16 июне 37 нче номер). Барлыгы 9024 тәңкә. Икенче өлеше Р. Фәхретдинов һәм Иске Казан музее аша 2007 елда Татарстан Республикасы Милли музей фондына керә (даими саклау турындагы акт № 23/15 һәм 24/15, 2015 елның 23 марты һәм КП–35464/1–14754 инвертарь номеры астында саклана). Монда барлыгы 19856,26 г авырлыктагы 14750 көмеш һәм 4 бакыр тәңкә[10].

*Борындык хәзинәсе.* Каратун хәзинәсеннән соң бер ел үткәч шул ук төбәктә яңа бер хәзинә – Болгарда монгол ханнары Мәңге һәм Арык-Буга исеменнән сугылган 906 көмеш тәңкә Борындык авылы (Апас районы) янында табыла. Аны урман янында мәктәп укучылары табып ала. Кызганыч, хәзинәнең бер өлеше мәктәп балалары, җирле халык арасында таралып бетә, аны инде киредән җыеп алу мөмкин булмый. Бу – XIII йөзгә караган иң мөһим хәзинәләрдән санала, алар кызыл балчыктан яндырып эшләнгән көмеш капкачлы керамик чүлмәккә тутырып, 1260 нчы елларда күмелгән тәңкәләр. Капкачына ике балык рәсеме төшерелгән. Бу хәзинә, үз чиратында, Болгар –

[8] Федоров-Давыдов Г.А., Мухаметшин Д.Г. Каратунский клад джучидских монет XIV века. Том. I. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, «Палеограф», 2018. – С. 9.

[9] Шунда ук. – С. 9.

[10] Шунда ук. – С. 18.

Алтын Урданың тәңкә сугучы беренче шәһәре һәм әһәмиятле һөнәр һәм сәүдә үзәге булганлыгын күрсәтүче билге[11].

*Әтрәч хәзинәсе.* Әтрәч хәзинәсе турында сүз алып барганда халык 1954 елгы табышны хәтердә тота. Аның табылу тарихын да телдән-телгә риваять рәвешендә сөйләп киләләр. Бу җирлек элек-электән тарихи урын икәне билгеле булса да, фән өчен бу хәзинә турында шактый соңлап кына ачыклана. Авыл халкы җир эшләре вакытында берәм-сәрәм чыккан тәңкәләрне җыя торган булган, вак акча җыю балалар өчен дә кызыклы шөгыль. Яңгырдан соң тәңкәләр Зур Әтрәчнең «Тәңкә сызасы» дип аталган кырында юылып җир өстенә чыккан, халык аларны җыеп күкрәкчәләр ясаган, калфакларын бизәгән, чулпылар ясаганда кулланганнар. «Изгеләр өсте» дип аталып йөргән кырда, хәтта алтын тәңкәләр дә табылуы хакында хәтерлиләр. Авылның абыйлы-энеле Хәйруллиннар кыр эшләреннән кайтканда энесе ялтырап торган металлга игътибар итә, әмма абыйсы аңа «ташла ул зәхмәтле нәрсә», дип алырга рөхсәт итми. Халык сөйләве буенча, аннан энесеннән качып килеп пул алтын акчаны үзе ала, шуннан кисәк кенә баеп китә, имеш.

Ә зур хәзинәгә басуларны сукалаганда трактор төрәне чүлмәк авызын ваткач, чәчелгән акчаларны колхоз малларын көтүче Садыков Рәмис күреп, Мансур Гәрәев белән бергәләп җыеп алалар. Аларның берсе 10 кг га якын, ә икенчесе 1 кг да 600 г тәңкә җыя. Хәзинәнең зур өлеше тирә-күршеләргә, дусларга тарала, әлбәттә иске акчалар карау барысына да кызык. Калган өлешен Р. Садыков 8 кг 200 г, М. Гәрәев – 1 кг 600 г акчаны Апас районы милиция бүлегенә илтеп тапшыралар. Бу табышны ишеткән авылдашлар да кызыксынып, табылган җиргә барып эзләп, күпмедер тәңкә табалар. Алар да табышларын дәүләткә тапшыралар. Шулай да, бу авыл кешеләрендә үзләре кырдан тапкан борынгы тәңкәләр саклана, әлбәттә инде, барысы да тапшырып бетермиләр. Кече Әтрәч хәзинәсе Татарстан Республикасы Милли музее фондына СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалыннан А. Х. Халиков аша 1957 елның 29 апрелендә 1145 нче номерлы акт белән тапшырыла. Аңа № КПНу–33843 инвентарь номеры бирелә. Хәзинәне тапкан Р. Садыков һәм М. Гәрәевләр 1000 сум күләмендә акчалата бүләккә ия булалар. Шул ук Кече Әтрәч кырыннан 88 көмеш тәңкә табыла, аларны 1965 елның 7 июнендә 3642 номерлы акт белән шулай ук музей фондларына тапшыралар. Монда 97,6 г авырлыктагы хәзинәне тапшыручы – А. С. Җамалетдинев[12].

1954 елгы табыш билгеле булганнан соң, бу урынны археолог А. Х. Халиков һәм нумизмат Ә. Булатов килеп тикшерә. Акчалар арасында XIV гасырга караган 20 алтын акчаларның булуы да мәгълүм, ул акчалар Һиндстан патшасы Потан идарә иткән чорныкы, алар бу җирлеккә сәүдә белән килеп

[11] Федоров-Давыдов Г.А., Мухаметшин Д.Г. Каратунский клад джучидских монет XIV века. Том. I. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, «Палеограф», 2018. – С. 8.

[12] Шунда ук. – С. 20.

чыккан. Тәтеш җирләре Болгар дәүләтенең мөһим бер торагы булган, Булат Тимер явы вакытында Иделнең уңъяк яры талана[13], Болгар дәүләтенең Шонгаты шәһәрлеге җирендә (хәзерге Әтрәч авылы җирлекләре) акча сугу үзәге дә җимерелә. Кече Әтрәч кырында табылган акчалар билгеле бер авырлык нормаларына туры китереп сугылган. Алар Урта Идел сәүдәсендә әйләнештә йөргәннәр, күпләп табылуы да шул хакта сөйли. Халыктан җыеп алынган 1597 тәңкәнең 1376 сы нумизматлар тарафыннан өйрәнелгән. Бу акчалар барысы да Идел буенда Алтын Урда чорында сугылган акчалар. Вакыты ягыннан караганда табылган акчалар 100 ел эчендә, 20 хан исеменнән эшләнгән. Галимнәр билгеләве буенча, иң борынгы акча 1310 елда Токта хан исеменнән Сарай шәһәрендә, ә иң соңгысы 1410 елныкы һәм Булат хан исеменнән сугылган. Хәзинәдәге иң зур коллекция Җанибәк хан идарә иткән чор акчалары. 1376 акчадан 17 акча Токта ханныкы, 204 е – Үзбәк ханныкы, 650 акча – Җанибәк ханныкы, 199 акча – Бирдебәк ханныкы, 61 акча – Көлнә хан, 82 акча – Хызыр хан, 22 акча – Туктамыш хан исеменнән сугылган. Бу тәңкә коллекциясендәге акчаларның күп өлеше Гөлстанда сугылган, Гөлстанда Мөрид хан исеменнән сугылган 348 тәңкә очрый. Әтрәч җирлегендә табылган акчалар арасында Яңа Сарайда сугылган 384, Гөлстанда – 460, Азак (Азов) шәһәрендә – 81 данә, шулай ук Болгар шәһәрендә, Хорезм (Хива)да, Маҗар шәһәрендә (Төньяк Кавказ, Кума елгасы буенда), Мокшы (Пенза өлкәсе Норавча районында), Орду (Казан белән Сарытау арасы) сугылган акчалар бар. Гөлстан – ул гөлбакча дигән мәгънәне бирә. Тарихта алар икәү: Гөлстан әл-махурыса һәм Гөлстан әл-җәдид, тарихчылар фикере буенча, шуларның берсе – «Мең өйле Шонгаты» дип атап йөртелгән урында булуы мөмкин. Гөлстанның Болгар йорты чикләрендә, яисә шәһре Болгарның үзендә дә булуы ихтимал.

Сөйкидә (Кама Тамагы районы) Алтын Урда чорына караган тәңкәләр, шул исәптән, Хызыр хан исеменнән сугылган акчалар да XIX гасыр ахырында ук Е. Т. Соловьев тарафыннан[14], тәңкә хәзинәсе Тәтеш районына карый торган Өрем авылында табыла.

[13] Халиков А. Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. – Казань: Фэн, 1994. – С. 70–72.

[14] Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С.59.

*Монгол явына кадәр булган чорда Болгар дәүләте тәңкәләре*
*Әтрәч авылында табылган акчалар*

| № | Хан исеме | Кайсы елларга караган | Акча саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Күлнә хан | 1358–1361 еллар | 417 данә |
| 2 | Нәүрүз хан | 1358–1361 еллар | 1088 данә |
| 3 | Хызыр хан | 1358–1361еллар | 727 данә |
| 4 | Тимерхуҗа хан | 1359–1361 еллар | 18 данә |
| 5 | Урдумәлик хан | 1360–1361 еллар | 54 данә |
| 6 | Килдебәк хан | 1360–1362 еллар | 127 данә |
| 7 | Мөрит хан | 1360–1363 еллар | 348 данә |
| 8 | Габдулла хан | 1360–1361 еллар | 127 данә |
| 9 | Мирбулат хан | 1362–1363 еллар | 6 данә |
| 10 | Дәүлиулла Хуҗа хан | 1364–1365 еллар | 7 данә |
| 11 | Газизшәех хан | 1364–1365еллар | 101 данә |
| 12 | Булат Тимер хан | 1366- 67еллар | 17 данә |
| 13 | Орыс Мөхәммәд хан | 1370–1371 еллар | 372 данә |
| 14 | Ка(һ)ганбәк хан | 1375–1376 еллар | 3 данә |
| 15 | Мөхәммәд Бүләк хан (Мәмәт хан) | 1370–1371 еллар | 17 акча |
| 16 | Туктамыш хан | | Күпчелек акчалар аныкы булуы ихтимал, чөнки бу чорда акчалар бер генә хан исеменнән сугыла башлый. |
| 17 | Бирдебәк хан | 1387–1388 еллар | 18 данә |
| 18 | Түләкбәк хан | 1380–1381 еллар | 16 данә |
| 19 | Бикбулат хан | 1391–1392 еллар | 2 акча |

Тәтеш төбәгендә табылган зур хәзинәләр тарих фәне өчен мөһим чыганаклар. Бу тәңкәләр нигезендә тарихи сәхифәләргә ачыклык керә. Нумизматик материалларга таянып төбәкнең аралашу даирәсе дә күзаллана, аның борынгы тарихын күзаллау өчен җирлек ачыла. Тәтеш төбәгенең Болгар чорында ук дәүләтнең тәңкә сугу үзәге булу ачыклана, бу исә, үз чиратында, әлеге төбәкнең борынгы заманнардан ук икътисадый үзәк булуын дәлилли.

# § 3. *Борынгы зиратлар һәм кабер ташлары*

Зиратлар – борынгыдан сакланып калган кабер ташлары тарих фәнендә мөһим тарихи чыганаклар. Атаклы галимнәр Ш. Мәрҗани дә, Х. Фәезханов, Г. Әхмәрев тә борынгы чорны өйрәнгәндә бу чыганакларны барлаганнар, текстларын күчергәннәр, анализлаганнар. Татарларда кабер ташлары тора торган урынны зират дип атарга гадәтләнсәләр дә, татарларның борынгы тарихында, төгәлрәге, Болгар чоры тарихында, вафат булган кешеләрне җирләү урынын «ташбилге», дип атаганнар. Тарихчы Г. Әхмәрев фикеренчә, татарларның бабаларына зират һәм кабер дигән гарәп сүзләре Идел буенда ислам дине ныгу белән кулланыш алганнар. Ул «ташбилге» сүзенең Спас өязе Җанбакты, Рәҗәп (хәзерге Спас районы Иске Рәҗәп авылы), Алабуга өязенең Тирсә авылында (Әгерҗе районы), шулай ук Тәтеш өязе Сатлыган, Келәнче авылларында (Кама Тамагы районы) авылларында зиратны белдерү өчен кулланылуы хакында яза[1].

Тау ягында Җүчи Олысы заманнарыннан ук сакланып калган кабер ташлары шактый, борынгы зиратлар да аз түгел, чөнки бу төбәк халык шактый тыгыз яшәгән һәм таза тормыш алып барган урыннар. Матди мөмкинлеге булган халык кабер ташларын да зурны, бизәклене куйган. Бу очракта, халык еш кына, борынгылыкны Болгар чоры дип күрсәтергә гадәтләнгән, халык телендә Алтын Урда, яисә Җүчи Олысы заманы дип сөйләшү юк. Төбәктә хәзерге көннәргә кадәр сакланып калган таш истәлекләрнең борынгылары Җүчи Олысы чорыныкы икәнен, ягъни инде Болгар дәүләтенең Җүчи Олысы составындагы чорыныкы икәнен искәртү кирәк.

Сөйки белән Мордва Каратае (хәзерге Кама Тамагы районы) арасында «татар зираты» дип атала торган бик зур зират булган, ул Болгар чорыннан килгән зират, Казан ханлыгы чорында да бирегә җирләгәннәр. Тарихчы Г. Әхмәрев Тәтеш төбәге җирләрендә тарихи җирлекләрне өйрәнеп йөргәндә борынгы чорда ук булып, инде ул йөргәндә эзләре генә калган зиратларны да барлый, әлбәттә кайберләренең булуы хакындагы мәгълүматны бары халык хәтере генә саклый. Шундыйлардан, хәзерге Тәтеш районына карый торган Пролей-Каша авылы[2] янындагы зират. Ул караган вакытта сөрү җиренә әйләндерелгән кечерәк кенә курган янында, халык сөйләве буенча, каберлек урыннары сизелеп торган борынгы зират булган, сөрү җиренә әйләндерелү

---

[1] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – 187 б.

[2] Ахмаров Г. Отчет о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // ИОАИЭ при Императорском университете. Т. XXVI. Вып.4. – Казань: Типография Императорского университета, 1910. – С. 398–408.

сәбәпле инде бу урында зиратны абайлау да авыр була. Өрем авылы янында да зур зиратның булуы хакында да мәгълүмат бар, Г. Әхмәрев караганда инде бу зиратның төсмерләре генә калган була, шулай да аңа кисәкләргә ватылган бер ташны бераз җыештырып куфи язулы өлешен укый ала. Бу зират турында Х. Фәезханов, И. А. Износков, Е. Т. Соловьев хезмәтләре дә хәбәр итә[3].

Салтыган авылы каберлегендә өч тарихи таш сакланып калган, шуларның икесе –1309 һәм 1325 елларга карый. Болгар чоры каберлекләре Шәмбалыкчы авылында да булган, алар 1961 елда Һ. Йосыпов тарафыннан өйрәнелде, Кече Бола елгасы буендагы Байтирәк авылындагы борынгы каберлекләргә Ш. Мәрҗани дә игътибар итә, аннан бу җирлек Н. И. Золотницкий, Һ. Йосыпов тарафыннан каралган. Ш. Мәрҗани Тау ягындагы Байтирәк – чуаш авылы янында да борынгы таш булуы хакында: «ул авылның чиркәве янында түбән ягы сынып төшкән таш бар – озынлыгы биш чирек кадәр, ә киңлеге бер аршыннан бер илле ярымга кимрәк. Ул ташның икенче кисәге икенче бер урында ята. Болгар ташларындагы кебек, куфи һәм нәсех язулары аралаштырып язылган». Аның текстын да бирә: «Әл-хөкме лиллаһил-галиилкәбир. Юныс улы Хаҗи бәлүке (билгеле) рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән, вафат бәлкәви тарих җият җүр җирем җити җал сәвер аех җирем биш көн ите»[4]. Х. Фәезханов бу авылдагы ташларның барысын да барлап, тәфсилләбрәк карауга ирешә. Аны ташларны карарга дусты – Әлки (хәзерге Буа районы) мулласы Баһаветдин хәзрәт алып бара. Авыл побы Иван Васильевич Васильковның рөхсәте белән чиркәү ишек алдындагы сынган ташны карый, бу таш нәкъ менә Ш. Мәрҗани тасвирланан таш, әмма аның ахыргы өлеше Х. Фәезханов караганда, беренче өлешеннән аерылып, мәхәллә пономаренең капкасы янында бусагага салынган була. Галим тасвирлавынча, ташның озынлыгы биш чирек [чирек – 17,775 см], киңлеге бер вершок [4,4 см]. Уеп язылган язу, почеркы белән Болгар чоры ташларына хас булганча, нәсех белән куфи арасында. Х. Фәезханов чиркәү тирәсендә тагын да Болгар чоры[5] ташларының барлыгын күрә, чиркәү каравылчысы өенең нигезенә салынган ташның язуын да укый. Калкытып язылган сөлес язулы таш, әлбәттә тулысынча сакланмаган, шулай да бу ташның икенче өлешенә охшаган өлеш тә шул территориядә табыла. Чиркәү рухание бу ташның асыл урыны монда түгел, ә алар башка җирдән китерелгәннәр, дип җавап бирә[6].

---

[3] Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во,1975. – 217 с.

[4] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б.75–76.

[5] Автор шулай яза.

[6] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.258.




Олы Әтрәчнең борынгы ziратындагы кабер ташлары

Ш. Мәрҗани Олы Яльчек исемле чуаш авылының басуында да каберлек барлыгын яза. Шулай ук бер таш куфи һәм нәсех язулары белән аралаштырып, чокып язылган, аның тексты: «Һуәл-хәййе әлләзи ля ямүт. Салавыш углы Муса углы Бәйрәм Хаҗи углы Биккенә», дип укыла. Бу урынны һәм бу ташны соңрак Х. Фәезханов та Әлки авылының Баһаветдин хәзрәт белән барып карыйлар, аның хезмәтендә инде аның тексты Ш. Мәрҗани укыганнан кечерәк, чөнки галим язуынча, бу таш бөтен түгел, ахыры юк. Текст укылышында да бераз аермалыклар бар: «һу әл-хәййе әлләзи лә йәмүт Шылауыш улы Муса угылы Бәйрәм хаҗи угылы …». Х. Фәезханов: «ахыргы сүз бик аерылмады. Ике ягында да язулары булганлыгы күренә, ләкин бик кырылган. Фәкать бер сүзне укыдым «камуг [бары]», дип яза. Таш бик зур, калын булган «сахрада ярдәмче булмаганлыктан, бер юлдаш муллам белән генә күтәрә алмадым»[7], ди. Галим фикеренчә, бу таш торган урын Байтирәк авылының ziраты булырга тиеш, чөнки элекке заманнан ук ziратларны авылдан якынча бер чакырым ераклыкта билгели торган булганнар.

Колгына, Кошта авылы, Олы Фролово, Олы Шәмәк авылы, Бәки авылы, Олы Кариле һәм Кече Кариле, Салтыган, Ишим (Кама Тамагы районы) авылы ziратларында да Җүчи Олысы чоры кабер ташлары булган. Алар XX гасырның 40–60 елларында Фәннәр академиясенең Казан бүлеге үткәргән экспедицияләр вакытында тикшерелгәннәр[8]. С.М. Шпилевский Н. И. Золотницкийга чуаш укытучысы биргән мәгълүматларга таянып, Колгына авылы ziратында

[7] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.258.

[8] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С.167–188.

10 таш булуын хәбәр итә. Халык бу зиратта татарлар руслар белән сугышкан вакытта шәһит киткән гаскәр җитәкчеләре җирләнгән дигән фикердә. Күрше Коштаулы авылы кешеләре еш кына бу каберләрне зыярәт иткәннәр, килеп Коръән укыганнар[9].

Колгына авылыннан көнбатышка таба 2 чакырым читтәрәк Коштаулы авылы янында борынгы зират булган. С. М. Шпилевский язуынча, Г. Доброхотов Коштаулы авылы янындагы Хан тавында булып, шундагы борынгы зират урынына килә[10]. Ул зиратның урыны инде туфрак белән капланып, беленер-беленмәс хәлгә килгәнен күрә. Шулай ук җирле халык телендә татарларның руслар белән сугышкан вакытында шәһит булган татарлар җирләнгән, дип сөйләнә. Г. Доброхотовны озатып йөргән Коштаулы авылы мулласы аңа монда төрле әйберләр табылуы хакында сөйли, шунда табылган бөҗрасыман әйберләрне җирле татарлар күз тиюдән саклый дип ышанып балаларының киемнәренә тегеп куя торган булганнар, мулла баласының да түбәтәенә шушы җирлектән табылган балдаксыман предмет әлеге максаттан беркетелгән була. Борынгы зираттан көнчыгыштарак булган тау өстеннән, мулла аңлатуынча, сугыш вакытында татар ханы үзенең әмерләрен биреп торган. Шуңа да бу тауны Хан тавы дип атаганнар[11].

Тәтеш өязенә кергән Пролей-Каша авылы зираты тарихчы Г. Әхмәрев тарафыннан 1910 елда тикшерелә[12]. Моннан кала, галим фикеренчә, Өрем авылы (Тәтеш районы) янында болгар чорына карый торган зур зират булган. Ул бу урынны караганда инде зиратның хәле шактый начар хәлдә, ул инде сөрү җирлегенә әйләнгән була, ә сынган, ватылган ташларның сөрелгән җир кисәгендә бер өемгә өеп куелганлыгын күрә. Галим кисәкләрне җыеп, куфи язуындагы берничә сүзне укый ала. Бу зират турында Х. Фәезханов, И. А. Износков, Е.Т.Соловьев хезмәтләрендә искә алына[13]. Х. Фәезханов Тау ягында болгар чорына караган өч борынгы кабер ташы сакланып калуы турында ишетә. 1862 елның җәендә аларны өйрәнү нәтиҗәсе буларак «Три надгробных булгарских надписи» дип аталган тикшерү хезмәте тәкъдим итә. Шуларның берсе – мордва авылы Өрем янында кыр уртасында ятучы кабер ташы. Аның тасвирлавы буенча, ташның биеклеге ике аршын. Янында яткан вак таш кисәкләре шактый булса да, аларның язулары юк. Ташның саклану

[9] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 496.

[10] Шунда ук.

[11] Шунда ук.

[12] Ахмаров Г. Отчет о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // ИОАИЭ, 1910. – Т.XXVI. – Вып.4. – С. 398–408.

[13] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во,1975. – 217 с.

халәтен Х. Фәезханов «бик яхшы» дип бәяли. Галим үз хезмәтендә бу ташның тулы язмасын да да, шәрехләмәсен дә бирә[14].

«Тәтеш өязенең Карабай карьясе белән Сәүтек карьясе арасында бер зур иске зират бар, кабер өстендә уеп-уеп куелган ташлары да бик күп, ләкин язулысы юк, бу зират соңрак заманда гына ташланган булса кирәк, каберләрнең каю тарафка таба каратып казылганы да беленеп тора. Ислам зираты икәне бик мәгълүм – кабер өсләре күбесенчә чокырланыбрак тора, ихатасы юк, уртасыннан юл йөри, шул кабер өсләреннән үтеп бәгъзе каберләрнең чокырына арба көпчәкләре төшеп-төшеп китә, кабер әйләнәсендә уеп куелган ташлар өстеннән менеп уза»[15]. XX йөз башында ук шундый хәлдә булган зиратның хәзерге вакытта эзе дә калмаганлыгы инде аңлашыла. «Шул ике авылның мөселманнары шулкадәр илтифатсыз: ата-бабаларының мөкаддәс зиратларын шул дәрәҗәдә тоталар. Ике авылга дүрт мулласы бар, дүртесе дә картлар, бу юлны аз гына читтәнрәк җибәрергә, әлбәттә, бик мөмкин, ихата тотып куярга хәлләре булмаса, канау казып әйләндерергә мөмкин, моңар акча чыкмый, халык бушрак вакытта бөтен авыл кешесе чыгып, бер көндә казып, әйләндерәчәкләр, имамнар тарафыннан илтифат кына кирәк»[16]. XX йөз башында, дини атрибутикага сак караган чорда ук, тарихи истәлекләргә карата булган игътибарсызлык мирасның югалуына китерә.

Г. Әхмәрев Җанбакты авылының чиркәү ишеге төбенә түшәлгән ике язулы ташка тап була. Шуның берсенең язуын күчереп тә ала, ул аны «665 ел мөкаддәм [элек] язылган», дип вакытын билгели. Галимгә Каратун авылында очраган гарәп язулы таш та, аның фикеренчә, борынгы Болгар җирлеге – Әтрәч зиратыннан китерелгән булса кирәк[17].

Борынгы кабер ташлары табылган урыннарда каберлекләр булган дип уйлау һәрвакытта да дөрес түгел. Болгар дәүләтендә хәлле, бай кешеләргә куелган зур, нык ташлар төзү материалы буларак төрле җиргә таралганнар. Аларның чиркәү нигезләренә салынуы да, юл түшәгәндә кулланулары да ачыклана. Х. Фәезханов, хәтта татар авылында табылган борынгы ташны да аны әлеге җирлектәге итеп кабул итү ялгышлыгына мисал китерә. Тәтеш өязе Аксу авылында (Буа районы) булганда Болгар чоры ташына тап булып, аның тарихы белән кызыксына. Бу ташны чуаш кешесе үзенең ишек төбенә баскыч итеп салыр өчен кайдандыр китертә, бу таш Шонгаты зираты ташы булуы ихтимал, әмма бу ташны ишек төбенә түшәгәч, йортка килгән кайгы-хәсрәттән соң, шул таштан күреп, чыгарып ташлый. Аксу авылының мөселманы

---

[14] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.307–310.

[15] Әхмәрев Г. Иске зиратлар хакында // Азат. – 1906. – 30 март.

[16] Шунда ук.

[17] Шунда ук.

моны күреп, бу ташны атасының кабере өстенә куярга ниятләп алып кайта. Х. Фәезханов караганда ул аның ишегалды тора торган була[18].

Г. Әхмәрев Тәтеш шәһәрендә дә чиркәү салганда бер зират ташы табылуы хакында яза. Бу таш Тәтеш җирлегенең үзенеке булганмы, яисә чиркәү нигезенә түшәү өчен башка урыннан китерелгәнме – билгесез. Бу ташны күргән Гайнетдин Әхмәрев «өстеннән арба юлы йөреп, бу таш урталай сынган, шул сәбәпле ахыргы өч сүзе танырлык түгел. Бу сүзләрне калган берничә хәрефләрен карап кына шулай булырга кирәк дип, үзебезчә уйлап язып куйдык (алары бәлки безнеңчә дә түгелдер)»[19]. Тексты бу рәвешчә «Әлхөкме Аллаһы әл-гали әл-кәбир Галәйе Аллаһы әүвәл гасый рәхмәтуллаһи галәйһи вә рәхмәтән васыйгатән вафат ... тарихе җийат җур (әз һиҗрәти газыйм...)»[20]. Г. Әхмәрев бу таш хакында Казан университеты каршында эшләүче Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә да хәбәр итә, алар килеп тә карыйлар. Ташны полиция участогына китереп, койма буена язулы ягы белән өске якка таба каратып салганнар. Полиция участогында кадерсезләнгән бу ташны Археология, тарих һәм этнография җәмгыятеннән рөхсәт сорап, Тәтеш мәчетенең бер бүлмәсенә китереп кую хәстәре артыннан йөри, Тәтеш мулласы исеменә рөхсәт алуга да ирешә. Фәнни тикшерү өчен караучыларга киртә тудырмау шарты белән эшләнә. Г. Әхмәрев бу хәл турында: «Тәтешнең исправнигыннан сорадык: «Ул ташны алсак, сүз әйтүче булмасмы», – дип. Исправник холыксыз нәрсә иде, язуымны укып карагач, тынычсызлана башлады: «Кайда ул, нинди таш», – дип сорашып, безгә – «губернатордан сораңыз», – дип алырга рөхсәт ителмәде, үзе шул көндә үк мәзкүр ташны полицийскийларны кушып, эзләтеп алдырган да, полициягә китереп, бер утын амбарына куйдырган, хәзердә кайдадыр, мәгълүм түгел. Шул 600 еллар мөкаддәм (хатты куфи белән) аяте Кәримә язылган ташны хәзердә эзләнеп алынса, яхшы булыр иде»[21].

Идел алды регионында Болгар тарихының соңгы чорына караган археологик истәлекләр тупланган үзәк – Үләмә һәм Коры Үләмә елгалары бассейны. Галимнәр шушы регионда 50 ләп Алтын Урда истәлекләре булу хакында әйтәләр. Шундыйлардан, алар билгеләвенчә, аерым игътибарга лаеклысы – Олы Әтрәч авылы зираты. Әтрәч авылы җирлеге һәм шул исәптән, аның борынгы зираты 1884 елда Е. Т. Соловьев, 1943 елда Ә. Булатов, 1949 елда Н. Ф. Калинин, 1961 елда Һ. Йосыпов, 1970 елда Фәннәр академиясе экспедицияләре тикшерә[22]. Борынгы каберлекләр Олы Әтрәч авылыннан

[18] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.258.

[19] Әхмәрев Г. Иске зиратлар хакында // Азат. – 1906. – 30 март.

[20] Шунда ук.

[21] Шунда ук.

[22] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С.180.

көнчыгышка таба 0,3 чакырым ераклыкта урнашкан, 7600 кв. м территорияне биләгән. Борынгы Болгар заманы зиратлары күп булса да, сакланып калганнар арасында бу зират территориясе ягыннан иң зурысы һәм иң уникале. Әхмәд Булатов фикеренчә, бу зиратта 1000 гә якын кеше җирләнгән булырга тиеш.

Борынгы Шонгаты җирләре булган урыннар – Әтрәч авылы янындагы борынгы каберлекләр халыкта изге урын буларак кабул ителгән. Халык аны шулай «Изгеләр зираты», дип атап та йөрткән. Дога кылу өчен дә, яисә кайгы-хәсрәтләре булганда да, авырулардан сихәтләнү өмете белән дә халык бу урыннарга килә торган булган. Тәтеш шәһәренә укытучы итеп билгеләнгән Г. Әхмәрев бу төбәктә эшләгән елларында Тау ягындагы каберлекләрне, борынгы тарихи урыннарны өйрәнә. Аның төбәк тарихы белән фәнни кызыксынуы нәкъ менә шушы елларда башлана. Халык белән аралаша, аларның хатирәләрендә булганнарны язып ала, Әтрәч халкы аңа ике Әтрәч авылының (Зур һәм Кече Әтрәч авыллары) кешеләре Болгар шәһәре Шонгатыдан күчеп утырганнарның нәсел дәвамчылары булуларын сөйлиләр. Бу шәһәрнең халкы болгарлар белән (ягъни пайтәхетләре булган Болгар шәһәренең мөселманнары белән) кыз алышып, кыз бирешеп йөргәннәр. Шунда шәһре Болгарга йөргән туры юлларын да күрсәтәләр. Зиратлары янында күп болгар нәрсәләре табыла, хосусан «әзгәри» дип атала торган Болгар тәңкәләре, элегрәк, Болгар заманында, акча урынына йөртелгән көмеш кисәкләре дә күп табылган, дип яза тарихчы[23]. Гайнетдин Әхмәрев Әтрәч зиратындагы ташларга карап, һәм дә халык хәтерен исәпкә алып, биредә авыл түгел, ә Болгар шәһәре булган булырга тиеш, дип фараз итә. Аның фикеренчә, авыл кешеләре генә бу кадәр алты йөз елларга түзәрлек зур вә яхшы ташларны куя алмас иде. Шул ук вакытта ул авыл халкын тәнкыйть утына тота, мондый ташларга, зиратка авыл халкының мөнәсәбәте, битарафлыгы борчый аны.

XIII–XIV йөзләргә караган эпиграфик истәлекләрне саклаган Әтрәч авылы зираты XIX гасырда ук инде галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Иң беренчеләрдән булып, Ш.Мәрҗани үзенең атаклы «Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенә Әтрәч зыяратындагы кайбер ташларның язмаларын кертә. 1863 елда Мәрҗани бу авыл зыяратында булып, болгар чорына караган 21 кабер ташын барлый. XIX йөз башында аларның саны 50 ләп булган. Ш. Мәрҗани шәкерте, галим Х. Фәезханов караганда да зиратта 21 таш торган әле. Ул күргәндә «бер-берсеннән бер сажиннан ун сажинга кадәр арада һәм ераклыкта торалар»[24], дип яза.

---

[23] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 30–75.

[24] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.260.

Ш. Мәрҗани билгеләвенчә, бу ташлар 1302, 1303, 1314, 1323, 1324, 1346 елларда вафат булган кешеләрнең каберләренә куелган. Халык сүзләре буенча, мондый ташлар биредә күп булган. «Моннан җитмеш еллар элек Өтрәчтән биш чакырым көньяктарак урнашкан Җанбакты исемле рус авылы алпавыты шул авылга чиркәү салдырганда, нигезенә таш кирәк булгач, шундагы тигез ташларны кулай табып, мөселманнарның олылап хөрмәт иткән ташларыннан егерме-утызлабын агач чиркәүнең нигезенә куйдырган». Бу сүзләренә дәлил итеп инде яше 80 нән узган карт мөәззиннең күңелендә калган тетрәндергеч сүзләре: «Мин бала чагымда атам белән шушы авылга йомыш белән барганда ул ташларны төзәтеп куйганнарын карап тордым. Атам елап: «Менә, балам, безнең авылыбыздагы газизләрнең каберләре өстендәге ташларны чиркәү бусагасына куялар», – дип әйтте»[25].

Бу авыл зиратына 1905 елда килгән Гайнетдин Әхмәрев 22 кабер ташы саный. 1949 елдагы тикшерүчеләр шулай ук 22 кабер ташын күрсәтә, ә инде Һ. Йосыпов өйрәнгәндә анда бары тик 16 кабер ташы була, ә хәзерге вакытта аларның саны бары тик 7. Өтрәч авылының «Изгеләр каберлеге»ндә үзәктәге җиде зират курган рәвешендә ясалган булган, әмма инде алар хәзерге вакытта җиргә иңеп беткән.

Саннарның шулай кимүенең сәбәбе төрле: беренчедән, Ш.Мәрҗани тарафыннан сөйләнгән, кабер ташларын рус авылларына алып китеп чиркәү төзелешендә, хуҗалыкта кулланылуы. Җирле халык әле ташларның Апас-Тәтеш юлына түшәлгәнен дә хәтерли. Бу хакта моның шаһите булган Гайнетдин Әхмәрев тә яза, ул язулы борынгы кабер ташларын Җанбакты чиркәүве нигезендә, Каратун авылында юлга түшәлгән хәлдә күрә. Икенчедән, җирле халыкның битараф мөнәсәбәте. 1906 елда «Азат» газетасында дөнья күргән «Иске зиратлар хакында» дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Һәр милләт – нәсараи [христиан] булсын, яһүд булсын, хәтта мәҗүс таифәләре дә, ата-бабаларының зиратларын мөкаддәс санап, мөмкин кадәр тәрбияле тоталар, мондаен эшләр дине исламда хосусан мактаулы булса да, вилайәтебезнең мөселманнары иске зиратларын бик тәрбиясез, кызганыч хәлдә тоталар». Мисал итеп, башкалар белән беррәттән иң беренче итеп Өтрәч авылы зиратын китерә: «...шунда алты йөз еллар мөкаддәм куелган (20–25 кадәр) язулы ташлар да бар. Ихатасы юк, ташларның бәгъзеләре авып ята, бәгъзеләре сынгалап, берничә еллар мөкаддәм араларын сукалап, иген дә чәчкәннәр иде, шул сәбәпле бер баруыбызда бәгъзе ташларны күрер өчен иген арасыннан эзләп таптык, икенче мәртәбә баруыбызда такыр басу иде. Шул зират өстендә Өтрәч карьясенең сыер-сарык көтүе йөргәнен күрдек, бәгъзе хайваннар ташлар арасына ятканнар, бәгъзеләре ташка ышкылып торалар. Хайван йөргән сәбәпле, зират өстендә тирес тә күрелде. Шунда бер көтүчедән сора-

---

[25] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1989. – Б.75–76.

дык: «Ник болай хайван йөртеп, зиратны кадерсез итәсез?» – дип. Йөртәбез шул инде, йөртмә дип әйтүче дә юк», – дип җавап бирде. Дәхи зыярат кылырга килүчеләр хакында сораштык. «Килүчеләр була, кичә дә бер пар ат белән килеп, Коръән укып киттеләр, ләкин белеп булмый, әллә кеше, әллә фәрештәләр булды – Ходай белсен. Мин сезне дә танымыймын, миңа сез дә әллә кем», – диде. Бу ташлар элегрәк бик күп булган имеш, ләкин мөселманнарның илтифатсызлыгыннан күбесен якындагы урыслар урлап ташыган, диләр. «Мондаен әсәрләрне [тарихи һәйкәлләрне] мәгърифәтле милләтләр бик саклыйлар, безгә дә сакласак, бәлки киләчәк заманда бераз файда булыр иде»[26].

Җанбакты авылындагы Әтрәч ташының һәм дә Әтрәч зиратындагы тагын бер ташның күчермәсен ул үзенең атаклы «Болгар тарихы» дигән хезмәтенә кертә.

Болгарда табылган 1316 елга карый торган куфи язулы ташъязмада да Әтрәч авылы белән бәйлелек бар, бу таш Әтрәч бабайның кызы Әлкискә куелган. Үлчәмнәре 22x54x182 см. булган әлеге таш хәзерге вакытта Мәскәүдә Дәүләт тарихи музей экспозиция залында саклана[27].

Ш. Мәрҗани 21 таш булуы хакында язган, әмма 1943 елга бары тик 14 ташның гына язуы укырлык дәрәҗәдә була, яңгыр, кар астында торган таш истәлекләр инде үз сыйфатын ел саен җуя баралар. Укырлык булган 14 таш барысы да куфи язуы белән язылган. Тел ягыннан килгәндә, бу каберташ язмаларының теле фәндә «икенче стиль» – «чуашизм элементлары» белән язылган. XIV гасырның беренче яртысына караган бу ташларның теле – хәзерге татар теленең борынгы болгар чорындагы кулланышы, бередә чуаш элементлары булу – ул ташъязмаларның хәзерге чуаш теленә мөнәсәбәте хакында сөйләми, алар арасында аермалар зур. Бу тел – әлеге чорда бу җирлектә кулланылган тел. Әлбәттә тел һәрвакыт үсештә, үзгәрештә һәм камилләшүдә.

1964–1971 елларда Әтрәч авылында каберлек өсте ачыла, аларның берсе ир кешенеке, ә икенчесе хатын-кыз каберлеге була. Моны күргән картлар сөйләве буенча, суган кабыгына төреп мумияләштерелгән кабер ияләре яхшы сакланган. Аларның чәчләре аксыл, кул чуклары тездән түбән булуга игътибар итәләр. Бу – шул чорда яшәгән җирле халыкка хас булган кыяфәт.

Әтрәчнең «Изге зираты» галимнәр тарафыннан соңгы елларда да тикшерелде, әмма ул инде территориясе ягыннан элекке чор белән чагыштырганда бик нык кечерәйгән. Күп җирләре басу составына кереп киткән. XIX гасырда ук бу җирләр керәшен булып язылганнарга бирелгән, аны сөрү

---

[26] Әхмәрев Г. Иске зиратлар хакында // Азат. – 1906 – 30 март.

[27] Татарская эпиграфическая традиция. Т. 1: булгарские эпиграфические памятники XIII–XIV вв. Кн. 1. /Авт.-сост.: И.Г. Гумеров, А. М. Ахунов, В. М. Усманов. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2021. – С. 61.

җире иткәннәр, дип сөйлиләр. 9 гектар җир биләгән зиратның сакланып калган өлеше бары тик хәзерге вакытта 0,93 гектар зурлыгында гына. Татарның күренекле драматургы Туфан Миңнуллин, аның энесе Альберт Миңнуллин ярдәме һәм Әтрәч халкын оештырган Мөнир Вәлиев, авыл халкы ясаган өмә белән бу зират тәртипкә китерелде, сакланып калган ташлар төзәтелеп, зират тимер койма белән әйләндереп алынды. «Шонгаты» оешмасының активистлары, тарих өчен, тарихи һәйкәлләрнең язмышы өчен янып торган кешеләр тырышлыгы белән ел саен бу каберлекләрдә ятучы ата-бабалар рухына дога укыла, корбан чалына. Галимнәрне, тарих белән кызыксынучыларны, җәмәгать эшлеклеләрен җыеп «Әтрәч укулары» дигән халык җыенында фәнни чыгышлар тыңлана[28].

Еш кына авыл зиратыннан читтә җирләнгән каберлекләр очратырга туры килә, күп очракта аны җирле халык «Изгеләр кабере» дип атарга күнеккән, гомумән, борынгы булган әйберләрне «изгеләр» рәтенә кертү гадәте бар. Дәүләки-Дәүеш (Апас районы) авылы арасындагы юл буенда Мәмәт бабай кабере бар, бу каберлекне җирле халык борынгы дип сөйли, кабер иясенең бакыйлык вакыты 1640 елга карый. Халык риваятьләре буенча, бабай Болгар хәрабәләренә зыярәт итеп кайткан вакытта вафат була. Чит җирдән килгән кешене, гадәттә авыл зиратына җирләмәгәннәр. Бу ялгыз каберлекне авыл кешеләре хәзерге вакытка кадәр тәрбияләп, карап торалар. Мәмәт бабай кабере янына 1992 елда төзү эшләре вакытында табылган борынгы чорга караган кеше сөякләре дә җирләнә. Галимнәр билгеләвенчә, бу сөяк калдыклары болгар сугышчылары, яшь кешеләрнеке булырга тиеш, шунда ук аларның тимер кылычлары да табылган.

Тәтеш районы җирләрендә борынгы кабер ташлары шактый сакланган булса да, Тәтеш өязенең хәзерге Апас районына карый торган өлешендә борынгы кабер ташлары күп түгел, бу да үз чиратында, бу җирләрнең үзләштерелү чоры Тәтеш төбәгенә караганда соңрак булуына бер дәлил була ала. Шундый 3 таш – Колгана, 1 таш – Шәмбалыкчы зиратында, алар Җүчи Олысының соңгы чорына – 1333/1334 елларга карый. Гарәп хәрефләре белән каллиграфик ысул белән язылган, безнең көннәргә килеп җиткән ташлар XIX йөз ахыры – XX йөз башы белән чикләнә. Андый ташлар Иске Энәле, Чатбаш, Танай Турай, Дәүләки, Апас зиратларында бар. Төбәкче М. Юнысов сүзләренә караганда, 1950 нче еллар уртасына кадәр Апас зиратында гарәп язулы ташъязма булган, галимнәр билгеләвенчә, ул 1450 нче елларга караган. Ул ташны Апас мәктәбе музеена күчереп куялар, ташның аннан соңгы язмышы билгеле түгел[29].

[28] Сәлахова Э. К. Күркәм җирнең асыл улы // Шәһри Казан. – 2017. – 23 июнь.

[29] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, – 2013. – С. 129–130.

Тәтеш өязенә караган җирләр тарихи әһәмияткә ия, бу фикерне башка тарихи чыганаклар белән беррәттән эпиграфик истәлекләр дәлилли. Кызганычка каршы, бу төбәкнең эпиграфик истәлекләрен туплаган махсус каталоглар эшләнмәгән, әмма шулай булса да, аерым хезмәтләрдә алар хакында мәгълүмат саклнаган, җирле халык арасыннан төбәк тарихын өйрәнеп, бу истәлекләрне тәрбияләп торучылар булу – аларның тарихи гомерләре озын булуына өмет бирә.

Тәтеш төбәге Идел буе тарихының мөһим тарихи җирләре булуы – югарыда аталган чыганаклар белән раслана. Кызганычка каршы, Идел буе Болгар дәүләте тарихын өйрәнгәндә Иделнең уңъяк яры хакындагы мәгълүматка тиешле игътибар бирелми. Шунлыктан, Идел буендагы Болгар дәүләте берьяклы, тулы булмаган хәлдә тәкъдим ителә. Әлеге тикшерү хезмәте бу бушлыкны тутыру, бу хилафлыкны бетерү юлында бер адым буларак үз бурычын үтәр дигән өмет белдерәбез.

# II бүлек

# ТӘТЕШ ТӨБӘГЕ АВЫЛЛАРЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ

## § 1. Татар авылларының икътисадый халәте һәм социаль каршылыклар

Казан губернасы гасырлар дәвамында җир эшкәртүчеләр, игенчеләр төбәге булган. Бу аның географик шартлары белән дә, шул ук вакытта тарихи традицияләре белән дә бәйле. Табигате иген игү өчен уңайлы, туфрагы уңдырышлы. Тәтеш өязе кара туфрагы белән аерылып тора торган төбәк. Терлекчелек Казан губернасы халкы тормышында игенчелек белән һәрвакыт беррәттән барса да, ул беренче планга чыкмаган, ә бер-берсен тулыландыручы тармак булып хезмәт иткән. Шуңа күрә дә, бередә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсе табигать шартларына турыдан-туры бәйле булган. Иген уңмаган еллар халык өчен бар яклап та авыр була, әмма бу вакытта башка өстәмә шөгыльләр аша хәлләрен җиңеләйтү юлларын тапканнар. Игенчелек эше туктап торган кышкы вакытта һөнәрчелек эшенә мөмкинлек чыккан. Беренчедән, һөнәрчелек иген игү эшенә, яисә хуҗалык алып баруга кирәк-ярак ясау белән бәйле булса, икенчедән, кайбер кешеләр үз һөнәрләре белән төрле якларга чыгып китеп хезмәт иткәннәр. Вакытлыча читкә китеп эшләү дә татар игенчеләре арасында бик еш очрый. Кайбер крестьяннар өчен читкә китеп, вакытлыча хезмәт итү даими хезмәткә дә әйләнгән. Соңрак алар крестьянлыктан эшче сыйныфына күчкәннәр.

Крестьяннарның авыр тормышына, аларның җир кишәрлекләре тамак туйдырырлык та мөмкинлек бирмәүләренә игътибар итеп, бу мәсьәләнең көн проблемасы булуын тарихчы Г. Әхмәрев 1906 елда «Казан мөхбире» газетасында басылган «Мөселманнарның җир мәсьәләсе» мәкаләсендә тасвирлый. Әлбәттә аны, беренче чиратта, мөселманнарның хәле борчый. Россиядә үткәреләсе реформалар да крестьяннар файдасына булмавы алдан ук билгеле була. Автор: «Милләтебезне алга җибәрү өчен әүвәл крестьян булган мөселманнарның тереклеген төзәтү кирәк була»[1], дип яза. Г. Әхмәрев күзәтүенчә, мө-

[1] Әхмәрев Г. Мөселманнарның җир мәсьәләсе // Казан мөхбире. – 1906. – 6, 30 гыйнвар, 1 февраль.

селман крестьяннарының җир кишәрлеге башка крестьяннарга караганда кечерәк булган. Моннан кала, тарихчы авыл җирендә татар крестьяннарының игътибарны бары тик җир эшенә генә юнәлтү ялгышлык дип исәпли, татар крестьяннары тормышындагы авырлыкларны ул аларның өстәмә һөнәр белмәүләре белән дә аңлата[2]. Крестьян хуҗалыгының уңыш алу мөмкинлеге аның аты булу-булмауга да бәйле, чөнки ул хуҗалыкта төп көч. Казан губернасында XIX йөзнең 80 нче елларында бер атлы, яисә, бөтенләй атсыз булган хуҗалыклар 70 % тәшкил иткән.

XIX гасыр уртасында Тәтеш өязенең 173,702 дисәтинә сөрү җире була, бу – җан башына 3,3 дисәтинә җир туры килгән дигән сүз. Тәтешлеләр 26,063 дисәтинә болынлыклар биләгәннәр[3]. Тәтеш өязе җирләренең 80 %ы дәүләт милкендәге җирләр, 14,5 % җирләргә алпавытлар хуҗа булган, 0,3 %ы удел җирләре, 4,5 %ы шәхси милек җирләре булып саналган[4]. Бу вакытта Тәтеш өязендә 10 нчы ревизия мәгълүматлары буенча 57316 ир кеше гомер кичергән.

XX йөз башында исә Тәтеш өязе буенча 49742 ир-ат, 52174 хатын-кыз дәүләт крестьяннары исәбендә булса, 32513 е шәхси хуҗалык тоткан, 1920 се җир кишәрлекләрен арендага биреп көн күргән, Тәтеш өязендә 62 кеше ирекле җир эшкәртүчеләр исәбендә саналган[5]. Ир-атларга җан башына якынча 2,5 дисәтинә җир туры килгән.

XX йөз башы мәгълүматлары буенча, Тәтеш өязе Әлки, Олы Кариле, Богородский, Олы Таяба, Олы Фролово, Олы Шәмәк, Олы Яңасала, Шонгат, Красно-Пролянский, Никифирово, Пролей-Каша, Урта Балтай, Иске Барыш, Яңа Шимкус, Сөйки, Черки-Килдураз, Шәмбалыкчы волостьларына кергән авылларда, нигездә, дәүләт крестьяннары яшәгән. Шул ук вакытта Богородицкий волостенда ирекле җир эшкәртүчеләр, элекке җир биләүчеләр, Красно-Полянский волостенда җирбиләүчеләр, удельный крестьяннар, Никифирово волосте крестьяннарының, Олы һәм Кече Әтрәч авылы дәүләт крестьяннарыннан кала, барысы да элек алпавыт милкендә булган (владельческие) крестьяннар, Пролей-Каша волостенда 284,4 дисәтинә җирне эшкәртүче крестьяннар[6] (удельные крестьяне) булганнар[7]. Тәтеш өязендә җирендә элек-

---

[2] Әхмәрев Г. Авыл җирендә мөселманнарның тереклеге // Казан мөхбире. – 1906. – 6 февраль.

[3] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 56–64.

[4] Материалы географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. Т. 8. Казанская губерния /Сост. М. Лаптев. СПБ.: Военная типография, 1861. – С. 29.

[5] Крестьянское землевладение Казанской губернии. Вып. 4. Тетюшский уезд. – Казань: Типо-литография И. В. Ермолаевой, 1907. – С. 68.

[6] Император гаиләсе милкендә булган җирләрдә эшләүче авыл халкының феодаль бәйле катламы.

ке морзалар да яшәгән, җирбиләүчеләр дә булган. Шундыйлардан, Келәнче авылы янында 17 хуҗалык морзаларга караган, әмма аларның җир биләмәләре булмаган. Олы Таяба волостенда Тихоновның 86,6 дисәтинә, Крамерның – 310 дисәтинә чәчүлек җирләре булган, Олы Фролово волосте Ракитовка янында 20,1, Аннеково, Никольский – 532, Кырлангы авылы янында – 230,1 дисәтинә җирләр шәхси милектә була. Иске Барыш волостена караган Тарловка, Чернышевка, Ивановка җирләре дә, Сөйки волостендагы Долгая Полянада, Черки-Килдураз волосте Кара Борнаш, Петровское, Шәмбалыкчы волостенда аерым хуҗаларның шәхси җир милекләре булуы билгеле[8].

Мисал өчен, Югары Балтай (Апас районы), Олы Лачшы (Буа районы) авылы янындага буш җирләрнең хуҗасы Долбирдин фамилияле кеше. Ташкичү (Буа районы) авылы янындагы 180,6 дисәтинә җирне Казан мещаннары Габдерәшитовлар, Габделвәли Мөхәммәтев, Фәтхулла Йосыповлар биләгән, коллежский советник Алкин Алексей Михайловичның Морзалар авылы янында, Ракитовка авылы янында Буа сәүдәгәре Авсентьевлар җирләре була. Энәле авылы янындагы 14,5 дисәтинә җир белән Тимербулат һәм Хөснетдин Бәхтияровлар идарә иткән. Болардан кала, Тәтеш өязендә Горымикиннар, Городецкийлар, Сергей Григорьев, Садретдин Хөсәенев, Лидия Черкасова, Гавриловлар, Васильевлар, Сабит Йосыпов, Хәсән Исланов, Кәрим Иксанов, Әлми Гомәрев, Габит Мөхәммәдьяров, Садыйк Нигъмәтуллин, Мөхәммәдәмин Әлмөхәммәтевләр һ.б. җир кишәрлекләре биләгәннәр[9].

Тарихи чыганакларда татар авылының борынгырак чорлары хакында материаллар бик аз сакланган. Борисов һәм Кикин писцовая һәм межа кенәгәләрендә Е. И. Чернышев берничә татар авылы булы хакында яза. 1565–1568 елларда Зөя өязенең 15 авылында йомышлы татарларның утары булуы күрсәтелә. Бу чорда Тәтеш җирләре Зөя өязе составында булуын искәртергә кирәк. Ясаклы авылларның саны 25 булган[10]. XVII гасыр уртасына йомышлы татарлар саны шактый арта. Зур җирбиләүчеләр арасында да татарлар күбәя. Е. И. Чернышев Казан өязе буенча 50 татар җирбиләүче булган дип яза, алар арасында танылган Яушевлар, Асановлар, Еникеевлар һ.б. билгеле[11].

---

[7] Крестьянское землевладение Казанской губернии. Вып. 4. Тетюшский уезд. – Казань: Типо-литография И. В. Ермолаевой, 1907. – С. 2–68.

[8] Шунда ук.

[9] ТР ДА, 244 ф., 1 тасв., 6 эш, 1–75 кгз.

[10] Чернышев Е. И. Татарская деревня 2-й половины XVI и XVII вв. // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. Вып. 4. Материалы Всероссийской научной конференции «Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья (XVI – начало XVII вв.» Круглого стола понятия «чюваш» и «ясачная чюваша» в письменных источниках XVI–XVIII вв. как этническая и социальная страты (г. Казань, 6 декабря 2013 г.), проведенного в рамках данной конференции. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ; изд-во «Яз», 2014. – С. 248.

[11] Шунда ук. – С. 261

1858 елга караган мәгълүматлар буенча, Казан губернасының 478 919 дисәтинә җире алпавытлар милкендә булган, шуның – 202 726 дисәтинәсе сөрү җирләре, 46 102 дисәтинә болынлыклар, 100 931 дисәтинә җирдә төзелешкә яраклы агачлар үсә торган урман, ә Тәтеш өязе буенча 18 825 дисәтинә җир алпавытларныкы, шуның 12 027 дисәтинәсе чәчүгә яраклы җир, 1264 дисәтинә җире болынлыкларга туры килгән[12]. Тәтеш өязендә 20 557 дисәтинә җир алпавыт крестьяннары кулланылуында исәпләнгән[13].

Тәтеш өязе крестьяннарының авыл хуҗалыгы тормышы башка төбәк крестьяннарыннан берни белән дә аерылмаган: бу төбәктә татар, рус, чуаш һәм мордва халкы гомер иткән, хуҗалыклары, нигездә бертөрле булса да, кайберләрендә үз үзенчәлекләре дә бар. Крестьяннар, нигездә, бодай һәм арыш утыртканнар. Арпа белән солыны күбрәк мордва халкы чәчкән, бу бөртеклеләрдән эшләнгән ризыклар алар кухнясында зур өлеш алып торган. Шулай ук борай да ашау өчен кулланылган. Орлыкларның сыйфаты, еш кына, начар булу сәбәпле, көтелгән кадәр үк уңыш җыелмаган да, соңрак вакытта дәүләт крестьяннарына дәүләт сыйфатлырак орлык бирә башлый. Җитен, киндер дә хуҗалыкта чимал буларак кулланылганга крестьяннар аларны да чәчкәннәр, әмма ул, нигездә, чуаш, мариларда күзәтелә.

Казан губернасында сөрү җирләре 3 өлешкә: язгы, көзге чәчүлекләргә һәм ял иттерелә торган җирләргә бүлеп эшләнгән. 1830 елларга караган мәгълүмат буенча, Тәтеш өязендә 124283 чирек – язгы, 190964 чирек икмәк көзге культуралардан җыеп алынган[14]. Әмма икмәк уңдырышы елы елына туры килмәгән. Кайвакытларда уңыш әйбәт булса да, икмәк бөтенләй булмаган еллар да булган. Казан губернасында уңдырышсыз, хәтта халык арасында ачлыкка китергән 1860, 1870, 1873, 1877, 1883 еллар билгеле[15]. Гадәттә уңыш булмаган еллардан соң уңдырышлы еллар килә торган булган.

Бәрәңге утыртуга крестьяннарның мөнәсәбәте тарихта билгеле, бәрәңгегә каршы «бәрәңге бунтлары» да була, шулай булса да, соңрак кырларга бәрәңге дә чәчәләр[16]. Һәр крестьянның бакчасы булса да, бакчачылык белән шөгыльләнү рус булмаган крестьяннарда гомумән, булмый диярлек.

Тормышны алып бару өчен өстәмә эшләр кирәк була. XIX гасырның 50–70 нче елларында мисал өчен, Тәтеш өязе Әлки авылының (Буа районы) 36% халкы алпавыт Филиппов җирләрендә эшләгәннәр, шундый ук хәл Олы Кырлангы (Буа районы) авылында да күзәтелә. Бу авыл крестьяннарының

[12] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 267.

[13] Шунда ук. – С. 272.

[14] Шунда ук. – С. 261.

[15] Смыков Ю. И. Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 г. – Казань, 1959. – С. 9.

[16] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 263.

яртысыннан артыгы (58 %) күршедәге җирбиләүчеләргә 2 дисәтинә җирне 17 сумга эшкәртергә ялланганнар[17].

XIX гасырда Тәтеш өязе крестьяннары алпавытка ялланып эшләгәндә, уртача 13 сум 50 тиен алганнар, ә хатын-кыз хезмәте күпкә арзанрак бәяләнгән – 6 сум 75 тиен[18]. Җирләр арендага бирелгән, кайвакытта килешү арендага вакытыннан берничә ел алдан ук төзелеп куелган. Шәхси милектә булган җирләр буенча Тәтеш өязе Казан губернасы буенча беренче урында торган. 1905 елда дисәтинә 5,5 сум булса, 1911–1923 еллар арасында бу сумма елга 25 сум тәшкил иткән. Аренда бәясе дә Тәтеш, Лаеш, Мамадыш өяләрендә уртача суммадан югарырак йөргән. Мисал өчен, Тәтеш өязендәге Пролей-Каша авылында көз чәчелә торган җир өчен дисәтинәсенә 30 сум, язгы өчен 20 сум сораганнар[19].

Терлекчелек Тәтеш өязендә беренчел роль уйнамаган. 1850 елгы мәгълүматлар буенча, өяздә 31154 ат, 96072 сыер, 1700 сарык, 15080 кәҗә исәпләнелгән. Тәтеш Казан губернасы буенча дуңгыз асрамаган бердән-бер өяз[20].

Казан губернасының төрле өязләрендә дворяннар утарлары булган. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча[21], Тәтеш өязендә 106 дворян исәпләнгән. 1908 елга Казан губернасы дворяннарның 5,2 %ы Тәтеш өязенә туры килгән. Иң күп дворян утарлары Спас, Зөя, Лаеш, Чистай өязләрендә булган[22].Тәтеш өязендә иң атаклы дворян утары – Молостововлар җир биләмәсе. Тамыры татарлардан килә торган бу дворян нәселенә әлеге җирләр XVII йөздә үк бүлеп бирелгән булса да, Тәтеш җиренә алар бары XVIII йөздә килеп төпләнә. Биләмәләр озак еллар буе буш җир булып ята, бары тик 1903 елда Владимир Молостовов (1859–1918) әлеге җирләрендә нәселләренең «оя»сын булдыра. Хәзерге вакытта да Тәтеш районына карый торган Долгая Поляна янындагы бу утар Татарстанның иң матур җирләре рәтендә[23].

*Бакчачылык.* Тау ягы үзенең җиләк-җимеш бакчалары белән дә данлыклы. Тәтеш, Зөя, Чабаксар, Козмодемьянск өязләрендә, нигездә алма бакчалары булган, кайбер урыннарда чия, армуд (груша), кара җимеш (слива)

---

[17] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 267.

[18] Шунда ук. – С. LI

[19] Ионенко И. М. Крестьянство Среднего Поволжья накануне Великого Октября по материалам Казанской губернии). – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – С. 35.

[20] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 67.

[21] Список селений Казанской губернии. Вып. 7. Тетюшский уезд. – Казань: Литотипография И. Н. Харитонова, 1910. – 23 с.

[22] Ионенко И. М. Крестьянство Среднего Поволжья накануне Великого Октября по материалам Казанской губернии). – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – С. 25.

[23] Фролова С. А.Молостововы // Храмы нашей памяти. Духовно-архитектурное наследие династей меценатов и благотворителей в Казанском крае /Под общ.ред. М. В. Андреева. – Казань: Центр инновационных технологий, 2016. – С. 51–58.

агачлары да үскән. Казан янында, Югары һәм Түбән Ослан авылларында күп итеп җир җиләге үстерү белән дә шөгыльләнгәннәр. Чыганакларда Казан губернасының иң зур һәм әйбәт бакчалары Зөя һәм Тәтеш өязләрендә дип күрсәтелә[24]. Ташевка, Красновидово авыллары янында 250, Лабыжка, Бортас, Шеланга тирәләрендә 136, Тенкидә 700, Богородскийда – 200, Антоновкада – 150 бакча булган[25]. Тәтеш өязенең иң зур, матур алма бакчасы дворян Молостововлар тарафыннан булдырыла. Тау сөзәклегенә 500 дән артык алма агачы утыртып тиңе булмаган бакча үстерәләр[26].

*Урманнар.* Казан губернасындагы дәүләт милкендә булган урманнар округларга бүленгән була, һәр округка 4 әр өяз кергән. Ядрин, Чар, Зөя һәм Тәтеш өязләре бер округка караган. Һәр округка үзенең урман офицеры, каравылчысы, бер ревизор билгеләп куелган. Крестьян урманнары белән дәүләт крестьяннары үз хуҗалык кирәкләре өчен куллана алганнар. Россия флоты өчен Тәтеш өязе урманнары да киселгән. XIX гасыр уртасында Казан, Чистай, Тәтеш, Мамадыш, Зөя, Чар, Лаеш, Чуел, Спас өязләренең 38 волостеннән 55619 ир-ат лашман хезмәтендә булган, алар бу хезмәтләре өчен рекрутлыктан азат ителгәннәр[27]. Россия флоты төзелешенә империянең бик күп урманнар ресурсы китә. Казан губернасында исә, бу кампания вакытында иң күбе Казан өязендәге урманнар юк ителә, югалтулар буенча икенче урында Тәтеш өязе торган. Тәтеш өязе картлары сүзләре буенча, «бөтен рәтле урман юк ителде, тәртәгә яраклы агач табып булмый», дип зарланалар[28]. Бу ике өяз урманнарына зур зыян килү буенча иң аянычлары булса, алардан кала Чуел, Зөя, Лаеш, Ядрин, Мамадыш өязләре бара. XIX йөзнең 60 нчы елларында Тәтеш өязендә бары тик 64169 дисәтинә генә урман була[29]. Бу елларда инде урманнарга иң ярлы өяз булып Тәтеш өязе саналган, өяздә төзелеш эшенә яраклы агачлары булган урман гомумән, калмый[30]. Тәтеш өязенең затлы урманнары турында җирле халык хәтерли, мисал өчен, Үләмә елгасы буендагы Никифировка авылы янында заманында бик куе урман булса да, ул урманнан бары тик агач төпләре генә калган. XIX йөзнең икенче яртысына карый торган чыганаклар халкы йортларын салам ягып кына җылыта ала

[24] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 287.

[25] Шунда ук.

[26] Фролова С. А.Молостововы // Храмы нашей памяти. Духовно-архитектурное наследие династей меценатов и благотворителей в Казанском крае /Под общ.ред. М. В. Андреева. – Казань: Центр инновационных технологий, 2016. – С. 51–58.

[27] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 76.

[28] Шунда ук. – С. 294.

[29] Шунда ук. – С. 289.

[30] Шунда ук. – С. 290.

инде, дип хәбәр итә[31]. Бу якларда инде куе урманнарны хәзер бөтенләй очратып булмый. Халык тыгызрак яши торган төбәкләр, урманнары интенсиврак юк ителгән төбәкләр белән тәңгәл килә, бу ике күренеш арасында бәйләнеш бар. Алар: Казан, Ядрин, Тәтеш, Чар, Зөя, Мамадыш, Лаеш өязләре.

Тормыш авырлыгы белән лашман урманнарына кереп агач кисәргә батырчылык иткән крестьяннарны тотканнар, каты җәза биргәннәр, хәтта суд ясап сөргенгә дә җибәргәннәр, төрмәләргә дә утыртканнар. 1865–1867 елларда Олы Бакырчы һәм Биеш авылы крестьяннарының Чирмешән-Биябаш авылындагы кораблар төзү өчен булган урманы кисүләре хакында эш ачыла. Биккенин, Ибраһимов, Хөсәенов фамилияле крестьяннарны бу кылган гамәлләре өчен 100 кеше аша суктырырга, 6 сум 90 тиен штраф түләргә һәм сөргенгә сөрергә карар итәләр. Гаделша Бадамшин, Шәмсетдин Иксанов шулай ук суктыруга, 39 сум 33 тиен штрафка һәм дә Себергә сөргенгә җибәрелүгә хөкем ителгән. Бәхтияр Иксанов уллары Баһаветдин, Җамалетдин белән һәм Сәмит Бикмуллин, Җиһанша Бәйрәмев, Тимергали Сөләйманов, Олы Бакырчыныкылар Әюп Мясыев, Фәтхулла Җәгъфәрев, Гыйззәтулла Кулаев, Халит Әдәмшин, Гали Ибраһимов, Гыйззәтулла Мәҗитев, Мәһди Әхмәдиев, Гази Зәйниев һ.б штрафка тартылалар[32]. Иске Әтрәч авылы янында да 1755 дисәтинә 1287 сажин мәйданындагы лашман урманы була, урман эчендә 33 дисәтинә 1936 сажин зурлыгындагы мәйданны печәнлек өчен кулланып булган. 1800 елгы документ буенча, әлеге урманда 66 кораб төзәрлек имән агачы үскән[33]. Авылның хәзерге күренешенә карасаң, анда инде бернинди агач та юк.

*Крестьяннар хәрәкәте.*

Крестьяннарның матди хәле, аларның яшәү шартлары җиңел булмый. Беренчедән, алар җир азлыгыннан интексәләр, икенчедән уңышсыз еллар кабатланып тору, табигать шартларының крестьян тормышына еш кына авырлыклар китерүе, болардан кала, җан башыннан түләнә торган оброкның да зур булуы һ.б. Җан башыннан оброкның суммасы якынча 10 сум 31 тиен тәшкил иткән[34], бу сумма еш кына крестьян хуҗалыгы табышының 50%ын алган[35]. Крестьяннар эшләргә тиешле мәҗбүри (повинность) эшләр күп булуы да аларның хәлен көннән-көн катлауландыра. XIX йөзнең икенче яртысында крестьян тормышына зур афәт алып килгән вакыйга ул – 1877

---

[31] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 294.

[32] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 2242 эш. 5–19 б кгз.

[33] ТР ДА, 324 ф., 725 тасв., 524 эш.

[34] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 272.

[35] Смыков Ю. И. Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 г. – Казань, 1959. – С. 8.

елгы ачлык. 1877 елгы уңышсызлыктан соң Казан губернасында йөреп чыккан эчке эшләр министрлыгы чиновнигы 1883 елда «продовольствие мәсьәләсе, нигездә, татарларныкы. Мин булган барлык җирләрдә дә, башлыча, татарларның хәле мөшкел»[36], дип яза. Санкт-Петербургка биргән докладында «1877 елгы уңдырышсыз елдан соң интегүчеләр – татарлар»[37], дип белдерә Казан губернаторы Н. Я. Скарятин. Казан губернасында 1877 елда иң зыян күргән төбәкләр: Казан, Мамадыш, Спас, Чистай, Тәтеш өязләре. Ачлыктан крестьяннардан кала, табышлары җир белән бәйле булган алпавытлар да бөлә, дворяннарның матди хәлләре дә бермә-бер начарлана. Моннан кала, 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышы гади халыкның тормышын түзә алмаслык катлауландыра. Бу бигрәк тә татар-мөселманнар өчен фаҗигага әйләнә.



Тәтеш шәһәре күренеше. XX йөз башы почта карточкасы

1877 елда башланган сугыш татар җәмгыятенең халәтенә зур үзгәрешләр кертә, сугыш беткәннән соң да аның кайтавазы татар тормышында озак вакыт дәвам итә. Беренчедән, татарлар да төрек белән сугышу өчен гаскәргә алына, сугышка алынучыларны озату күренеше үк татар кешесендә аптыраш уята, сугышка китүчеләрнең күңелен күтәрү максатыннандыр инде, химаячеләр акчасына аларны аракы, ак ипи белән сыйлыйлар[38]. Мондый гамәлләр татар-мөселман җәмгытенә бары тик киеренкелек кенә өсти.

Төрек солтаны армиясенең бу сугышта җиңелүе Русиядәге татар җәмгыятенең тынычлыгын бетерә. Сугыштан кайткан рус солдатлары «төрекне

[36] Смыков Ю. И. Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 г. – Казань, 1959. – С. 8.

[37] Шунда ук.

[38] ТР ДА, 1 ф, 3 тасв., 3987 эш, 14 кгз.

җиңдек, хәзер барлык мөселманнарны да чукындырачаклар», дигән сүзләр тарата. Мөстәкыйль дәүләтен югалтканнан бирле чукындырылу белән куркытылган татар кешесе өчен бу хәл аеруча куркыныч. И.Гаспринский язганча, хөкүмәткә каршы башланган хәрәкәтләр Касыймнан башлап Ташкентка кадәр, Пермьнан Ленкоранга кадәр җәелә. Крестьяннар тарафыннан башкүтәрүләр Казан, Самара, Уфа, Сембер, Вятка губерналарында да күзәтелә. 1878 ел башына хәл аеруча кискенләшә, властьларның һәр адымы татар җәмгыяте тарафыннан христианлаштыру итеп кабул ителә башлый. 1878 елда янгын куркынычсызлыгы өчен чыгарылган инструкция, хәтта Казан өязендә крестьяннарның зур күтәрелешен китереп чыгара. Инструкциянең бер пункты итеп янгын куркынычсызлыгын күзәтү өчен авылларда каланча төзү тәкъдимен татарлар мөселман авылларында чиркәү сала башлыйлар дип кабул итәләр, чөнки алар каланчаны чиркәүгә охшаталар. Гомумән, һәр нәрсәне татар куркып каршы алган, аның өчен иң курыкканы чукындыру була. Янгын куркынычсызлыгы өчен кабул ителгән инструкцияне дә халык чукындыру белән бәйле булырга мөмкин дип кабул итә, шуңа да халык арасында зур күтәрелешләр башлана. Хәтта халык күтәрелешләрен бастыру, халыкны суктыру өчен Казан губернаторы Н.Я Скарятин үзе халык өстенә гаскәр белән бара. Шушы елларда хәлле татарларны руслар төректән яулап алган җирләргә күчерә башлыйлар икән, Зөя өязендә писарь шундый татарларның исемлеген төзи башлаган дигән хәбәр тарала. Бу сугыштан соң тагын бер зур буталыш 1897 елда Россиядә халык санын алган вакытта була, монда да татарлар чукындыру куркынычын күрәләр.

Инструкция нәтиҗәләре аркасында килеп чыккан буталышлар нәтиҗәсе булып, кайбер авыл җәмгыятьләре үз идарәләрен булдырырга тырышалар, аларның бу эштә үз җитәкчеләре дә була. Чынлап та, алар аерым бер татар авылында үзидарәләрен урнаштыралар да. Крестьяннар үзләренең җитәкчеләренә генә буйсынып, хәтта дәүләткә ясак бирми башлыйлар[39]. Хакимият вәкилләренә булган каршылык Чистай төбәгендә, Спас, Казан, Мамадыш һәм Тау ягында аеруча көчле була. Полиция Тау ягында «халыкны котыртучы» буларак Габдулла Халитовны атый. Ул катгый рәвештә власть буйсынудан баш тарта, авыл җыенына килми. Аның көрәштәшләре Билялетдин Җәләлетдинев, Якупов, Хәбибуллин, Сафа Монасыйповлар да аның үрнәгендә гамәл кылалар. Татар крестьяннары өстенә төшкән салым, түләүләр авырлыгы һәм милли яктан изүләр 1878 ел ахырына барлык крестьяннар арасында киеренкелек тудыра башлый һәм бу хәлләр крестьяннар хәрәкәтенә этәргеч бирә. 1878 елның башында ук чуаш һәм мордва крестьяннары да властьларга каршылык күрсәтә башлый. Казан губернаторының Санкт-Петербургка биргән докладында чуаш һәм мордва крестьяннарының татарларга карап эш итүләре күрсәтелә. Тәтеш өязендәге губерна жандарм идарәсе ярдәмчесе

[39] ТР ДА, 1 ф, 3 тасв., 4659 эш.

Казандагы начальнигына татарларга карап 1877 елдагы инструкция буенча булачак йөкләмәләрләрдән куркып кул куюдан баш тарталар, дип хәбәр итә. Татарлар арасында башланган ризасызлыклар Урта Иделнең һәр төбәгенә, барлык крестьяннар арасына тарала. Һәрвакыттагыча, бу хәбәрләрнең үзәге һәм халыкның гамәл тактикасын билгеләүче пункт буларак базарлар торган. Крестьяннарның башкүтәрүләре Казан губернасының бар өязендә дә барган. Крестьяннарны «тынычландыру» өчен Казан өязенә Скарятин гаскәр белән үзе килә, ә Спас өязенә гаскәр җибәрә алмый, чөнки гаскәрен ул бары тик Лаеш, яисә Тәтештән генә ала алган, әмма ул ел җылы булып, боз озак катмау сәбәпле, елга аша үтү мөмкинлеге булмый[40].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Тәтеш төбәгенең социаль картинасы төрле, ә халкының төп шөгыльләре беренче чиратта авыл хуҗалыгы, җир эше белән бәйле булган. Авыл җирлегендә гомер иткән кешеләрнең төп проблемасы – җир мәсьәләсе бу төбәкнең дә кискен социаль проблемасы булып тора. Россиядә барган бар социаль вакыйгалар да, киеренкелекләр дә Тәтеш төбәге халкының тормыш, көнкүрешендә чагылыш тапкан.




Тәтеш шәһәре күренеше. Идел елгасы яры.
XX йөз башы почта карточкасы

[40] Смыков Ю. И. Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 г. – Казань, 1959. – С. 19–29.

## § 2. *Тәтеш ягы халкының кәсепләре, һөнәрләре*

Билгеле булганча, башкүтәрүләрдән шүрләп, XVII гасырның башыннан, татарларга тимер эше белән шөгыльләнү өчен рөхсәт бирми башлыйлар. Авыл кешесе тимер белән эшләмичә көн күрә алмавы да билгеле, аның җир сөрү өчен тырмасы да, сукасы да, агач кисәр өчен балтасы да, пычкысы да булырга тиеш. Әмма бу эшләрне эшләү өчен татар авылларнына башка җирләрдән рус кешеләре, чуашлар, яисә провославие динендә булган башка халык вәкиле китерелгән. Бу кешеләрнең татар авылларында гел мөселманнар янында яшәп, алар белән аралашып торуы, хәтта кайберләренең татар кызлары белән гаилә корып җибәрү очраклары да була. Күп кенә христиан тимерчеләрнең татар авылларында үзләренең, яисә соңрак аларның дәвамчыларының татарлашуы җирле халык бик ачык хәтерли. Кайбер авылларда ул нәселләр әле дә дәвам итә. Тора-бара татарлар белән көн саен татар телендә аралашу нәтиҗәсе буларак, үз туган телләрен җуеп, татарча да сөйләшә башлыйлар, хәтта исламга күчү очраклары да еш булган. XIX гасырда Тәтеш өязендә бер тимерчеләре булган авыллардан, Шәмбалыкчы волостена карый торган Югары Ындырчы, Ябалак, Шәмбалыкчы, шулай ук Олы Яңасала, Кече Таяба, Апас, Бәки, Әмәкәй, Васильево, Марьино, Никифирово, Олы Яльчек, Әхмәт, Кошта авыллары, Степановка, Бәбки, Кырлангы, Иске Йомралы, Бәйрәш авыллары. Тимерчеләре ике һәм аннан да күбрәк авыллар – Чернышевка, Антоновка, Икенче Чирмешән, Аюкүдергән, Ишеево, Танаево, Лаптевка, Сөйки, Ишем, Шершалан, Алексеевка, Олы һәм Кече Фролово, Төбәк Черкене, Янбухта, Чинчурино, Колунец, Өрем, Нечасово, Яшевка, Нармонка, ә Татар Борнашы авылында тугыз кеше тимер белән эш иткән. Агач эше, бакыр кою белән шөгыльләнүчеләр күп булмый. Андыйлар Биябаш, Иске Күлкәш (хәзерге Урман Тәүгелдесе авылы), Шәмәк, Кече Бортас, Олы Болгаер, Каенлык, Кызыл Поляна, Монастырское, Чинчурино авылларында бары берәр кеше бакыр эше белән эш иткән. Бакыр эше ул, нигездә, татарлар өчен бакырдан комган ясау булган. Аның белән җире булмаган кешеләр шөгыльләнгән. Әллә ни зур табыш китерә торган эш булмый, чөнки чимал буларак бакыр үзе шактый кыйммәт торган, оста комганнарны күпләп сатып алучыга биргән, алар Бөгелмә, Самара, Уфа, Оренбург һ.б. базарларга озатылган. Бер оста атнасына күп дигәндә 5 комган ясый алган, комганның бәясе 1–2 сум торган. Тәтеш ягында ювелир әйберләр, яисә төрле бизәнү әйберләре, ат дагасын бизәү өчен эшләнмәләр ясаучылар бик күп булмый. Бары тик хәзерге Буа районына карый торган Кужак (3 кеше) һәм Әхмәт авылында (1 кеше) гына бу эш белән үз өендә шөгыльләнгән, ә татарлар яшәгән кайбер төбәкләрдә бу һөнәрләре белән тирә-якка чыгып акча эшләүчеләр дә, эшләнмәләрен базарларга чыгаручылар да күп

була, әмма бу һөнәрчелек Тәтеш төбәгендә бу чорда бик популяр булмаган. Таш, известь белән эшләүчеләр арасында татарлар бик аз, бу эш белән күбрәк руслар шөгыльләнгән. Казан губернасы буенча карасаң да, татар авыллары бу өлкәне үз һөнәрчелеге итмәгән. Тәтеш өязендә Сөйки (55 кеше), Долгая Поляна (18 кеше), Мордва Каратае (18 кеше) авыллары кешеләре, Мордва Каратаендагы 18 кеше алебастр һәм акшар белән эшләгән. Мордва Каратаенда бу эш алдагы елларда гөрләп бара торган булса да, табышны да ярыйсы гына бирсә дә, XIX гасыр ахырына инде ул үзен акламый башлый. Бу авыр хезмәткә хатын-кызлар катнашмаган, алар бары тик акшар белән эш иткәндә ярдәмче генә булганнар. Таш чыгару яз һәм көз айларында гына алып барылган, бу авыр хезмәт 40 сумнан 80 сумга кадәр генә табыш китергән. Җитештерелгән товар, материал Казан шәһәре базарына чыгарылган, шулай ук Идел буйлап башка губернияләргә, хәтта Әстерханга кадәр дә җибәрелгән. Зөя өязендә известьне яндыру өчен махсус мич тә булган. Кирпеч сугу эше Казан губернасының бар өязендә булса да, аның белән зур табыш алырлык киң итеп шөгыльләнүче булмый, бары тик хуҗалык кирәк-яракларына, үз мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә алырлык кына җитештергәннәр. Тәтеш өязендә Картапа (43 кеше), Кече Бакырчы (15 кеше), Югары Балтай (50 кеше), Сөйки (15 кеше), Кирельское (4 кеше), Балтачтан 4 кеше кирпеч сугу белән үз авылларында гына эшләгәннәр, ә Кыят, Тәтештән Буага китеп эшләүчеләр була. Ягъни, кирпечне үз ишегалдында чатыр астында киптергәннәр, аның өчен аерым бина булдыру авыл кешесе өчен мөмкин булмый. Бу авыр эшне, әлбәттә, ир-атлар башкарган, әмма гаиләдәге яшьүсмер егетләр, хатын-кызлар да булышмый калмаган. Кирпеч бәяләре Казан губернасының төрле төбәгендә төрле бәядән йөргән, Тәтеш өязендә кипмәгән 1000 кирпечкә 2 сум 50 тиен, яндырылганына 4–5 сум табыш алып булган. Бер сезонда, нигездә, җәй айларында, уртача зурлыктагы гаилә 10000 тирәсе кирпеч суга алган, зуррак гаиләләр күбрәк тә эшләргә өлгергән.

Балчыктан савытлар ясау һөнәре Тәтеш төбәге өчен чит һөнәр түгел, борынгы Болгар җирлеге – Шонгатыда табылган керамик әйберләр мондагы халыкның балчык белән эшләвен күрсәтә, хәтта археологлар фикеренчә, биредә балчыктан әйберләр ясаучылар бистәсе дә булган. Шулай булса да, XIX гасырга бу төбәктә әлеге һөнәр белән шөгыльләнүчеләр инде калмый. Бары тик Шонгатыда 16 кеше, Чинчуринода 6 кеше, Кирельскоеда 4 кеше, Олы Нечасовода 6 кеше генә бу һөнәр белән көн иткәне билгеле. Кирильскоеда җитештерелгән чүлмәкләр, кувшиннар, балчыктан ясалган башка әйберләр тирә-як авылларда сатылганнар, бу һөнәр аларга 180 сумлык еллык табыш китергән[1]. Игътибар итсәк, бу эш белән татар авыллары бөтенләй дә шөгыльләнмәгән, гомумән, бер Тәтеш ягына гына түгел, бу хәл бөтен Казан

[1] История Татарии в документах и материалах. М.: Государственное социально-экономическое изд-во, 1937. – С. 278.

губернасында күзәтелә. Төп шөгыльләре җир эше булганнар бары буш вакытларында гына эшли алганнар. Балчыктан ясаган әйберләр җирле базарларда сатылган, заказ бирүчеләр, нигездә, алпавытлар, алар гөл чүлмәкләренә заказ биргәннәр. Спас өязе чүлмәкчеләренең товарларын Самара губернасына җибәреп, анда икмәккә алыштырулары мәгълүм.

Мич чыгару татарлар арасында шактый танылган һөнәр булган, кыр эшләре бетеп, мөмкинлек чыкканда алар тирә-як авылларга барып, мич чыгарганнар. Һәр төбәкнең атаклы миччеләре була, мич чыгару ул үтә профессиональлек таләп иткән, өйнең җылы булуы мичченең осталыгыннан да торган. Шәмбалыкчыда – 2, Болын-Балыкчыда – 1, Тарловкада – 3, Әлмәндәрдә – 2, Иске Казиле – 4, Барышта – 4, Караталга, Балчыклыда – 1, Олы Яңасала – 2, Олы Бакырчыда – 3, Олы, Кече Кариле, Келәнчедә – 1, Ишеевода – 4, Лаптевкада – 2, Ишимовода – 1, Әхмәттә – 7, Күзби, Ташкичүдә – 1, Олы Фролово – 2, Иске Йомралы – 4, Алабирде – 5, Олы Тормыда – 2, Бәйрәштә – 11 шкатур, пыяла, буяу эше белән шөгыльләнүчеләр була. Ә Шәмәктә – 5, Түбән Балтайда – 4, Урта Балтайда – 5, Әлки, Атабай, Әнкәбәдә – 1 мичче булуы билгеле. Кызганычка каршы, аларның исемнәре инде безгә билгеле түгел. Тәтеш өязенең Ракитовка авылыннан май аеннан октябрь аена кадәр читкә китеп таш эше белән акча эшләүчеләр дә була.

Халык юкә тузыннан кайры аерып тормыш кирәк-яраклары ясау, чабата үрү эше белән шөгыльләнергә мәҗбүр булган, авыр чорларда аларга хуҗалыгында кирәк булса, кайберләре күпләп сатып алучыларга тапшырып беркүпмедер табыш та калдырган. Бу товарлар, нигездә, җирле базарларда сатылган. Тәтеш ягында бу һөнәрчелек әлләни зур үсеш алмый, нигездә, үз кирәк-яраклары өчен генә эшләнгән. Байбердино Аранчеевода 20 гаилә, Аксуда – 6, Черкендә – 4, Черки Ишмәктә – 2 гаилә, ә Колунец авылында авылның барлык кешесе дә диярлек чабата үргән.

Тәтеш ягында зур урманнар булмау сәбәпле, урман белән табыш итү мөмкин булмый, шулай да авылдан берничә кеше утын әзерләү, аны сату белән көн күргән. Шундыйлар, Сибирче авылыннан – 4, Иске Казиледән – 6, Әлмәндәрдән – 4, Картапа, Әҗем, Караталгадан – 2, Икенче һәм Өченче Чирмешән, Олы Бакырчы, Аюкүдергән, авылларыннан – 2, Коллар – 10, Тәүгелдедән – 7, Түбән Балтайдан – 4, Олы Балтайдан – 20, Урта Балтайдан – 9, Борнаштан – 4, Бишалабтан – 4, Олы, Кече Бортастан – 2, Сөйкидән – 7, Балтачтан – 3, Ишемнән – 2, Олы Фроловодан – 5, Кече Фроловодан – 3, Степановкадан – 2 кеше агач белән бәйле төрле эшләр башкарган. Монастырское авылы кешеләре урман аударып, аны саллар белән җибәреп тә сату иткәннәр. Шулай ук Кирельское авылы кешеләре ягулык утын әзерләп сатканнар. Тәтеш ягында агачтан нәрсәдер ясау һөнәре юк дәрәҗәсендә: бары тик Ивановка авылында 4 гаилә, Балчыклыда – 2 кеше кәрҗиннәр үргән, ә агачтан йорт җиһазлары ясаучылар бөтенләй дә булмаган.



Тәтеш янында тотылган кырпы балыгы. 1921 ел

Агачтан йорт бурау, яисә башка корылмалар салучылар Казан губернасының барлык авылларын да диярлек булган, бу эш белән күбрәк татар, чуаш һәм руслар шөгыльләнгән. Күп очракта җир эшеннән бушаган арада, өстәмә акча эшләү мөмкинлеге өчен 3–4 кеше бер төркем булып күрше авылларга, яисә шәһәргә эшкә чыгып китә торган булган. Шәмбалыкчы, Иске Барыш, Олы Яңасала, Олы Таяба, Урта Балтай, Олы Кариле, Сөйки, Әлки, Килдураз, Олы Фролово, Олы Шәмәк, Пролей-Каша волостьларына кергән авыллардан 3–7 кеше бурачы булып йөргән, Коллар авылында 10 кеше, Сөйкидә 13 кеше, Ильинское һәм Чинчурино авылларында йөзгә якын кеше балта остасы булган. Читкә китеп акча эшләргә мөмкинлек бирә торган тагын бер һөнәр – ул агачтан төрле әйберләр ясау, көрәкләр, савытлар, зур су савытлары һ.б. Казан губернасында бу эш белән, нигездә, руслар һәм татарлар шөгыльләнгән, ә аерым Тәтеш өязен алсак, бу эш татарлар кулында була. Җитештерелгән товар җирле базарларда сатылган. Бу эш белән ныклап эшләүчеләр товарларын Самара, Сембер базарларына чыгара алганнар. Чималның бәясе югары булып, әзер товар бәясе әлләни югары йөрмәгәнгә мондый әйберләрне сатып табыш алу читен булган. Тәтеш ягында бу эш белән Олы Бакырчыда – 18, Кече Бакырчыда – 25 кеше, башка авылларда 2–3 кеше генә шөгыльләнгән. Агачтан тәгәрмәчләр, дугалар, чаналар ясау күбрәк Казан арты авылларына хас, шулай да, үз төбәге өчен мондый кирәкле товарлар үз җирлегендә эшләнгән. Пролей-Каша волостена карый торган Колунец, Удельное Нечасово, Барское Нечасово, Выселки Нечасово, Өрем исемле рус авылларында 49 кеше бу һөнәрчелекне үз итә. Татар авылларында да бу һөнәр була, әмма аерым 3–4 кеше генә бу эшкә вакытын бүлә алган.

Көндәлек тормышта тукыма һәрвакыт кирәк, шунлыктан, кышкы вакытта хатын-кызлар туку белән эш иткәннәр, әмма гаилә кирәк-ярагына гына түгел, ә зур партияләрдә сату өчен Тәтеш өязенең Сөйки авылы кешеләре җитештергән. Монда җитештерелгән җитен, тукыма сыйфаты ягыннан Ярославль осталарыныкыннан бер дә калышмаган. Бу промышленность төре аларга елына 950 сумга кадәр табыш биргән. Товарларын илнең төрле төбәкләреннән сәүдәгәрләр зур партия белән сатып алып киткәннәр[2].

Казан губернасында тире эшкәртү белән күбрәк руслар шөгыльләнгән, кайбер татар авылларында да мондый һөнәрчеләр булган, әмма аларның саны

---

[2] История Татарии в документах и материалах. М.: Государственное социально-экономическое изд-во, 1937. – С. 278.

бик аз, бары 1–3 кеше генә. Тире белән Тәтеш өязенең Сибирче, Бишево, Иске Барыш, Картапа, Сөйки, Шершалан, Шонгаты, Олы Фролово, Антоновка авылларында берничә кеше эшләгән. Казма (Буа районы) авылында 8 кеше читек теккән, Колонец авылының 5 остасы күн итекләр ясаган. Татар авылларында киез дә басканнар, әлбәттә, бу Тәтеш төбәгендә табыш алу дәрәҗәсендә үк зур үсеш алмый. Моның белән Сибирче, Биябаш, Аюкүдергән, Каргала, Өченче Чирмешән, Түбән Балтай, Тутай авылыннан берничә гаилә шөгыльләнгән, татарлар киездән төрле әйберләр ясау осталары булганнар. XIX гасырда һөнәрчелекне өйрәнгән тикшерүчеләр бу эштә, нигездә татарлар булуын, татарлар җитештергән эшләнмәләрнең пөхтәрәк булуын таныйлар. Һөнәрчелек тарихын өйрәнүчеләр дә «Вотяклар татарлар белән конкурентлыкны күтәрә алмыйлар, шуңа күрә, товарларына бәяләрен төшерергә мәҗбүрләр»[3], дип язалар. Бу һөнәрчелек читкә чыгып эшли торган һөнәрләрдән саналган, 1–2 кеше, яисә олы кеше белән яшьүсмер кыр эшләре беткәч, көз аенда чыгып китеп март, апрель айларына кадәр читтә эшләп кайтканнар, ә кайберләре бу эш белән үз авылларында гына шөгыльләнгәннәр. Шулай ук тегү эше кышкы айларда крестьян өчен беркадәр акча эшләргә мөмкинлек биргән. Бер ишеләре якын-тирә авылларга кышкы айларда барып эшләсәләр, кайберләре күрше губерналарга да китеп эшләгәннәр. Кайбер тегүчеләр Оренбург якларына китеп, ел әйләнәсе буенча тегү теккәннәр. Тәтеш ягында бик күп авылларда тегүчелек белән эш иткән кешеләр була, әмма тегүчеләр күп яшәгән авыллар: Ишеево, Танай, Марьино, хәтта 20–35 кеше бу хезмәт белән шөгыльләнгәне билгеле. Тәтеш ягында 108 кеше аучылык иткән, шуларның 35 се Олы Шәмәк волосте авылларыныкылар. Килдураз волосте кешеләре елына 15 тиенгә күлләр арендалап, шулай ук Зөя елгасыннан балык тотып, Буа шәһәре һәм Каратун базарында сата торган булалар, бу эш 190 сумга кадәр табыш китергән. Сөйки, Мордва Каратае, Кирельское, Ишимово, Балтач, Иске һәм Яңа Кариле, Бәби, Малаевка, Салтыган, Минсәед авыл җәмгыятеннән, казна, җирбиләүче Апанаевлардан арендага алынган күлләрдә, Идел елгасында Сөйки волостеннан 300 гә якын кеше балык тотканнар. Тәтеш өязенең ветеринар врачы Олифин сүзләре буенча, Идел буендагы авыл крестьяннары, мещаннары барысы да балыкчылык белән шөгыльләнәләр. Красная Поляна, Монастырское, Сөйки, Кирельское, Богородский авыллары кешеләре балык тотып хәллеләр рәтендә саналганнар. Сату өчен тере балыкны Казан шәһәре базарларына озатканнар. Балыктан алынган табыш төрле җирдә төрлечә булган, әлбәттә. Пролей-Каша писаре күрсәтүе буенча, балыкчылык 1430 сумга кадәр табыш китерә алган, балыкчылык ул сезонлы эш, балык тоту белән Петров посты вакытында шөгыль-

[3] Материалы для исследования промыслов населения Казанской губернии. Казань: Казанская Губернская Земская Управа, 1887. – С. 216.

ләнгәннәр. Кирельское авылы крестьяннары балык тотудан еллык 1800 сум табыш алганнар[4].

Һәр төбәкнең үзенең танылган һөнәрчеләре була, күп кенә очракта алар чит төбәкләргә чыгып та үз хезмәтләре белән танылу алалар, алар эшләгән эшләнмәләр гасырларны үтеп хәзерге көннәргә кадәр дә килеп җитә. Тәтеш өязендә шундый кешеләрнең берсе – ташчы Ибәтулла Рәхмәтуллин. Ул 1863 елда дөньяга килгән, Болын-Балыкчы (Апас районы) кешесе. Атасыннан ятим калып, агасында тәрбияләнә, әмма аның кырыслыгына түзә алмыйча, үсмер егет Җаек якларына чыгып китә, яллы хезмәттә йөри. Шушы вакытта төзелеш эшенә өйрәнә, кирпеч суга, мичләр чыгара, йортлар сала. Туган ягына киредән әйләнеп кайтканда аңа бары тик 22 яшь кенә булса да, ул инде һөнәрче булып җитешкән үз эшенең остасы итеп таныла. Туган ягына кайтып төпләнгәч, известь яндыра, балчыктан кирпеч суга, аның кулы белән тирә-як авылларда бик күп биналар җиткезелә. Тәтешнең үзендә генә дә ул 8 ташпулат сала, Апаста Кадыйр байга йорт һәм кибет, Болын-Балыкчыда Спиридон йорты[5], Габделхалик байларга кибет биналары, Үтәмеш баена ташпулатлар төзеп бирә, моннан кала Көлкәштә, Балтайда (Апас районы) ул салган биналар бар. Ул җиткезгән биналарның күбесе хәзерге көннәрдә тарихи архитектура истәлеге булып дәүләт исәбендә дә торалар. Атаклы ташчыга шул төбәкнең шулай ук «күренекле» кешесе Шәкүр карак та мөрәҗәгать итә, аны яртылаш җайлап, яртылаш куркытып та эшкә күндерә. Ибәтулла ташчы Шәкүр каракка 10 ат сыярлык кирпеч конюшня һәм таш капка салып бирә. Төбәкнең бае – Шәкүр карак аның хезмәтенә тиешенчә түли, әмма аны озатканда ярым шаярып: «Син, Балыкчы татары, безне тыңлап яхшы эшләдең әле, юкса, 2 атың да балык кебек «шуачаклар» иде, – ди»[6]. Төбәкче Азат Сункишевкә Ибәтулла ташчы салган Шәкүр йорты дип бер таш бинаны күрсәтәләр, әмма ул вакытта ул бинаның тарихын ачыклап өлгерми, бары тик фотога гына ала, соңрак инде бу бинанын юкка чыгуы ачыклана[7].

Авыл җирләрендә кечерәк мануфактуралар да, заводлар да эшләгән. Шундыйлардан,Тәтеш өязендәге Ындырчы авылы, Собачья Поляна, Өрем һәм морза Бикеевлар утарында 5–10 кеше хезмәт куйган постау заводлары елына 500 дән 1200 потка кадәр чимал җитештергән[8].

Төбәкнең экономик халәтен күрсәтүче тагын бер билге – ул аның тегермәннәре булу. Икмәкне җитештерү генә түгел, ә аны халыкка җиткерерлек

[4] История Татарии в документах и материалах. М.: Государственное социально-экономическое изд-во, 1937. – С. 278.

[5] Сәүдәгәр Спиридон Петрович йорты.

[6] Сункишев А. Истәлекле биналар, истәлекле урыннар. Беренче кисәк. – Казан: Школа, 2009. – Б. 94.

[7] Шунда ук.

[8] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 89–90.

чимал итү дә мөһим, тегермәнне хәлле кешеләр генә тота алганнар. XIX йөз уртасында Тәтеш өязе буенча 230 су тегермәне булган, Тәтеш шәһәренең үзендә 1 су тегермәне, 3 җил тегермәне эшләгән[9].

Тәтеш шәһәре зур су юлында урнашу сәбәпле, XVIII–XX йөз башында өяз халкына яллы хезмәт – бурлаклар булып та көн күрергә туры килә. Тарихчы Г. Әхмәрев алар хакында «аларның [крестьяннарның] ничек булса да, хөкүмәткә аңлату ляземдер [кирәктер], хөкүмәт аларны бөтенләй онытмасын, падишаһның крестьяннар хакында бирелгән манифесты белән алар да файдалансыннар, гайреләре [башкалары, бүтәннәре] җирле булганда, алар да җирле булып калсыннар! Бөтен Русиядә бурлак булып йөрмәсеннәр»[10], дип яза. Башлыча, бу авыр хезмәткә җирсезлектән интеккән крестьяннар, элеккеге солдатлар яллanырга мәҗбүр булганнар. Тау ягы өчен дә бу хезмәт чит булмый, чөнки Идел ярында урнашкан Тәтеш шәһәре товар суднолары үтә торган пункт саналган, шулай ук Иделдән кала, ул вакыттагы мул сулы Зөя елгасы өчен дә бу хезмәт таләп ителгән. Тәтеш өязеннән бу авыр хезмәттә Ильинско-Шонгут, Олы Шәмәк волосте крестьяннары мәшгуль булган. Җирсезләр, бары тик үз физик хезмәтләренә яшәргә мәҗбүр булганнар, Иделнең түбән агымына төшеп тә, бу авыр эшне башкарганнар. Әстерхан ягына күчеп китүчеләрнең бер өлеше дә шушы Тау ягының бурлаклары. Тау ягындагы бурлаклар хакында төбәкче Азат Сункишев үз хезмәтләрендә тәфсилле итеп сурәтли[11].

Тау ягының, нигездә, үзенең башка төбәкләрдән аерылып тора торган үзенчәлекле һөнәрләре юк, халкы башка төбәкләргә дә хас булган һөнәрләр белән көн күргән. Үз тормышлары өчен, шул ук вакытта сатуга чыгару максатыннан да һөнәрчеләр тарафыннан эшләнгән эшләнмәләр сыйфатлары ягыннан югары бәяләнгән. Болгар заманыннан ук һөнәрчеләр төбәге булган бу яклар, вакытлар узу белән үз асылларын беркүпмедер югалтсалар да, борынгы бабаларының һөнәрләрен саклап килгәннәр.

---

[9] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 98.

[10] Әхмәрев Г. Мөселманнарның җир мәсьәләсе // Казан мөхбире. – 1906. – 6, 30 гыйнвар, 1 февраль.

[11] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, 2013. – С. 50.

## § 3. *Сәүдә*

Тәтеш төбәгендәге татарлар җыела торган зур базарлар татарларның, гомумән, шул төбәк кешеләренең сату-алу, шул ук вакытта аралашу урыны да була. Тәтеш шәһәрендә зур базарлар һәр дүшәмбе саен эшләп торган, ә ярминкәләр елга ике мәртәбә уздырылган һәм 2 көн дәвам иткәннәр[1]. XX гасыр башында ярминкәләрнең хәтта җиде көн дәвамында эшләве дә билгеле. 1913 елда Казан губернасының Җирле идарәсе карары белән Тәтеш шәһәрендә 20–26 июньдә үткәрелә торган ярминкә 6–12 июль көннәренә күчерелә[2]. Шәһәрнең үзендә 10 базар эшләп торган, халыкка кирәкле товар сатылган. Тәтеш шәһәре зур шәһәр үзәкләреннән ерак булу сәбәпле, ерак җирләрдән товарны китерү беренчедән, кыйммәт булса, икенчедән, моны эшләү өчен су юлы җайлы булганга, товар китерү навигация чорында башкарылган. Китерелгән товарларны саклау өчен Идел ярында 70 ләп товар саклау складлары төзелгән була[3]. Тәтеш яры бик сөзәк булу сәбәпле, пристаньнан товарны шәһәргә китерү шактый кыенлык тудырган, бу хәлне бераз җиңеләйтү өчен 1883 елда пристаньнан шәһәргә килә торган юлны ремонтлыйлар, ә 1911 елда сөзәк таудан күтәрелә торган баскыч төзелә[4].

Тәтеш өязе, нигездә, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче төбәк буларак сату-алуда, базарда авыл хуҗалыгы товарлары, авыл кешеләре җитештергән һөнәрчелек товарлары сатылган. 1850 ел мәгълүматы буенча, Тәтеш шәһәренең өченче гильдия 21 сәүдәгәренең еллык капиталы 50000 сум тәшкил иткән[5]. Төп сәүдә товары – икмәк булган. Тәтеш шәһәре Идел буйлап Тәтеш, Буа, Спас өязе товарын башка төбәкләргә җибәргән. Күпләп сату белән алыпсатарлар шөгыльләнгән. Халыктан сатып алып, Идел буйлап зур ярминкәләргә озатканнар. Күпләп алучыларга халыктан икмәк җыеп әзерләп кую белән шөгыльләнүчеләр дә була. Большая Владимировская урамында Тәтеш мещаны Исмәгыйль Мәҗитов үзенең складларына икмәк җыйган[6]. Зур сәүдәгәрләр Тәтеш пристаненнән елына 6–7 миллион пот икмәк алып киткәннәр. Идел ярында товарны саклау өчен 70 склад амбары төзелә[7]. Мисал өчен, XX йөздә икмәкне күпләп алучылар Санкт-Петербург сәүдәгәрләре Блиновлар

---

[1] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 13964 эш, 6–7 кгз.

[2] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 7847 эш, 1 кгз.

[3] Приволжские города и селения в Казанской губернии с картой р. Волги и рисунками. Репринтное издание. Казань: ТаРИХ, 2008. – С. 199.

[4] Опись городских поселений Казанской губернии /Сост. А. П. Орловым. – Вып. 1. – Казань: тип. Губ. Правл., 1885. – 139 б.

[5] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 101.

[6] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 7905 эш, 24 б. кгз.

[7] Приволжские города и селения в Казанской губернии с картой р. Волги и рисунками. Репринтное издание. Казань: ТаРИХ, 2008. – С. 199.

булган[8]. Күпләп алучылар крестьянның авырлык белән тапкан товарларына бәяне тагын да төшергән, шуның өстенә әле товарның авырлыгы белән алдау очраклары еш кабатланган. XX гасыр башында шәһәрнең үзендә 1 фунт (0,454 кг) арыш икмәге 1,5–2 тиен, бодай икмәге – 4 тиен торган, тозны 1 тиенгә, шикәрне 17 тиенгә алып булган, ә 1 фунт ит 12 тиенгә сатылган[9].

Шәһәрдә бакалея товарлары белән дә сәүдә иткәннәр. Товар төрле төбәкләрдән китерелгән. XX йөз башында бакалея әйберләре белән сату итүчеләр: Тәтеш шәһәре мещанкасы Газизкамал Вәлиева, Түбән Турай авылыннан Җәләлетдин Таһиров, Иске Татар Адәм авылыннан Әфзалетдин Насретдинов, Бибигазизә Мустеевна Карымова, шәһәрнең Большая Владимировская урамында Борнаш авылының Сабирҗан Бикмурзин, Исмәгыйль һәм Габделҗәббар Мәҗитовлар, Кече Владимировская урамында Шакирҗан Бикмурзин, Коллар авылыннан Габдулла Әхмәтшин, Танай Турай авылыннан Мөхәммәдхафиз Гайнуллин, Тәтеш мещаны Салаватулла Бикмурзиннар вак-төяк мануфактура товарлары белән сәүдә итә торган кибетләр тотканнар. Базар мәйданында Олы Тормы авылыннан Йосыф Мускеев, Тәтеш мещанкасы Хәмбарниса Хәйретдинова, Балтач авылыннан Гөлҗәмал Тимергалеевна Мянгутова, Келәш авылыннан Сабирҗан Мансуров, Гыймран Шәйдуллин, Олы Тормыдан Исмәгыйль Гобәйдуллин, Биябаш авылыннан Сәлимгәрәй Бикяшев, Тәтеш мещаны Хөснетдин Курамшиннар бакалея товарлары белән сәүдә иткәннәр. Галантерия товарлары белән Алабирде авылыннан Габдулла Нафилов, канцелярия товарлары белән Танай Турай авылыннан Җәләлетдин Таһиров, Буа мещанкасы Бибифатыйма Хәйретдинова, Русаково авылыннан Габелкадыйр Ярмөхәммәтев кәгазь продукциясе белән, Олы Тормы авылыннан Камалетдин Хәйсаров сәгать һәм башка галантерия товарлары белән сәүдә иткән. Бәйрәш авылы кешесе Касыйм Миңнегалиев утын саткан, ә Иске Казиле авылы кешесе Большая Владимировская урамында сыра лавкасы тоткан[10].

Чыгышы белән Олы Тормы авылыннан булган Мускеевлар Тәтеш шәһәрендә билгеле кешеләр булалар. Мещан титулындагы бу фамилия төрле сатуалу эшендә дә, укытучылыкта да очрый. 1900 елда шушы нәселнең Бибиәсма Нурмөхәммәд кызы Мускеева губернатор исеменә китап сәүдәсе белән шөгыльләнүгә рөхсәт сорап яза. Ул татар, рус, гарәп, фарсы, алман, француз һәм башка телләрдәге китаплар,башка басма әсбаплар, дәреслекләр белән сәүдә итәргә ниятли[11].

---

[8] Чекмарев П. А. «Есть на Волге городок» (из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана). – Казань, 2004. – 33 б.

[9] Города России в 1904 году. – СПб.: тип. Н. Л. Нуркына, М. Д. Ломковского, Акц. Общ. «Слово», 1906. – 296 с.

[10] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 7905 эш, 1 б. – 69 б. кгз.

[11] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 6959 эш, 1 кгз.




Идел елгасында Тәтеш пристане. XX йөз башы почта карточкасы

Сәүдәнең якынча 20%ы Тәтеш шәһәрендә барса, зур өлеше өязнең зуррак авылларындагы базарларында гөрләгән, алары инде халыкка якынрак та булган, бу базарлар бары тик сату-алу өчен генә түгел, ә аралашу, үзенә күрә идея үзәкләре булып та торган. Мондый базарлар өязнең төрле авылларында атнаның төрле көннәрендә үткән: сишәмбе – Шонгатыда, Яңа Шимкуста, чәршәмбе – Олы Фроловода, пәнҗешәмбе – Кирильскоеда, Ямбактыда җомга көннәре, Кече Яльчиктә шимбә, якшәмбедә – Каратун, Богородскоеда[12]. Базар бу вакытта шактый киң мәгънәгә ия булган сату-алу вакытында биредә күп кенә мәсьәләләр дә чишкәннәр. Мисал өчен, Каратун авылындагы базарда халык Әтрәчнең зиратына дога кылырга баруны да оештырган һәм шунда ук исламга кайту хәрәкәтенең дә идея үзәге булган. Төрле имеш-мимешләр дә бу базарда ишетелгән, җитәкчелек белән дә шунда очрашканнар. Каратунда базар якшәмбе көннәре эшләгән. Каратун базарында тирә-як авыл крестьяннары сәүдә иткән лавкалар тотканнар. Шундыйлардан, Танай Турай авылыннан Сафиулла Ибраһим улы Йосыпов, Шәмбалыкчы авылыннан Садретдин Насыров, Мөхәммәдяфас һәм Ярулла Сафиуллиннар, Кормаш авылыннан Ногман Камалетдинев, Танай Турайдан Латыйф Ибраһим улы Йосыпов уллары Мөхәммәдзакир һәм Мөхәммәдгариф Лапыповлар, Үтәмеш

[12] Список населенных мест по сведениям 1859 г. /обработан А. Артемьевым. – СПб.: Центральный статистический комитет Министерства Внутренних дел, 1866. – С. 96–108.

авылыннан Сабирҗан Әхмәтҗанов, Черки Ишмәк авылыннан Нигъмәтҗан Мәхмүтов, Шигаеводан Кашафетдин Хасанов, Шәмбалыкчыдан Хәмидулла Хәлиуллин улы Зариф Хәмидуллин белән, Түбән Балтайдан Зыяэтдин Сөләйманов, Күкшемнән Нуретдин Әбелханов, Шәмбалыкчыдан Солтан Насыров, Әхмәттән Гайнулла Гайнуллин, Бәбкидән Григорий Пахомович Карабанов, Биябаштан Сафиулла Фатхуллин, Кольчугановадан Гыйльман Хантимеров, Кошта авылыннан Гыймран Гомәрев мануфактура товарлары белән сәүдә итәләр. Ябалак авылыныкы Гыйльман Ногманов шикәр, прәннек саткан, Югары Балтай авылы кешесе Фәсхетдин Фәизев Каратун базарында башлыклар, шикәр, бу якларда кыйммәтле йөргән лимон, Урта Балтайныкы чәй, прәннек, Чүри Бурашныкы Шәфигулла Әдһәмев чәй сервислары, Үтәмешнеке Шакирҗан Сөләйманов фарфор савытлар, Апасныкы Габделкадыйр Ибраһимов шулай ук чәй сервислары, табын кирәк-яраклары белән сәүдә иткән. Иске Энәленеке Шәрәфетдин Миннегалиев чәй, шикәр, прәннек саткан, керосин лавкасы тоткан. Тәүгелде кешеләре Ярулла һәм Вахит Таһировлар шулай ук чәй, шикәр, чикләвекләр сатканнар[13], Килдураз волостена караган авылларда чәй, шикәр, сабын белән сәүдә иткәннәр. Хәзерге Буа районына карый торган Яңа Чәчкапта Гариф Нурмөхәммәтев, Тәүгелдедә Җамалетдин Сәгыйтев, Әхмәттә Гайфулла Гайнуллин, Вахит Габдерәҗәков, Әхмәтсафа Мөхәммәдышин, Куҗакта Бибихәнифә Хөснетдинова, Килдураздан Фәхреҗәмал Хәмитев һ.б. сәүдә хезмәтендә булганнар.

Никифорово волостена караган атаклы Әтрәч авылларында да (хәзерге Тәтеш районы) сәүдә белән шөгыльләнүчеләр күп була. Көндәлек кирәк-яраклары – сабын, чәй, шикәр шырпы, керосин сатучылар: Сабир Гатауллин, Мөхәммәджан Насыбуллин, Габделсаттар Габделбогатов (Олы Әтрәч), Әфләтун Гыйззәтуллин, Габдулла Бикчәнтәев, Тимерҗан Рәхмәтуллин, Хәдичә Фәтхуллина (Кече Әтрәч). Олы Әтрәчтән Габделҗәббар һәм Габделзакир Әминевлар халыктан йомырка җыйганнар. Бу авылларда он тарту тегермәннәре тотучылар да була. Мәсәлән, Олы Әтрәчнең Биктимер Минькин, Якуб Әхмәдиев, Габделнәфигъ Сафин, Муса Мөхәммәдҗанов, Нәҗметдин Хисаметдинев, Кече Әтрәчтән Мәүлед һәм Ибраһим Рәхмәтуллин җил тегермәне, Габделнәфигъ Сафинның ярма ярдыру җайланмасы тотканнар[14]. Никифирово волостенда сәүдә белән шөгыльләнүчеләр һәрбер авылда диярлек булган, 1899 елгы мәгълүмат буенча, Ишееводa – 12, Олы Әтрәчтә – 10, Кече Болгаерда – 8, Танайда – 7 кеше сату иткән.

Тәтеш өязеннән чыккан кешеләр Казанда да сәүдә иткәннәр, үзләренең кибетләрен дә булдырганнар. 1905–1906 еллар мәгълүматы буенча, Тәтеш өязенең Кече Салтык авылыннан Галиулла Гыззәнҗанов Якупов йортында, Газизулла Вәлиулла улы Минькин Апанаев йортында, Сөйки авылыннан

[13] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 13378 эш, 117 б. – 135 кгз.
[14] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 13378 эш, 605 б. – 620 б. кгз.

Николай Варламович һәм Сиражетдин Фәхретдинев Иманколов йортында, Иске Казиле авылыннан Закир Садыйков Казаков йортында, Әлки авылыныкы Зиннәтулла Гыйззәтуллин, Валеев йортында Танай Турай авылыныннан Шәрәфетдин Тәхаутдинев, Таһиров йортында Олы Салтык авылыныкы Галиәсгар Мозаффаров, Монасыпов йортында Болгаер авылынан Сәгадәтбану Ибатуллина, шул ук авылныкы Габделсаттар Рәхмәтуллин Тихвинская урамында ипи һәм башка бакалея товарлары белән сату иткәннәр, үзләренең кечерәк кибетләрен булдырганнар[15]. Олы Тормы авылыннан Йосыф Юнысов Галеев йортларында галантерия товарлары сата торган урыннар тоткан. Мех баш киемнәре, түбәтәйләр, читекләр сата торган кибетләр Юнысов йортында Иске Казы авылының Әфзалетдин Иштирәкев, Әҗем авылыннан Кормаш Шәйхулла улы Фәйзуллин, Атабай авылыннан Мифтахетдин Мөхәммәдгарипов, Гобәйдуллин йортында Иске Йомралының Габделкадыйр Гыйльметдинев, Бәки авылының Сәлимгәрәй Әхмәдкәримев, Юнысовлар йортында Баһаветдин Таҗетдинев тарафыннан ачылганнар[16].

Тәтеш шәһәренең үзендә 7 лавка ел әйләнәсендә эшләп торган, шулай ук 1 кунакханә, 2 шәр хәмер йорты, хәмер базы да булган[17].

Әлбәттә инде, аерым базарлардан тыш, иң зур вакыйга – ул ярминкәләр. Тәтеш өязендә XIX йөз ахырында эшләгән шундый берничә ярминкә билгеле, аларны һәрберсенең үзенең билгеле бер вакыты булган. Мондый ярминкәләр Тәтеш шәһәренең үзендә 8–10 июнь көннәрендә оештырылса, Богородское авылында язгы ташу вакытында, Христофоровка авылында 6–10 июнь, 20–25 сентябрь, Покровскоеда 1 октябрь, Ындырчыда 29–30 июнь, 1–2 июль көннәрендә үткән. Шулай ук Александровка авылында да елга бер үтә торган ярминкә эшләгән. Бу ярминкәләрдә, нигездә, крестьяннар үзләре җитештергән товарлар белән сату иткәннәр, яисә Мәкәрҗә ярминкәсеннән алып кайткан товарларын сатканнар[18]. Тәтеш өязе сәүдәгәрләре күрше өяз шәһәре Буа ярминкәсенә дә йөргәннәр. Мисал өчен, 1912 елда газетада ярминкә халәте хакында түбәндәге хәбәр бирелә: «Буа ярминкәсенә – крещение ярминкәсенә күп сатучы килмәде. Килгәне зарланмады, сату иттеләр. Халык та бик үк хәерче түгел, җәмәгать эшләре булгач, акчалары бар. Ат бәясе күтәрелгән. Рус китапчылары юк, татар китапчыларыннан Кәримевләр[19] кенә бар иде. Хайван азыгының бәһасе ярминкәдә бераз төште»[20]. Бу хәбәрдән күренгәнчә, ярминкәдә китаптан башлап атка кадәр сатылган.

---

[15] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 2606 эш, 253 б., 257 б., 294 б., 334 б., 413 б. – 425 б. кгз.

[16] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 2606 эш, 253 б. – 172 б. кгз.

[17] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 106.

[18] Шунда ук. – С. 69–100.

[19] Бертуган Кәримевләр нәшрияты китаплары.

[20] [Буа ярминкәсе] // Йолдыз. – 1912. – 21 январь.

Даими эшләгән базарларда сәүдәгәрләр тоткан лавкалар, кибет биналары булган, аларның биналары сакланмаган диярлек, әмма кайберләре гасырлар аша узып булса да, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән, җимерек хәлдә яткан биналарның инде тарихы да онытылган. Тау ягы төбәкчесе, журналист Азат Сункишев аларны барлап, тарихларын кәгазьгә төшереп, якташларына җиткерде. Шундый биналарның берсе, Апасның үзендәге Җәләл байның сәүдә лавкасы. Җәләл бай XX гасыр башында Апасның атаклы сәүдәгәрләреннән булган кеше, совет вакытында аның лавкасын кулланучылар кооперациясе кибетенә әйләндерәләр. Азат Сункишев бу хакта Садрый Низамов сүзләренә таянып, түбәндәгеләрне яза: «Җәләл байның буш яткан сәүдә лавкасын аена унике тәңкәдән арендага алып, шул бинада потребкооперация кибете ачып җибәрдек, Тәтештән алып кайтылучы товарлар белән сату итә башладык. Якында гына Кадыйр бай кибете эшләп тора иде – халыкны бай кибетеннән үзебезгә тарту өчен товарларны арзанрак бәядән сатарга керештек...»[21]. Апас базары булган урында гомер иткән Мөхәммәдшәриф исемле кеше кибет тоткан. Үзен кулак дип йортын сүтеп алгач та, таш кибете шул урында кала, совет чорында аның кибетендә инде башкалар сату иткән[22].

Апасның атаклы тарихи биналарыннан берсе – Кадыйр бай Латыйпов йорты, бу бина 1908 елда төзелгән, бинаны төзүче шушы төбәкнең атаклы ташчысы – Ибәтулла Рәхмәтуллин булган. Кадыйр бай йорты янында сәүдә лавкасы тоткан. 1930 нчы еллар башында аның йортын тартып алалар. Бу архитектура истәлеге булган йорт төрле елларда төрле максатларда кулланылган, атаклы ташчының хезмәт җимеше авыр елларны үтеп хәзерге көннәргә кадәр сакланып кала алган[23].

Татар авылларында да кибетләр тоткан кешеләр була. Болын-Балыкчы авылында шундый кибет бинасы сакланган. Аны Спиридон Петрович дигән рус кешесе тоткан, озак еллар татар авылында яшәп, татар кешесе кебек үк гомер иткән, хәтта исемен дә татарчалаштырып «Эспиркә» дип атап йөрткәннәр. Спиридон кибетенең кайчан салынганлыгын Болын-Балыкчыда беркем дә хәтерләми, бары тик халык телендә «революциягә чаклы, гасыр башында, авылның шөһрәтле ташчысы Ибәтулла бабай тарафыннан салынган булырга кирәк», дип кенә сөйлиләр. Спиридон кибетенең малы шактый бай булган, ул мануфактур товарлары белән сату иткән, уллары да аның кәсебендә булган, атлар белән Казаннан товар ташыганнар. Авылның тегермән хуҗасы да Спиридон булган. Моннан кала Болын-Балыкчыда Гыйльметдин һәм Габделхалик исемле абзыйлар авыл халкына чәй-шикәр, йорт кирәк яраклары сатканнар.

---

[21] Сункишев А. Истәлекле биналар, истәлекле урыннар. Беренче кисәк. – Казан: Школа, 2009. – Б. 120.

[22] Шунда ук. – Б. 121.

[23] Шунда ук. – Б. 106.

Сәүдәгәр Спиридонның совет заманы килгәч язмышы аянычлы тәмамлана, кибетендәге малны талап бетерәләр, үзен «зарарлы элемент» дип сөргенгә сөрәләр[24]. Шул ук вакытта татар сәүдәгәре Гыйльметдинне дә авылдан гаиләсе белән куалар.

Көлкәш авылында (Апас районы) сакланып калган кибет бинасы шул авылдагы сәүдә тарихының бер истәлеге. Аны Ярулла бай кибете дип атап йөртәләр, әмма кайчан салынганы билгеле түгел. Ул инкыйлабка кадәрге чорда эшләгән кибет, Ярулла бай кибет тоту гына түгел, ә кибетенә өстәп кондитер фабрикасы эшләү турында да хыяллана, кибет бинасын эшләгәндә үк аңа өстәмә бина тоташтыру өчен урын калдыра. Кибет бинасы Олы Бакырчы балчыгыннан сугылган кирпечтән төзелгән. Зур кибетенә товарны Ялчек, Буа, Казан базарларыннан ташыган. Халык хәтере буенча, аның кибетләре мануфактура товарлары белән сәүдә иткән. Совет елларында аның да язмышы аянычлы юллардан китә, күмәкләшү елларында колхозга керергә ризалашса да, аны алмыйлар «авыл байгурасы» дип атап, Себергә сөрәләр, кибет малын конфискациялиләр[25].

Шәмбалыкчы авылында да (Апас районы) атаклы сәүдәгәр – Хәлил бай яшәгән. Аның 1898 елда төзегән ике катлы, яртысын таштан, яртысын агачтан салган өе төбәкнең тарихи йорты булып тора. Урман кисеп, аны сатып, мунчала ясап мал туплаган Хәлил бай, үз өенең аскы катында сату лавкасы ачкан. Совет дәверендә Хәлил байның да малы талана, ә үзе сөргенгә озатыла[26].

Иске Йомралы авылында инкыйлабка кадәрге чорда 5 сәүдә лавкасы эшләгән, шуларның берсе – Сөнгать байның вак-төяк сата торган кибете. Ул XIX гасыр ахырында төзелгән кибетенең товары 1930 елларда талап алына, үзе кулак дип табылып сөргенгә җибәрелә, әмма ул төзеткән бина озак еллар буе авылдашларына хезмәт итә: иген киптерү өчен склад та була, совет кибете буларак та эшли[27].

Урта Биябаш авылында эшләгән Фәйзрахман бай кибете XX гасыр башында төзелгән, ул Морзалар авылында да кибет тоткан. Шул ук дәһшәтле еллар килгәч, аны таларга килгән җинаятьчеләргә хәләл малын бирүдән баш тарта, алар боерыгына буйсынмаган өчен байга аталар, хатыны дә шушы вакыйгаларда алган яраларыннан берничә көннән соң җан бирә.

Иске Күлкәш авылында Бакырчы кирпеченнән, Бакырчы төзүчеләре тарафыннан салынган бина авыл сәүдәгәре Ярулла байныкы була, үзен

---

[24] Шунда ук. – Б. 116–118.

[25] Шунда ук. – Б. 118.–120.

[26] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энөиклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, 2013. – С. 77.

[27] Шунда ук. – Б. 172.

сөргенгә сөргәнче акчасын кибет диварына кирпеч астына яшереп калдыра, аны бары тик 1970 нче елларда гына табалар[28].

Тәтеш өязенең бик күп авылларында сәүдә итү үзәкләре булган, чөнки халыкның көндәлек кирәк-ярагын канәгатьләндерүдә мондый кибетләргә ихтыяҗ була, шул ук вакытта вак-төяк белән сәүдә итү дә күпмедер табышлы эш саналган. Шундый кибетләрнең берсе – Тәтеш өязе Черкен (Буа районы) авылында Гатаулла кибетен төнлә кереп талап чыгулары, әмма урлаучыланы бик тиз табулары хакында «Йолдыз» газетасы хәбәр дә бирә[29].

Гомумән, сәүдә итү, базарлар һәм ярминкәләр җәмгыять тормышының аерылгысыз бер өлеше. Тәтеш төбәге халкының сәүдәсе бары тик үз өязендәге базар һәм ярминкәләр белән генә чикләнеп калмыйча, киң даирәгә чыккан. Буа, Казан шәһәрләренең базарларында да сату-алу иткәннәр, Мәкәрҗә ярминкәсе бар татарның сәүдә үзәге булган кебек, Тәтеш сәүдәгәрләренең дә елына бер бара торган көтеп алынган сәфәре саналган. Сәүдә татарларның яратып һәм уңышлы шөгыльләнә торган өлкәсе. Халыкны җыя торган сәүдә урыннарын татар җәмгыятенең киңрәк куллануын, ул аны үзенең иҗтимагый үзәге итүне аерым билгеләп үтәргә кирәк.




*Чыганак:* Адам Олеарий. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. СПб., 1906. С. 15

[28] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энөиклопедия: Памятники археологии, истории, культуры, природы, водные и другие объекты. Том. I. – Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, 2013. – С. 173.

[29] Угырлау // Йолдыз. – 1912. – 19 январь.

## § 4. *Ат үрчетү һәм Тау ягында ат караклыгы*

Кешелек тормышын аттан башка күзалдына китерүе дә авыр. Ат кеше белән беррәттән йөк тә тарткан, яуларга да чапкан, яу кырында башын да салган. Һәр мөмкинлеге булган крестьян да ат тотарга тырышкан. Аты булган кешенең генә яшәүдә, көнкүрештә нидер эшләргә, нәрсәгәдер ирешергә мөмкинлеге булган. Ат – ул транспорт та, эш көче дә, сугышчы да.

Россиядә кеше санын алулар булган кебек үк атлар исәбен дә алганнар. 1882 елгы «ат исәбе» алу буенча Казан губернасында 505896 ат исәпләнгән: шулардан, 487767 се авыл җәмгыятьләренеке, 9943 крестьяннарныкы, 8186 сы шәһәрдәге атлар булган. Якынча, 100 кешегә 26,5 ат туры килгән, әлбәттә бу зур сан түгел. Казан губернасы өязләре арасында ат саны ягыннан Чистай өязе халкы байрак булган, анда 76199 ат саналган, ат күбрәк булу, халкы да хәллерәк икәнен күрсәтә торган билге. Тәтеш өязендә 100 кешегә бары тик 21 ат туры килгән, ә бу үз чиратында Тәтеш өязе халкының тормышы җиңел булмаганлыгы хакында сөйли. Авыл җирендә, җир эшкәртү белән көн күргән авыл кешесе өчен бу кечкенә сан. Тәтеш өязе буенча бер хуҗалыкка якынча 1,7 ат туры килгән. Бу яктан карасаң да бу күп түгел. Казан губернасында атлар, нигездә авыл хуҗалыгы өчен кулланылган. Җир эшкәртүче крестьян өчен хуҗалыкта 1, яисә 2 ат булу кечкенә күрсәткеч. Беркадәр вакыт ат кыш көне хуҗалыкта була, кайберләре икмәк ташуда, сату өчен пристаньнарга товар илтүдә, урман кисүдә катнаша.

Казан губернасында атлар үзендә үстерелгән, алар беренче чиратта, йөк аты буларак, тәбәнәк, нык бәдәнле атлар. Ат заводлары Спас һәм Тәтеш өязләрендә Молостововлар, Бакуниннар тарафыннан тотылган[1]. Моннан кала, ат заводлары Казан губернасының Спас һәм Лаеш өязләрендә 5 әр, Казан өязендә 4 әү, Чистайда 1 әү булган. Ә иң эреләре булып А. И. Сахаров, Д. И. Мазалевский, П. М. Останков, В. һәм А.Т. Молостововларныкы булган. Молостововлар заводы 1830 елда ук нигезләнгән иң борынгы заводлардан саналган, аларның атлары чабышларда да танылып өлгергән[2]. XIX гасыр уртасында Кирельское авылында (хәзерге Кама Тамагы районына керә) алпавыт Дратаевский, Сумароков авылының алпавыт Плотников утарларында 35 алаша, 20 колын тотылган, алардан елына 1000 сумга кадәр табыш алганнар[3]. 1909 елгы документ буенча, шәхси ат заводлары хуҗалары итеп

---

[1] Конская перепись 1882 года. – СПб.: Главное Управление Государственного коннозаводства, 1884. – С. 35–36.

[2] Шунда ук. – С. 36.

[3] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 68.

Тәтеш өязе Федоровка авылында поручик Дмитрий Николаевич Сверчков күрсәтелә. Аңарда 2 шәр бия, чабыш аты, җигү аты, 22 эш аты булган. Анненков авылында Вера Николаевна Горемыкина 2 чабыш аты, 2 җигү аты һәм 31 эш аты тоткан[4].

Тәтеш өязе авылларының атлары да сугышларга алынган, әлбәттә инде беренче чиратта, ярлыларның атларын фронтка җибәргәннәр, байлар бу эшләрдән читтәрәк калырга тырышканнар, яисә зәгыйфьрәк атларын гына биргәннәр. Фронтка китү өчен Тәтеш өязе авылларыннан 123 ат әзерләнгән, шулар арасыннан 2–3 ат кына бай кешеләрдән алынган атлар булган. Гади авыл кешесенең бәясе 160–170 сум торырлык атына бары тик 88 сум 70 тиен акча бирелгән, аты алынган игенче җирен эшкәртү өчен кул хезмәте кулланырга, 15–20 сумга эшчеләр ялларга мәҗбүр ителгән. Шушы авыр хәлләрен сурәтләп Тәтеш өязе Шәмәк авылы крестьяннары 1915 елның 25 апрелендә губернатор исеменә хат язалар. Алар хатларында бу дөрес түгел, безнең улларыбыз, ирләребез инде сугышта, атсыз да калабыз, бу хаксызлыкка юл куймагыз, дип үтенәләр[5]. Авылдагы халәтне билгели торган көч – атларның булмавы, яисә азаюы авыл җирлеге экономикасының начар булуын күрсәтә.

*Ат сәүдәсе.* Ат белән сату итү Спас һәм Тәтеш өязләрендә чәчәк ата. Сембер ярминкәсендә бер еллык колыннар XIX гасырда 80–150 сум аралыгында, өчьеллык, дүртъеллык атлар 400 сумга сатылган. Буа ярминкәсендә күбрәк «башкорт нәсел»ле атлар белән сату иткәннәр. Казан сәүдәгәрләре мондый атларны Самара губернасыннан кайтарткканнар, аларны, башлыча, алып-сату өчен алганнар. Спас һәм Тәтеш өязеннән кала, ат базары Казан шәһәрендә дә зур була. Яшь колыннарны сатып алып, аларны әзерләп базарга чыгарганнар. Ат базары, нигездә кышкы вакытта гөрләгән, ат сату, нигездә, татарлар кулында була. Казан шәһәрендә дүшәмбе көннәрендә атна саен ат базары эшләгән, моннан кала, Козьмодемьянск өязендә, Лаеш өязенең Алексеевский һәм Теләче авылларында ат базарлары булган. Лаеш өязендәге базарларга атлар Уфа һәм Самара губерналарыннан, Чар (Царевококшайск) базарынына Вятка губернасыннан китерелгән. Җирле атлар белән Мамадыш өязенең Кукмара базарында сату иткәннәр. Кечерәк базарлар Зөя өязендә, Базарлы Матакта булган. Җәй айларында уза торган базарлар Чар һәм Чабаксар өязләрендә 22 июнь – 1июль көннәрендә үткән, бу базарларда шул төбәк кешеләре эш атлары белән сату-алу иткәннәр, бәяләре чагыштырмача арзанрак саналган атлар сатылган.

[4] ТР ДА, 359 ф., 1 тасв., 506 эш. 7 кгз.

[5] Чернышев Е. И. Народы Среднего Поволжья в XVI – начале XX века. Избранные труды /сост., авт. Предисл., прим., указ. И сокр. И. З. Файзрахманов; под ред. И. К. Загидуллина. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. – С. 112.

*Ат караклыгы.* Тау ягын өйрәнгәндә бу проблеманы да читләтеп үтеп булмый, чөнки бу төбәкнең ат урлау буенча да «даны» чыга. 1882 елгы ат исәбен алу документлары буенча, Казан шәһәреннән кала, Казан губернасында ат урлау очраклары күп түгел диеләә, әмма елына якынча 100 ат урлана торган була. Тәтеш өязендә ат урлау очраклары елына 10–12, ә иң күп ат караклыгы Чуел (Цивиль) өязенә туры килә, монда 35 очрак[6]. Чуел өязенең Чүти авылы кешесе Шәкүр Рәхимов һәм аның командасы «ат урлау» буенча тирә-якта «танылу ала». Ат урлау, нигездә, җәй көннәрендә барган. Гадәттә, болыннарда утлап йөргән атларны урлаганнар. XIX гасыр ахырында ук Зөя һәм Тәтеш өязендә ат урлау вакыйгалары халыкны борчуга сала, урланган атлар, гадәттә табылган, хуҗаларына аларны сатып алырга тәкъдим иткәннәр. Атның кайда булуын, хуҗа аны сатып ала алуы хакында хәбәр бирүче махсус кешеләре булган. Урлап сатучылар ат өчен 20–30 сум сораганнар. Ат урланганын хакимият органнарына әйткән очракта урлаучылар аңа зыян салачагын белгәннәр. Шуңа күрә, белгертми генә үзләре эзләп табып, үз атларын урлаучыдан сатып ала торган булалар. Шундый бер вакыйга 1870 елның 23 еннән 24 июнь төнендә Бортас авылы крестьяны Козьма Тутаев йортында була. Ябылмый калган арткы капка аркылы аның бер атын алып чыгып китәләр. Озакламый ат табыла да, хуҗа үз атын 20 сум түләп кире кайтара. 1870 елда крестьян Антон Семенович Абызовның 2 аты болыннан юкка чыга, Иван Яковлевич Журавлевның өч аты урлана. Тәтеш ягында эш иткән ат каракларын тоталар: алар Күпербаш авылыннан Тимербай Миндубаев, аның туганы Гыйльметдин, Тимергали Минкиннар, Балчыклыдан Шакир Хисмәтуллин, аның атасы Хисмәтулла Сәйфуллин, Төхвәтулла Сәйфуллин, Исхак Ильясов, Иске Казиле авылыннан Морат Габдерәфиков, аның улы Сафиулла (рәсми документлар буенча Илья Петров). Кайберләре, әлбәттә, ат караклары булуларын танымыйлар. Бу хәлләрдән соң Шакир Хисмәтуллин белән Илья Петровны төрмәгә утырталар. Гыйльметдин Миндубаев ат урланганнын белгерткән очракта ат хуҗасын куркытучы, янаучы буларак таныла. 1870 елда 6 йорттан 9 ат урлана һәм урланган бар атлар да Тимербай һәм Гыйльметдин Миндубаевлардан, Морат Габдерәфиков, Төхвәтулла Сәйфуллин, Исхак Ильясовлардан сатып алынган[7]. Исемнәрдән үк күренгәнчә бу «кәсеп» белән аталы-уллы да, туганнары белән бергәләп тә шөгыльләнгәннәр. Тау ягында ат урлау күренешләрен зур «кәсеп»кә әйләндергән һәм үз гамәлләре белән тирәяк халкын куркытып торган, хәтта хакимият органнарыннан да шүрләмәгән зур команданы Шәкүр Рәхимов оештыра.

XX гасыр башында ат карагы булып тирә-якта танылган Шәкүр Рәхимов озак еллар дәвамында бу кәсеп белән көн күргән нәсел дәвамчысы. Ат урлау

[6] Конская перепись 1882 года. – СПб.: Главное Управление Государственного конноводства, 1884. – С. 35–36.

[7] ТР ДА, 1 ф., 3 тасв., 2483 эш. 1 б. – 9 кгз.

уйланылган система буенча алып барылган, әгъзалар арасында вазыйфалар бүленгән була: кемдер атны алып китә, башкасы яшерә. Аның авыл саен «күз-колагы», үз кешесе, шымчысы булган. Тактикасы кыю һәм шулвакытта көтелмәгәнчә хәйләкәр була, хәтта печән олавын күздән югалтырлык итеп яшерү урыннары тотканнар, артка себерке тагып барып эз югалтканнар. Урланган атларны Казан шәһәрендәге Мокрая урамында (хәзерге ЦУМ кибете) урынында сатканнар. Бу зур көчле банда тирә-як авылларын куркуда тоткан. Сарык 20 сум, сыер 50 сум бәя белән йөргәндә, яхшы атның бәясе 200 сумнан башланганны исәпкә алсак, ат югалту авыл кешесе өчен дә, шәһәрнеке өчен дә зур югалту икәнлеге аңлашыла. Шәкүр карак командасы караклары атларны Мәскәү асты, Себергә кадәр барып урласа да, үз авылдашлары Чүтиләрнең атларына тимәгән. «Шәкүр карак» дип сөйләсәләр дә, әмма аңа карата дошманлык сизелми. Чаялыгын, зирәклеген сөйлиләр, берничә хәйләсе дә әле исемдә, дип искә алган шагыйрь Шәүкәт Галиев.

Шәкүр Рәхимов оештырган ат урлаучылар бандасын озак еллар кулга алу, җәза бирү мөмкин дә булмый. Совет елларында гына аларга җинаять эше ачыла һәм аларны хөкем ителәләр. Озак вакыт дәвамында барган тикшерү процессының нәтиҗәсе буларак гаепләү эшләре бик күп том тәшкил итә. «Шәкүр бандасы»ның җитәкчелеге Шәкүр Рәхимовка якын, ышанычлы кешеләрдән оештырылган була. Үзе җитәкчелектә булса, төркемнең аерым тармаклары белән уллары Сабир, Миңнегали, ир туганнары Зиннәтҗан һәм Гариф Мәҗитовлар идарә иткән. Карап торышка әлләни көчле кебек тә булмаган, гарибрәк кеше тәэсире калдыра торган Зиннәтҗан ярминкәдән 17 ат урлап китә алган, моның өчен инде ул берничә мәртәбә төрмәдә утырып чыга. Соңгы елларында ул кемдә нинди ат барлыгын ачыклаучы оста разведчик ролен дә башкара. Гариф Мәҗитов чабыш атларын урлау «остасы» буларак таныла, Шәкүр каракның олы улы – Сабир «тәҗрибәле» «остарган» ат карагы булып җитешә, бу кәсебе өчен берничә мәртәбә төрмәләрдә утырып чыга. Урланган атларга документлар ясау, төрле чиновникларның мөһерләрен «профессиональ» дәрәҗәдә үзгәртү эшен авыл мөәззине улы Мирза Рәхимов башкара. Һәрберсенең үз эш юнәлеше билгеләнгән төркем Тау ягы авылларны гына түгел, хәтта ки Россия төбәкләрен куркуда тота.

Ат татар тормышының аерылгысыз бер өлеше, ул эш көче генә дә түгел, ә татар тарихында аерым бер хөрмәткә ия булган хайван. Тау ягындагы ат урлауны караклык буларак бәяләсәк, ә урлаучылар бу «кәсеп»нең нигезендә атка булган мөнәсәбәт, азарт ята дип тә аңлатырга тырышканнар.

## § 5. *Нефтьле төбәк*

Хәзерге вакытта Кама Тамагына керә торган Сөйки (Сюкеево) тарихи авылларның берсе. Ул Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. 1992 елгы мәгълүматлар буенча анда 812 кеше яшәгән. Тарихи истәлекләр бүлегендә бу җирлектә халык телендә «Кызлар уйный торган җир» дип аталган урын булуы һәм галимнәр тарафыннан 1892 елда тикшерелүе хакында бәян ителде. Бу җирлекнең тарихын, аны нигезләүче – Сөйки дигән татар кешесе белән бәйлиләр. Әмма чыганаклар буенча, аның борынгы чоры буларак Казан ханлыгы чоры күрсәтелә. Шулай булса да, 1384 елга караган Хызр хан тәңкәсе табылу, бу җирлекнең тарихы борынгырак икәнлеккә сылтама ясый, бу урында кечерәк кенә болгар шәһәрлеге булган булырга тиеш дигән фикер бар[1]. Борынгы татар зираты булу, җирләре белән морзалар идарә итү дә бу авыл тарихына кайбер шәрехләр кертә. Бу төбәктә хәзер көн күрүчеләрнең бабалары чыгышлары белән Владимир һәм Ростов өязе кешеләре. Алар 1720 елларда буякларга килеп урнашалар, аларның бирегә күчүләре Петр I реформалары белән бәйле. Күчешләренең беренче чорында Зөя өязе җирләренә тукталсалар, аннан соң Сөйки авылы тирәсендәге урыннарга килеп утыралар. 1813 елда авылда чиркәү салына, 1866 елда земское училище эшли башлый. Авыл XIX гасырда зур авыллар рәтенә кергән, анда 686 утар, 1029 торак йорты була, 3500 кеше яшәгән.

1892 елда Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте галимнәре тарафыннан хәзерге Кама Тамагы районына карый торган Сюкеево дигән рус авылы тирәсендә татар тарихи истәлеге – татар шәһәрлеге җире табыла. Сөйки янында татар истәлекләре булу хакында халык арасында йөргән риваятьләр дә, шулай ук төрле табылдыклар да ишарә итә торган була. Халык хәтере буенча бу шәһәрлек урыннары җирле халык телендә «Кызлар уйный торган җир» дип аталып йөргән һәм аның мәйданы 125000 кв м, ике бик биек булмаган вал белән әйләндереп алынган. Бу – аның соңгырак чорда да, Казан ханлыгы вакытында да, яшәгәнлеген күрсәтә торган билге[2]. «Татарское жилище» дип аталган урын Сюкеево авылыннан көньяк-көнчыгыштан 3 чакырым тирәсендә, шунда ук башка шәһәрлек шул ук юнәлештә 5 чакырым тирәсе ераклыкта урнашкан. Шәһәрлекнең саклану тирәлеге, ныгытмалары булмый, чөнки аның тирә-ягы болай да чокырлы, үзе тау башынна урнашкан булган. Шәһәрлектән бераз читтәрәк зират бар, ул шул шәһәрлек каберлеге булырга тиеш. XVI гасырга – XVII гасырга кадәр

[1] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 320.

[2] Халиков А. Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. – Казань: Фэн, 1994. – С. 70–72.

монда татарлар яшәгән. Хәтта аларның мәчетләре дә булган. XIX гасыр ахырында да Сөйки янында борынгы нәсел морза җирләре булган, бу морза нәселләре вәкилләре соңрак вакытта Тәтеш өязенең төрле татар авылларында гомер иткәннәр. Сөйки тирәсендә имәннәр үскәнгә, аны Дубрава (Имәнлек) дип тә атаганнар. Бу җирдә борынгы чорның мәгарәсе сакланган. Чыганакларда күрсәтелгәнчә, мәгарәнең эче шома диварлы, төгәл формалы, ә аның эчендә күл булган, күлнең суы күкерт-водородлы газ катнашмасыннан тора. Сөйки авылы янында да күкертле чишмәләр шактый булганы билгеле[3]. Бу мәгарә Казан губернасының күренекле курганнары һәм шәһәрлеге исемлегендә йөргән, хәтта бу 1879 елда Мәскәүдә узган антропологик күргәзмәдә дә күрсәтелә. Кызганыч, бу мәгарәнең тарихы 1858 ел белән тәмамлана, Куйбышев сусаклагычын эшләгәндә ул су астында кала[4].

Бу авылның үзенчәлеге – ул аның табигате, табигать казылмалары. Сөйки авылы янында күкерт аланы дигән урын була, борынгы вакыттан ук монда күкерт чыккан[5]. С. Шпилевский XVI-XVII гасыр патша грамоталарында бу урын күкерт аланы дип атала, дип яза. Михаил Федорович чорына караган грамотада Зөя татары Ямбулат бу урынны тасвирлый: «есть де за рекою за Волгою, за Чертыком, против сернова городища пусточные сенные покосы лежат в пустее, а межа тем сенным покосам – верхняя межа Бездна нижняя, а нижняя межа Кривое озеро. Чертык, Бездна и Кривое оз[еро] (означенное на рукописной карте Каз[анского] ун.[иверситета] находятся по лев[ую] сторону Волги, против с. Сюкеева»[6]. Бу тасвирламада аның урыны төгәл күрсәтелә[7]. Долгая Полянага таба яр буйлап күкертле-нефтьле су саркучы чишмәләр бик күп булган. Шунда яшәүче җирле халык хуҗалык өчен су өстенә чыккан нефтьне җыйган, әмма бу шөгыль катлаулы, әлләни файда китерерлек булмаганга зур үсеш алмаган. Аннан, бары тик дәвалаучылар, имчеләр генә дәвалауда куллану өчен җыя торган булганнар[8].

[3] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 136.

[4] Абдуллин Х. М. «Списки курганов и городищ, наиболее замечательных в Казанской губернии» антропологической выставки 1879 г. как источник по средневековой истории региона // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2021. – № 4. – С. 71–80.

[5] Приволжские города и селения в Казанской губернии с картой р. Волги и рисунками. Репринтное издание. – Казань: ТаРИХ, 2008. – С. 194–195.

[6] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 319–320.

[7] Шунда ук. – С. 320.

[8] Военно-статистическое обозрение Российской империи. Том V. Казанская губерния. – СПб.: Тип-я Департамента Генерального штаба, 1850. – С. 140.

Бу төбәк – Татарстан җиренең нефть ятмаларының зур хәзинәсе дә. Казан губернасы җирләрендәге нефть турында 1637 елда ук Пушкарский приказ[9] материалларында искә алына. 1703 елда чыккан «Ведомости» газетасы битләрендә дә нефть табылу турында Казаннан хәбәр бирәләр. Императрица Анна Иоанновнага 1738 елда Тәтеш тирәсендә кара алтын ятмалары булуы хакында белдерелә. Тәтеш төбәгенең Идел яры буйлап табигать байлыгы ятмалары булуына А. П. Иванов 1913 елда биргән отчет-тасвирламасында да ассызыклый. 1837 елда инженер Александра Гернгросс Идел алды һәм Кама арты өслекләрендә нефть булуын ачыклый. 1864 елда инде Бөгелмә алпавыты Николай Малакиенко казу эшләрен башлап җибәрергә беренче омтылыш ясый. Бу эш елдан ел камилләшә, яңа ысуллар белән табигать байлыгына юл табарга тырышулар арта. Н. Головкинский 1869 елда «Описание геологических наблюдений в Казанской и Вятской губернии. Материалы для геологии России», 1904 елда А. П. Ивановның «Нефтяные источники Поволжья», 1911 елда Н. Мазаровичның «Дислокационные явления в области Свижско-Волжского водораздела»[10] һ.б. тикшерү хезмәтләре дөнья күрә. Хәзерге Татарстан җирләрендә нефть эшкәртү XVIII гасыр урталарында инде башлана да, 1877 елда геолог Ласло Шандор яңа ятмаларны тикшерә, шул вакытларда Шөгер нефтебитум заводы эшли башлый. XX йөз башында нефть эшенең колачы киңәя, 1913 елда инглиз финансистлары акчалары белән немец инженер-геологы һәм эшкуары А.Ф. Френкель оештырган «Казан Ойлфилд ЛТД» исемле акционерлык компаниясе Сөйки авылы тирәсендә нефть ятмалары эзли.

Татарстан җирендә нефть төбәге дип Әлмәт ягы, иң беренче булып нефть суыртыла башлаган Шөгер төбәге атала. Монда рәсми рәвештә 1943 елдан башлап нефть суырту алып барыла. Тау ягының XX гасыр башында ук ачыкланган нефть ятмалары, аларны өйрәнү, аларның тасвирламалары бары тик тарих булып кына кала.

1913 елда бу урыннарда галимнәр тикшергән вакытта бу табигать байлыгы киләчәккә шактый зур өметләр бирә. Моны аның тасвирламасы аша ачык күрергә була. 1913 елда А. П. Иванов төзегән әлеге тасвирлама тексты кушымта өлешендә тәкъдим ителә (Кушымта № 16). Ул иң беренче булып бу урынны караган П. Головкин фикерләре белән килешмичә, Сөйки авылы янындагы нефть чыганагы, башка җирләрдәге кебек үк, җирнең бик тирән катламыннан күтәрелгән, биредә җәйге кызу көннәрдә урыны-урыны белән куе нефть чыгып торган урыннар була. Кызганычка каршы, нефть ятмалары

[9] Пушкарский приказ – Иван IV вакытында Россиядә хәрби идарәнең үзәк органы. Рус дәүләтендә инженерлык эшчәнлеген гамәлгә кую һәм контрольдә тотуда вазыйфаларын үтәүче беренче беренче дәүләт оешмасы буларак билгеле.

[10] РДТА, 58 ф., 2 тасв., 765 эш, 1–5 кгз.

булган кайбер урыннар су күтәрелү сәбәпле, хәзерге вакытта су астында калган.

А. П. Иванов ясаган нәтиҗәләр буенча, Сөйки авылы янында нефть ятмалары булуга гына ишарә түгел, ә чын мәгънәсендә әзер нефть ятмасы булу хакында «здесь в недрах имеется нефтяное месторождение огромной мощности»[11], дип бәя бирә. 1913 елга инде ул өлгереп җиткән генә түгел, ә казу скважиналары белән суырту өчен үзлеген югалтып бару дәрәҗәсенә җиткән. А.П. Иванов бу җирлектә нефть суыртыла башлавына шикләнми, ул бары тик скважиналар куйганда нинди ялгышлыклар җибәргә ярамаганын күрсәтә һәм дә үзенең киңәшләрен бирә. Әмма ләкин Тау ягының нефте әлегә кадәр кулланылмый, Әлмәт ягында нефть табылу белән, ни сәбәпледер бу ачышлар онытыла. Җирле халык бу төбәктә совет елларында да нефть ятмаларын күзәтеп геологларның йөргүен хәтерли. Киләчәктә бу төбәкнең нефть ятмаларына игътибар арту бик ихтимал.

[11] Шунда ук.

# § 6. Беренче Бөтендөнья сугышы чорында Тәтеш төбәге халкы: тыл һәм фронт

Кайсы гына сугыш булса да, беренче чиратта авыл кешесе, гади крестьяннар җилкәсенә төшә. Авыр тормыш көткән гади кеше өчен Беренче Бөтендөнья сугышы башлану зур кайгы алып килә. Тормышының очын-очка ялгап яшәгән крестьян, сугышка якыннарын, атын да, хәтта азык-төлек тә әзерләп тә бирергә тиеш була. Сугыш, кайгы-хәсрәте белән, бер яктан матди кыенлык алып килсә, икенче яктан, рухи газаплар өсти.

Сугыш башлану хәбәре кызу урак өсте барган Ураза аена туры килә. Кызуда ашамый-эчми көннәр буе басуда булган ир-атларны сугышка җыю башлана. Сугыш шартларында мөселман гадәтләрен үтәү, шәригать кушканны эшләү өчен мөмкинлек булмаганны аңлаган татарларга бу кайгы өстенә кайгы гына өсти. Сугыш бәетләрдә дә солдатларның ураза тотып бетерә алмауларына, киләсе Гаетләрне күрә алу-алмауларына борчылулары чагыла. Тәтеш өязеннән сугышка алынучы тарафыннан чыгарылган бәеттән аның беренче көннән үк сугышка алынуы, гаиләсе белән аерылышу хәсрәте күренә: «Җомга көнне сәгать унда илдин чыгып кителде.

Шинбә көнне сәгать унда Тәтешкә барып җителде.

Ике балам ике җакка бәне кочып ятканнар.

Җомга көнне иртәгәч

Безне илдин кудылар.

Әткәй-әнкәй, туганнарым

бездин мәхрүм калдылар»[1]. Татар солдатының сугышка алынуны «сугышка куылу» дип сөйләве дә аның сугышка китүне ничек кабул итүен ачык чагылдыра торган гыйбарә. Казан хәрби округы буенча сугышка алулар 18 июльдә башлана, ә аның артыннан ук 20 сентябрьдә, 30 декабрьдә киләсе дулкыннары була[2]. 1915–1916 еллар аралыгында барлыгы 12 мәртәбә мобилизация үткәрелә[3], 1917 елда 1 февраль һәм 1 мартта кабат ике мобилизация кампаниясе эшли[4]. Ашыгычлык белән башкарылган бу кампанияләрдә сугыштан азат ителәсе кешеләрне әлләни барлап тормаганнар. Шунлыктан, күпбалалы аталар да, гаиләдәге бердән-бер ир дә, еш кына авыру-сырхау да

---

[1] Сугыш һәм солдат бәетләре /Төз. Р. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – Б. 76–77.

[2] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С.23.

[3] Шунда ук. – Б. 40.

[4] Шунда ук. – Б. 51.

бу хәлләрнең һәлакәт дулкыны белән утка барып керә. Беренче чиратта запастагылар алынганганга, сугышка китүчеләр арасында күпчелекне төп эшче көч – эшкә яраклы урта яшьтәге ирләр тәшкил иткән. Беренче Бөтендөнья сугышы чорында 43 яшькә кадәр булган ир-атлар хәрби бурычлылар исәбенә кергән. Генераллар һәм офицерлар 50 яшькә кадәр сугышка алына алганнар. Үз теләкләре белән сугышырга теләүчеләр өчен яшь чикләве булмый[5]. Шуңа күрә дә, солдат яшенә килеп җиткән улыннан бигрәк, гаилә башлыклары, аларның аталары сугыш кырына китә. Гаиләдән берничә ир-атның сугышка алынуы, авыл кешесе өчен, бигрәк тә, урак өсте барган чорда да булуы гаять авырлык тудыра. Татар бәетләрендә дә бу хәлгә өзелеп, карт солдатлар киткәндә, җилләр генә түгел, ә ил елый, дип бәян ителә. Солдат хезмәтен үтү бер хәл булса, солдаттан күптән кайткан ирләрнең билгесезлеккә чыгып китүе халык өчен аерым зур кайгы булган. Түбән чиндагы сугышчылар, нигездә, авыл кешеләре булганлыктан, беренче чиратта сугыш авыл тормышына зыян сала. Беренче Бөтендөнья сугышы дәвамында 19 миллион кеше мобилизацияләнгән, бу – Россиянең шул чордагы 10,5 % халкы дигән сүз. Сугышның беренче елында бары тик Казан губернасы буенча гына да 290 мең ир-ат сугышка алына, бу – губернаның 10,7 % халкын тәшкил итә, эшкә яраклылардан 44,8 %ы сугыш кырына китә[6]. Моннан кала, сугыш тылдагы һәрбер кешенең язмышына үз эзләрен салмый калмый, авыл кешесе сугышка гаилә әгъзасы дәрәҗәсендә кадерле булган атын да бирергә мәҗбүр ителә. Авылның гади кешеләре, инде ирләребезне генә түгел, ә соңгы, ябык кына атыбызны да алалар, нигә байлардан алмыйсыз, безнең атны аласыз дип тавыш та куптарып карыйлар[7].

Солдат хезмәтен үткән ирләр сугыш авырлыгы белән бер дәрәҗәдә ислам йолаларын тоту мөмкинлеге булмауга, ашауның хәләл, үлемнең җеназасыз булуына борчылалар. Татар-мөселман кешесе өчен болар яшәү белән үлем дәрәҗәсендә торырлык мөһим нәрсәләр, әмма сугыш бу таләпләрне үти алмый, шулай да сугыш шартларында да мөселманнар өчен рухи әйдаманнар – муллалар билгеләү мөмкинлеге булдырыла. Дәүләт тарафыннан билгеләнгән муллалар мөселманнарның сугышка алынуына, аларның бу язмышка буйсынуларына күп тырышлык куялар. Татар авылларындагы мобилизациянең тиешле дәрәҗәдә оештырылуы авыл мулласының да бурычы итеп кабул ителгән. Сугышка солдат җыю җиңел генә бармаган. Солдат хезмәтенә китү дә элек-электән үлемгә китү белән тиңләштерелгән, берсе дә кире әйләнеп

[5] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 24.

[6] Шунда ук. – С. 41.

[7] Чернышев Е. И. Народы Среднего Поволжья в XVI – начале XX века. Избранные труды /сост., авт. предисл., прим., указ. и сокр. И. З. Файзрахманов; под ред. И. К. Загидуллина. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. – С. 112.

кайтуына өмет итмәгән, ә сугышка китү бигрәк тә куркыныч була. Шунлыктан, китми калу өчен төрле юлларын табарга тырышканнар: ач торып хәлсезләнгәннәр дә, әгъзаларына да зыян салганнар[8]. Мисал өчен, 1915 елда, Казан гарнизоны буенча гына да, 22 % солдат хәрби частька килми йөри, шул ук ел мәгълүматы буенча 1,3 мең кеше качкынлыкта саналган[9]. Качып йөрүчеләр күп булу сәбәпле, 1915 елның ахырында дезертирларны күзәтү һәм полиция участогына китереп тапшыруны оештыру тиешлеге хакында махсус документ та булдырыла[10]. Дезертир барын сизми калган өчен авыл старосталарына шактый штрафлар салына, еш кына авыл халкы дезертир барын белдерми, хәтта авылы белән аны яклап чыккан очраклар да билгеле[11]. Шул ук вакытта улының качып кайтуын хакимият органнарына, хәтта, атасы барып әйткән очраклар да була[12]. Бу мисаллардан да, кешеләрнең сугышка булган мөнәсәбәте төрле икәнлеген аңлашыла.

Тәтеш өязе халкында да килеп туган хәлләргә ризасызлык белдерергә җөрьәт иткән кешеләр дә билгеле. Шундый бер мисал, Тәтеш өязенең Олы Яңасала авылы кешесе Җәләлетдин Шәрәфетдиневне патшага каршы булган һәм Кызыл Хач оешмасына акча җыюга ризасызлык белдерүдә гаеплиләр. Әлбәттә, авыр тормыш алып барган авыл кешесе өчен мондый өстәмә түләүләрнең дә өстәлүе ризасызлык уята. Крестьян гаиләсе өстенә төшкән авырлыкларны кемдер тәкъдир дип, сүзсез генә кабул иткән, ә кемдер фикерен белдерергә батырчылык кылган. Җәләлетдин Шәрәфетдинев тәрбиясендә 5 баласы, карт ата-анасы була, шуның өстенә әле бертуган энесе дә сугышка алынган. Ул 1914 елда авыл җыены вакытында халыкның тормыш авырлыгы турында белдереп, авыл җәмгыятенә акча җыю өчен байрак кешеләргә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим ясый. Аның «патшаның акчасы булмагач, сугыш башламаска иде», дигән җан әрнүен ишетү белән авылдашы крестьян Шәйдулла Җәгъфәрев аның өстеннән донос яза. Әлбәттә, доносчы очын-очка ялгап көн күргән крестьянның җаныннан әрнеп чыккан сыкравына куәтле тон биреп, аны гаепләрлек җирлек әзерли. Кызганычка каршы, мондый очракларда үпкә, дошманлыкны бер-берсеннән үч алу өчен куллану җирлеге итү очраклары булып торган. Бу очрак та шулар рәтеннән булса кирәк. Әлеге вакыйганы тикшерү өчен ахун Мөхәммәдзариф Галиәкбәревтән һәм 8 авылдашыннан урядник, полиция сакчысы катнашында сорау алулар узган. Авылдашлары доносчының Җәләлетдин Шәрәфетдинев белән күптәннән конфликта булуын, бу – аңа яла ягу өчен эшләнгәнен расласалар да, Казан

---

[8] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 37.

[9] Шунда ук. – С. 42–43.

[10] Шунда ук. – С. 53.

[11] Шунда ук. – С. 54.

[12] Шунда ук. – С. 55.

жандармериясе «эшне» ябарга карар кылса да, Казан губернаторының әмере буенча, сугыш беткәнчегә кадәр Җәләлетдин Шәрәфетдинев Казан губернасында яшәү хокукыннан мәхрүм ителә. 1914 елның 22 декабрендә ул күрше Сембер губернасына барып, Әхмәтҗан Мөхәммәт Ильясовның чәй лавкасына эшкә урнашырга планлаштыра, ә 80 яшьлек атасы Шәрәфетдин Хәйбуллин аны туган авылына кайтаруны үтенеп Казан губернаторына хат яза. Карт зур гаилә белән бер ялгызы калуга, үзе генә бу гаиләне туендыра алмаячагына зарлана һәм шул ук вакытта, бер улының фронтта булып, зур яуларда катнашуын да күрсәтә. 1915 елның 23 февралендә, улы Җәләлетдингә авылга кайтырга рөхсәт бирелә, картның бер улының сугышта булу факты да бу вакыйганы уңай хәл итергә этәргән булуы ихтимал[13].

Сугыш елларында солдатларның гаиләләренә хөкүмәт тарафыннан беркүпмедер ярдәм булган. 1970 елгы археографик экспедициядә хәзерге Апас районына карый торган Аю Көйдергән авылыннан табылган бер хатта ананың улы Фәсәхетдингә язганнарыннан тылда солдат хатыннарының ничек көн итүләре, нинди түләүләр алулары күренә: «вә һәм бу да мәгълүм булсын, солдат хатыннарына чыккан акчаның һичбер рәте юк. Габдулла Гатаулла улының һәрбарча җәмәгатенә дә җан башына өчәр сум, бәгъзысенә җан башына икешәр сум, кайсына бер сум ярымышар, кайсыларының берәр баласына юк, кайсы солдат хатыннарына да юк бу юлы. Бер дә порядка юк әле. Икенче мәртәбә ничек булыр – белмибез»[14]. Шул ук вакытта ана бу акчалар гаиләгә бер шатлык та алып килми дип сыкрый[15]. Солдат гаиләләренә дәүләт тарафыннан да, иҗтимагый оешмалар тарафыннан да төрле ярдәм бирелгән, хәтта ярлылар өчен җәмәгать ашханәләре дә эшләгән. Һәрвакыттагыча, җәмгыятьтә төрле кеше бар, бер ишеләре түләнә торган акчалар улыңны, иреңне алыштыра алмый, шатлык китерә торган акча түгел дип хәсрәтләнсә, кайберләре дәүләт биргән акчага сөенгән дә. Солдатларга карата «Үлмәсен дә, кайтмасын да, чыгып торсын акчасы», дигән мөнәсәбәтнең дә солдаткалар арасында булганын фольклор белгечләре тарафыннан теркәлгән[16].

Сугыш шартлары, әлбәттә тыл тормышыннан күпкә киеренке булган. Сугышның 40 ае дәвамында Россия армиясенең югалтулары шактый зур

[13] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 30–31.

[14] КФУ КСКБ. 2435 т.

[15] Сәлахова Э.К. «Каләм әйтә: тагы бераз язасы, китә төшсен солдатларның мазасы» (Беренче Бөтендөнья сугышы чоры хатлары) // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2016. – № ¾. Б. 186–197.

[16] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 245.

була, әмма хәзерге көнгә кадәр төгәл сан аталганы юк. Төрле авторлар яу кырында үлүчеләрнең санын 600 000 башлап 4 500 000 гә кадәр булган дип саный. Иң зур югалтулар сугышның беренче чорына – 1914–1915 елларга туры килгән[17].

Сугышка алынучылар арасында мөселманнар шактый була, ә шуларның күпчелеген татарлар тәшкил иткәннәр. Алар гади солдатлар гына түгел, ә югары чиндагы хәрбиләр рәтендә: генераллар да, офицерлар да булганнар[18]. Сугышта 1 миллионнан алып миллион ярымга кадәр төрки солдат катнашкан, бу – армиянең 10%ы дигән сүз[19]. Мөселман солдатларына рухи халәтләрен тоту өчен сугышка гаскәри муллалар да алынган. Шундыйлардан, тумышы белән Тәтеш өязенең Олы Яңасала волостеннан булган Казанның Бишбалта имамы 26 яшьлек Исмәгыйль Габитов та сугышка китә, Тәтеш өязе Казиле авылыннан булган Казанның Алафузов фабрикасы мәчете мөәззине дә, сугыш өчен эшли торган фабрика эшчеләренә мөәзиннең үзләренә кирәклеген, аны калдыру турында сорасалар да, мөәззинне сугышка алалар[20].

Сугыш кырында татар солдатын борчыган нәрсәләр ачлык, суык һәм үлемнән кала, аның рухи халәтенә кагылу: дини, милли тәртипләрне, гадәтләрне үти алмау, җитәкчелек тарафыннан аларның бу үзенчәлекләренә игътибар булмау, татар авылыннан алынган, гомере буе үз телендә генә аралашкан татар солдатларына үзара татарча аралашуны тыю. Бары татар булганы өчен генә дә югары дәрәҗәләргә билгеләмәүләре дә башкалар белән беррәттән кан койган татар өчен кимсетү буларак кабул ителгән[21]. Татарларның бәетләре солдатларның эчке халәтен күрсәтүче көзге буларак, аларның бар моңзарларын, бу хәлләргә мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Озакка сузылган сугышның мәгънәсезлеге дә, аның чын йөзен дөрес күрсәтмәү дә җанын сыкрата, ул аны бәет аша, хатлары аша

«Бу сугыштан файда юктыр күзгә күренгән бер дә,

Шуның өчен мин язамын мәгълүм булсын дип сезгә», дип җиткерергә тырыша. Еш кына фронттагы солдатлар сугыш кырында чын мәгънәсендә ни барганын да белмиләр, алар хатларында туганнарына бу хакта ниләр сөйлиләр, ниләр язалар соң дип сорап язалар[22]. Сугышта мөселманның мөсел-

---

[17] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 56.

[18] Шунда ук. – С. 58–59.

[19] Шунда ук. – С. 89.

[20] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 9614 эш.

[21] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 89–90.

[22] Салахова Э. К. Первая мировая война в судьбе татарского народа: взгляд через призму писем татарских солдат // Народы Поволжья и Приуралья между революциями

манга каршы барырга мәҗбүр булуы да Ходайның бер сынавы була, татарның ике ут арасында калып «януы да» бәетләрдә һәм мөнәҗәтләрдә чагыла:

«Дунай суын чыккачдин
Утырттылар олауга.
Хәтта йир-күк иңрәде
Мөселманнар йыглауга.
Зәңгәр мәсҗид, яшел михраб
Торадыр ла ялтырап.
Ядрә килеп тигәчдин
Солдат китә калтырап»[23].

Шушы авырлыкларның барысын да үз җилкәсендә алып барган татар хәрбие барыбер үзенә куелган бурычны үтәргә тырышкан. Татарлар арасында сугышчан батырлыклары өчен берничә мәртәбә югары дәрәҗәле орден-медальләр алган кешеләр бар. Кушымтада китерелгән исемлектә Тәтеш өязе авылларыннан сугышка китеп, орден-медальләр белән бүләкләнгән хәрбиләрнең исемнәре күрсәтелә (кушымта № 17), алар арасында татар фамилияләре дә шактый. Рус телендәге документларда татар исемнәренең еш кына бозып язуларын беләбез, төрле документларда бер үк исемнең берничә төрле күрсәтелүе дә мәгълүм, шунлыктан, кайвакыт бер үк кеше берничә тапкыр да теркәлгән булуы ихтимал. Шулай булса да, аларны дөресләп, төзәтеп язуны кирәк дип санамадык, чөнки укучыга үз бабасын башка чыганаклардан да табу өчен бу вариантлар турында да хәбардар булу кирәк.

Һәр сугышның озак вакытка кадәр бара торган кайтавазы ул – әсирләр, аларның язмышлары. Сугыш дәвамында 8 миллион хәрби чиндагылар, 200 меңнән артык кеше әсирлектә була, күпме татар әсирлектә булганын әйтү авыр, әмма якынча 50 мең мөселман әсирлек газабын кичерә. Сугышка психологик әзерлексез кергән гап-гади солдатлар иң беренче булып әсирлек коллыгына барып кергәннәр, әлбәттә, әсирлекне гомерне саклап калуның бердән-бер юлы буларак та кабул итүчеләр була. Тоткындагы әсирләрнең хәле җиңел булмый, иң авыр эшләр дә, төрле җәзалар да була, әмма шул ук вакытта әсир мөселманнар үзләренең дини гореф-гадәтләрен үтәү мөмкинлеге булган шартларга эләгүләренә канәгатьлек тә кичерәләр. Мисал өчен, Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында Вюнсдорфтагы әсирләрнең хәтта мәчетләре, китапханәләре, хәтта халык инструментлары оркестры да булганын, газеталары да чыкканын тарихчы И. А. Гыйләҗев билгеләп үтә[24]. Әсир-

(1905–1917 гг.). Сб. Статей. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – С. 370–378.

[23] Сугыш һәм солдат бәетләре /Төз. Р. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – Б. 38–39.

[24] Гилязов И. А. На другой стороне. Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны. – Казань: Мастер Лайн, 1998. – С. 38–43.

лектәге солдатларның алдагы тормыш юллары төрлечә булган, кемдер әсирлектән котылып туган җиренә кайту бәхетенә дә ирешкән, кайсылары шунда үлгән, кемдер бөтенләйгә дә чит җирдә яшәп тә калган. Мисал өчен, дини яктан иреклек алу мөмкинлеге булган Госманлы җирендә шактый мөселман төпләнеп кала. Хәзер дә бабаларының шушы вакыйга белән төрек җиренә килеп чыгуын хәтерләүчеләр бар. 1916 елда Россия армиясенең 9 мең әсире Госманлы җирендә калырга теләк белдергән[25].

Әсирлектә лагерь газабын узучыларның хәсрәтләрен, аларның кичергән җәзаларын үзендә саклап бүгенге көннәргә кадәр җиткергән чыганакларның берсе – ул әсирләрнең җырлары язмасы, шуларның берсе – «Әй, заман, заман» А. Фәйзрахманов тарафыннан эшкәртелеп, фольклор ансамбле башкаруында татар әсиренең күңел халәте җанландырылды. Солдат хатлары, шул исәптән, әсирләр тарафыннан язылган хатлар да тарихның бу сәхифәләрен халык җаны аша ачып бирә. Шундый хатларның берсендә Тәтеш өязе Урта Балтай авылының Әфзәлетдин Җамалетдин улының Германиянең Шнейдемюлле лагеренә эләгүе хакында мәгълүмат бар. Әсирлектәге татар солдаты бу хакта туганнарына хәбәр итә алган, атасы аңа хатлар язып торган, берничә мәртәбә чәй, шикәр салып посылка да җибәргән. Шундый посылкаларның берсенә, әсирнең үтенече буенча, посылкага яшереп кенә Европа картасы да салалар. Бу, бәлки солдатның әсирлектән качарга әзерләнүе өчен кирәк булгандыр. Адресны немецчә язу өчен этисе немец әсирләрен эзләп Казанга барып, алардан яздырткан[26].

Әсирлек коллыгыннан котылып кайтучыларның язмышлары да җиңел генә булмаган, әмма инвалид булып кайткан әсирләрнең яңадан да сугышка алыну куркынычы торган, алар әсирлектәге авыр шартларны башка солдатларга сөйләп, әсирлеккә төшмәскә өндәргә тиеш булалар, әмма бер сугыш кырыннан чыккан солдат яңадан ут эченә керергә ашкынып тормаган, алай да берничә кешене бу миссияне үтәр өчен ризалаштыра алалар. Шуларның берсе – герман әсирлеген үткән Тәтеш өязе Олы Шәмәк волосте Бәйрәш авылы кешесе Самат Яһүдин. Соңрак аңа тагын берничә элекке әсир дә кушыла[27].

Әсирлектә булып кайткан кешеләргә мөнәсәбәт тә бертөрле генә булмаган, кайберләре бу фактка игътибар да итмәсә, бер ишеләре бу язмыш юлын узучыларны кимсетергә, аларны түбәнсетергә дә күп сорап тормаганнар. Тәтеш өязенең Иске Барыш волостена карый торган Волгузино авылы кешесе Гарифулла Хәйбуллинның гаиләсеннән авылдашлары ул әсир булганы өчен, җир кишәрлеген тартып алмакчы булалар. Бу очракта

[25] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 160.

[26] Шунда ук. – С. 164.

[27] Шунда ук. – С. 150–151.

кешелеклелек сыйфатлары белән халыкның хәерчелеге очраша, бәлки алар шул рәвешле үзләренең җир азлыгын хәл итәрбез дип уйлаганнардыр[28]. Бу вакыйганың ахыры алай ук трагик тәмамланмый, әсирнең гаиләсе кишәрлеген үзендә калдыра ала.

Сугыштан кайткан инвалидның хәлләре бермә-бер авыр булган. Сугыш яралары белән калган солдатлар, имгәнгән кешеләрнең барысы да пенсия дә ала алмаган, бөтенләй хәлләре начар булганнарны урнаштыру өчен инвалидлар өчен йортлар булдыру каралса да, анда бик сирәкләр генә элэгә алган, ә җиңелчәрәк яралар белән булганнар бөтенләй дә ярдәмсез калганнар. 1908–1911 елларда армиядә хезмәт итеп, ә 1914 елның июль аеда ук мобилизациягә эләккән, сугыштан яраланып кайткан Тәтеш өязе Олы Яңасала авылы кешесе Һидиятулла Миңнуллин пенсия сорап өяз җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә, әмма яралары җиңелчә яралар рәтенә керә дип пособия түләүдән баш тарталар. Моңа якын вакыйга шул ук өязнең Каенлык авылының Самигулла Зәйнуллин белән дә була. Сугышта ике бармагының беренче буыннарын эздерткән солдат та бернинди пособиясез кала. Шулай итеп, сәламәтлеген югалткан бик күп солдат язмыш кочагына ташлана, алар шул хәлдә сау-сәламәтләр белән бер үк дәрәҗәдә тормыш йөген тартуларын дәвам итәләр. Кайберләренә ниндидер иҗтимагый оешмалардан, хәйриячеләрдән күпмедер ярдәм тигәләгән, әмма сугыш аркасында җимерелгән язмышлар, күпсанлы ятимнәр алга таба бары тик үз көчләренә генә ышанып яшәүләрен дәвам иткәннәр.

Тәтеш өязе халкы өчен дә бу сугыш зур авырлыклар алып килгән, бу хәлләрнең барысында да аерым кешеләр, аерым гаиләләр, халык язмышы ята. Кызганычка каршы, күбесенең язмышы әлегә кадәр билгеле түгел, соңгы елларда ачыла башлаган архив сәхифәләре, мәгълүматның интернет челтәрләренә куелуы бу хәлләрне өйрәнүгә мөмкинлек ачты. Рәсми документларны халык хәтерендә булган хәбәрләр белән тулыландырып, чагыштырып өйрәнгәндә генә реаль картина барлыкка килә ала. Кызганыч ки, бу тарихларны хәтерләүче буын китеп бару сәбәпле дә, әлеге сугыш хәтирәләренә игътибар булмау да, күп нәрсәләрне онытгырган. Кушымтада (№ 18) бирелгән материалда Тәтеш өязе авылларыннан сугышка алынып, төрле дәрәҗәдәге орден-медальләр алучылар бирелде, ә исән кайтканнар, яралылар, әсирлектә калучылар турында, кызганыч, тулы картиналы мәгълүмат туплау мөмкин дә түгел.

Беренче бөтендөнья сугышы җәмгыять тормышына зур үзгәрешләр алып килгән сугыш: ул икътисадый, социаль тормыштан башлап, җәмгыятьнең эмоциональ халәтенә кадәр тәэсир итә. Кайтавазы бик озак елларга сузыла. Сугыш халыкның тормыш шартларын, аның көн күрү мөмкинлеген бермә-

[28] Габдрафикова Л. Р., Абдуллин Х. М. Татары в годы Первой мировой войны (1914–1918 гг.): монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 151.

бер начарлата, җәмгыятькә социаль киеренкелек алып килә: сугыш турында халык арасында каршылыклы фикерләр туа. Шул ук вакытта, сугыштан сугышны узып, үз проблемасы белән бер ялгызы калган кешеләр саны, ятимнәр арта. Демографик кризис өлгереп җитә. Боларның ахыргы нәтиҗәсе буларак, дәүләттә кискен үзгәреш – инкыйлаб башлана.



Тәтеш өязе картасы. XVIII йөз ахыры.
Борынгы актлар Дәүләт архивы. 1356 ф., 1 тасв., 1221 эш.

# III бүлек

# ТӘТЕШ ТӨБӘГЕНЕҢ РУХИ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЫ

## § 1. *Төбәкнең күренекле дин әһелләре*

Тәтеш төбәге үзенең укымышлы кешеләре, руханилары белән дә таныла. Бу төбәктән чыккан голямалар ислам дөньясына да билгеле булганнар. Беренче мөфти булган Мөхәммәдҗан Хөсәеновның бабасы мелла Мансур бине Габдеррахман бине Әнис әл-Борындыкый Тау ягындагы Борындык авылы кешесе[1]. Ул бу төбәктә атаклы кеше булуы мәгълүм, аны халык «Мансур әфәнде», яисә «Мансур хафиз» дип атап йөрткән. Мансур хәзрәт мелла Мортаза бине Котлыгыш әс-Симити дигән кешенең шәкерте булган. XVIII йөзнең башында гомер иткән Мортаза хәзрәт дәресләр биргән, бик күп шәкертләр тәрбияләгән остаз. Халыкта Мортаза хаҗи, Мортаза хафиз, Мортаза мөфти буларак та танылган бу шәхес белән, укытучысы булган булса да, Мансур хәзрәт аның фикерләре белән каршылыкка керә, хәтта ул аның белән дошманлаша да. Ш. Мәрҗани аның турында: «халык телендә, остазы Мортаза әфәндегә хөрмәтсезлеге аркасында мөселманнар исәбеннән чыккан, дип сөйләнә»[2], дип язган. Беренчеләрдән булып Бохарага барып укыган Мансур хәзрәт белем алып кайткач үзен остазыннан гыйлемлерәк дип санаган. Һәр сорауда аның карашына каршы фикер әйтә торган була. Мортаза хәзрәтнең «Тәкъбире ифтитах»та «һәмзә»не сузып укуына ризасызлыгын белдереп, хәтта җавап итеп бер рисалә дә яза. Аның «Әл-гавамилелми йә» исемле рисаләгә аңлатма рәвешендәге «Тәрякибе-Мансурия» дигән хезмәте 1727 елда язылган. Бу китапта ул исемен күрсәтмичә генә тәхәллүс формасында «Гобәйдулла әл-Болгарый» дип куя. Р. Фәхреддин бәяләвенчә: «бу әсәре арабызда шулкадәр күп күренә ки, мондый зур күләмле бер китапның каләм илә язылып, бу кадәр күп таралуыннан әлеге шәхеснең шәкертләре күп вә шөһрәте дә аеруча зур булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин»[3].

---

[1] Р. Фәхреддин Мансур хәзрәт мөфти Мөхәммәдҗан хәзрәтнең бабасы түгел, ә атасының бер туганы гына дигән караш та бар дип яза.

[2] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 235.

[3] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 39.

Мансур хәзрәт үзе дә мәдрәсә тотып шәкертләр укыткан, дәресләр биргән. Әлбәттә ул, заманы өчен төпле дини гыйлемле кеше булганлыгы билгеле. Насыйр бине Габдессәед Әбелмәкярим бине Гали Әбелмозаффар Әбелфәтех әл-Мотаразыйның[4] «Әлмисбах»ы һәм аңа аңлатма рәвешендә эшләнгән «Ифтитах» буенча укыткан. Бохарадан укып кайткач ул үз мәдрәсәсендә җәдидчә белем биргән. «Бидан», «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд», «Гавамил»дән дәрес итү кагыйдәләрен эшләгән. Морфология, синтаксис нигезләрен шәкертләргә аңлаешлы итеп аңлатуның үз методикасын булдыра. Мансур хәзрәтнең вафат булу елы, җирләнү урыны билгесез.

Нәсел тамырлары белән Борындык авылыннан булган Хөсәен бине Габдеррахман бине Әнәс әл-Борындыкый Мансур хәзрәтнең туганы, кайбер мәгълүматлар буенча, ул аның улы булган да диләр. Һәрхәлдә, ул Россия мөселманнарының беренче мөфтие Мөхәммәдҗан Хөсәеневнең атасы. 1720 елларда Уфа губернасы Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып хезмәт иткән, галим, нәсихәт итүче, хәтта изге кеше иде дип халык хәтеренә кереп калган. Р. Фәхреддин «исеме язылган таягы бу көнгә кадәр мәчеттә саклана вә хатыйблар кулында берсеннән-берсенә күчеп йөрүе мәгълүм»[5], дип язган. Вафат булу елы, кызганычка каршы, билгеле түгел, XVIII гасыр ахырында вафат булган дип кенә фаразлый алабыз, чөнки аның дәвамчысы Габделшаһ бине Габдулла Эстәрлебашка 1796 елда мөдәррис булып килә.

Хөсәен хәзрәтнең улы Мөхәммәдҗанны Ш. Мәрҗани Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур бине Габдерәхим бине Әнәс әл-Болгарый дип бирә[6], әмма Р. Фәхреддин Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Габдеррахман[7], дип яза. Әйткәнебезчә, мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәенев Мансур хәзрәтнең оныгымы, яисә туганының оныгымы – бу хакта ике төрле фикер бар, ике галим ике төрле язганнар. Мөхәммәдҗан мөфти шактый катлаулы, каршылыклы шәхес була. Ш. Мәрҗани аның турында: «Бу мәмләкәткә кайтканнан соң үзенең тырышлыгы вә яхшы иҗтиһады сәбәпле Русия дәүләтенең олысына вә кечесенә мәгърифәт пәйда итеп, Русиядән вәхшәт вә буйсынудан нәфрәт иткән казакъ вә башкорт вә башка таифәләрне кызыктыру вә куркыту илә буйсындыру хосусында юл күрсәтүче мәэмүр булды, үзенең таләбе яки башка бер сәбәп илә Диния нәзарәте оештырылгач, биредә башлык һәм мөфтие итеп билгеләнә», дип яза. Кыю, катгый карарлар кабул итә торган мөфти власть биргән мөмкинлекләр белән һавалана, мал җыя башлый. Тора-бара халык арасында дәрәҗәсе төшә, мелла Габделҗәббар бине Мөстәкыйм әл-Кайбычи казый булганда ике дусты белән мөфтигә каршы барырга килешә. Бу

[4] 1538 елда вафат.

[5] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 48.

[6] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 211.

[7] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 98.

ызгыш-талаш зурга китеп прокурор тикшерүенә барып җитеп туктатыла. Мөфти үзе: «Йөзе генә кара булсын, барысына да Габделҗәббар сәбәп булды», дип әйтә торган булган дип яза Ш. Мәрҗани[8]. Аның беренче хатыны Исмәгыйль Апанаевның тол хатыны Гайшә[9], икенче хатыны Кәримә, өченчесе Суфия исемле булган. Гайшә мөфти хәзрәттән алданрак бакыйлыкка күчә. Мөхәммәдҗан мөфтинең туплаган байлыгы да, дан шөһрәте дә бик тиз сарыф ителә башлый, үзеннән соң дин юлында булган варисы да калмый, кайчандыр атаклы булган бу нәселнең тамырлары шуның белән өзелә дияргә дә була. Бары тик икенче хатыны Кәримәдән туган Фатыйма исемле кызы бу нәселнең лаеклы дәвамчысы, ул Җиһангир хан никахында була. «Мөфти хәзрәтнең дөрес бәхетле вә үзенең дә хәер илә исеме хәтердә калуына сәбәпче баласы шушы Фатыйма булган, диләр. Чөнки барлык туганнарыннан аермалы буларак, гаять диндар, тәкъва, инсафлы, гакыллы, уйлап эш итүчән бер хатын булып, ханның мәхәббәтен җәлеп иткән вә ханның үзен тәрбия иткән кебек, бөтен Бүкәй иленә мәдәният керүенә сәбәп булган. Казакъ гаиләләренә шәхсән үзе гореф-гадәтләрнең гүзәл булганнарын өйрәткән, ә исламга туры килмәгәннәрен кире каккан, тәһарәт вә пакълеккә аеруча зур игътибар биргән. Хан хатыны булып барганнан соң, Бүкәй иле белән Оренбург, Уфа вилаятьләре арасында килеп-китеп йөрү халык арасында таралу белән арада бөек бер дуслык вә танышлык пәйда булган. Казакъларның дәүләтлеләренең угылларны үз байлыкларыннан, мохтаҗ вә фәкыйрьләренең балаларын үз кесәсеннән чыгым тотып, Эстәрлетамак вә Эстәрлебаштагы мөселман мәдрәсәләренә җибәреп укытканнар. Бүкәй илендә бу көндә булган могътәбәр галимнәр һәм танылган мөдәррисләр әлеге ике мәдрәсәнең вә аларны тәрбияләгән шәехләрнең тәрбия җимешләреннән. Җиһангир ханның, мәсҗид салдырып, һәртөрле ыруг вә кабиләләргә имамнар билгеләве вә аларга рәсми сурәттә хокук кәгазе биреп, мәхәллә балаларын укыту вә сабыйларга борынгылардан калган исем бирү нәтиҗәсендә танылуы шушы хатынның уйлап эшләве белән булган»[10], дип бәя бирә Р. Фәхреддин.

Тәтеш ягының атаклы имамнарыннан берсе – Шәмәк авылының (хәзерге Апас районы) мелла Әлмөхәммәд бине Сүкәй бине Айтуган бине Шаһйосыф бине Шәмәк (1742 елның 11 августында вафат). Ул мелла да Мансур Борындыкый кебек үк, Мортаза бине Котлыш әс-Симетинең (1723 елларга кадәр яшәгән) шәкертләреннән. Әлмөхәммәд хәзрәтнең оныгы Исмәгыйль бине Сабит бине Габбас бине Габделҗәлил бине Әлмөхәммәд бине Сүкәй – Ш. Мәрҗани шәкерте. Ул шул ук өязнең Урман Тәүгелдесе авылында имамлык итә.

[8] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 212–213.

[9] Гайшәне Русия белән Төркия арасындагы сугышта әсир алынган төрек кызы булган диләр.

[10] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 39.

[10] Шунда ук. – Б. 100–101.

Анының туганы Хәйрулла хәзрәт тә имам булган кеше. Гомумән, бу авылда ата-бабалары чиратлашып озак еллар имамлык иткәннәр[11]. Әлмөхәммәд хәзрәтнең 1724 елда туган Хәнифә исемле кызы, Габделвахид исемле улы, 1726 елда дөньяга килгән Хафаса исемле кызлары, Габделҗәлил, Мөхәммәделәмин исемле уллары булган. Габделҗәлил хәзрәтнең улы Габбас, анының улы Сабит, ә Сабитның уллары югарыда аталган Исмәгыйль белән Хәйрулла хәзрәтләр[12].


8 Мая 1908 г.

Тәтеш өязе Олы Әтрәч авылына мөәззин итеп билгеләнү өчен
Камалетдин Хөснетдиневнең Диния назәрәтенә биргән гаризасы. 1908 ел.
БР МА, И-295 ф., 3 тасв., 5035 эш.

[11] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 235.

[12] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 41.

Хәзерге Апас районына карый торган Барыш авылы да мөселман дөньясында хөрмәт казанган руханилар биргән авыл. Мелла Габденнасыйр бине әл-Мөхәммәд әл-Җәбәли әл-Барыши Барыш авылында имам булып торганда казый булып сайлана. Казыйлык срогы тәмамлангач, Казанга кайтып, 1831 елда, мелла Әмин урынына Казанның бишенче мәчетенә («Галиев мәчете», яисә «Барудия» мәчете) имам булып билгеләнә. Соңгы елларын, вафатына кадәрге гомерен, Казан артындагы Орнашбаш авылының имамы буларак үткәрә[13].

Барыш авылыннан чыккан аталы-уллы Ибраһим бине Габдулла әл-Нократый һәм Сәгыйдь бине Ибраһим бине Габдулла әл-Барышилар да заманында татар-мөселман дөньясында танылган шәхесләр булып, тәрбия, укыту эшендә тарихи эзләрен калдырган күренекле шәхесләр. Халык Ибраһим хәзрәтне «Урбар хәзрәт» дип тә атап йөрткән, чөнки соңгы еллары аның Урбар авылында үтә, шунда мәдрәсәдә шәкертләр тәрбияли, 1780 елда Урбар авылында (Татарстанның Балтач районы) вафат булган, шунда җирләнгән дә, Ш. Мәрҗани аның кабере билгеле дип яза[14]. Бу имам күп авылларда яшәгән, төрле җирләрдә шәкертләр укыткан. Ш. Мәрҗани шәкертләр күчергән борынгыдан калган кулъязма китаплар буенча хәзрәтнең Хәсәншәех, Ташкичү, Казакълар, Шашы һәм Урбар авылларында хезмәт иткәнен билгели. Бик күп шәкертләрнең остазы булган имам, шул исәптән, Шиһаб хәзрәтнең бабасы мелла Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани дә әлеге хәзрәттә белем эстәгән. Ә үзе исә югарыда әйтеп кителгән мелла Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети шәкерте. Ибраһим хәзрәтнең атасы Вятка губернасы Нократ авылында имам булып торганда шул авылда дөньяга килгән, тәхәллүсен дә шул авыл белән бәйләп Нократый дип атый. Атасы Нократ авылында яшәп, шунда вафат булган.

Аның улы Сәгыйдь бине Ибраһим 1796 елларда атаклы Кышкар (Арча районы) авылында имамлык итә, мәдрәсәдә шәкертләр укыткан, аларга остаз булган кеше. Халык арасында аны «Карт Сәгыйдь хәзрәт» дип атап йөрүләре мәгълүм. Гарәп телендә җир шары турында үзе язган кечкенә генә китабы да булган. 1813 елга кадәр Кышкар авылында гомер итеп, шул авыл зиратына җирләнә. Аның улы Шәмсетдин хәзрәт Иске Кишет авылына (Арча районы) мулла итеп билгеләнеп, шунда соңгы көннәренә кадәр гомер итә. Оныгы – Шәмсетдин хәзрәтнең улы – мелла Бәдретдин 1872 елда вафат була, Казанда җирләнгән, җеназасын Шиһаб хәзрәт укый. Аның ике улы кала[15].

---

[13] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 303.

[14] Шунда ук. – Б. 241.

[15] Шунда ук. – Б. 259.



Тәтеш өязе Олы Әтрәч авылы крестьяны
Мөхәммәдһади Мөхәммәдсабировның имамлыкка дәгъва итү өчен
дини белем буенча имтихан алуны үтенеп язган гаризасы.
БР МА, И-295 ф., 3 тасв., 6248 эш.

Татарстанның иң зур шәһәрләренең берсе булып үсеп киткән Әлмәт шәһәре урынындагы Иске Әлмәт авылын нигезләүчеләр дә, аның имамнары булган кешеләр дә Тау ягыннан чыкканнар. Мелла Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сәрмәт бине Әлмәт бине Алыш әл-Казани әл-Әлмәтинең бабалары Шонгаты авылыннан (Тәтеш районы) чыгып Иске Әлмәт җиренә килеп төпләнәләр. Гобәйдулла хәзрәт ишанлыкка мелла Габделҗәббар бине Җәгъфәр әл-Пәравидән фатыйха ала, Кизләү авылына имам, хатыйб һәм мөдәррис булып килә, 1822 елгача – вафатына кадәр шул авыл халкына хез-

мәт итә. Атаклы Кизләү мәдрәсәсендә татар-мөселман дөньясына хезмәт иткән бик күп шәкертләр укытып чыгара. Хәзрәтнең икенче улы – Рәхмәтулла мелла атасыннан соң имам, хатыйб, вә мөдәррис булып кала. Ул заманының атаклы остазларыннан – Габдрахман әл-Каргалыйдан белем алган, хаҗи Вәлиэддин әл-Багдадидан Коръән уку серләрен өйрәнгән. Кизләүдә вафат була, вафатыннан соң аның урынына бертуган энесе – мелла Мөхәммәд хәзрәт килә, шулай ук танылган шәхес була, шәехлек итә. Бик укымышлы, хөрмәтле кеше булган, агасы мелла Рәхмәтулла белән бергәләп Коръәнне көйләп укыганнар. 1878 елда Кизләү авылында вафат була.

Гобәйдулла мелланың олы улы мелла Нигъмәтулла Яңа Әлмәт авылында имам, хатыйб һәм мөдәррис булып тора, шәехлек белән шөгыльләнә, аны «Әлмәт ишан» дип атап йөрткәннәр. Нигезле дини белем алган кеше, алдан әтисе Гобәйдулладан укыса, аннан укуын Габдрахман әл-Каргалыйда, мелла Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытидан укый, хаҗи Вәлиэддин әл-Багдадидан Коръәнне яттан укырга өйрәнә. Гомер буе Әлмәттә эшләгән имам шунда вафат булып, шунда ук җирләнгән[16].

Тау ягының, Тәтеш өязенең атаклы иманнар нәселе Тәүгелде авылыннан да чыга. Мөфти Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәеннең кыз туганының баласы Сәгыйдь бине Хәмид бине Йосыф бине Хәсән бине Габдрахман бине Хәлиулла атаклы Күлбаш авылы мәдрәсәсендә остаз Максуд бине Корбангалидән гыйлем алып, 1800 елда Указга имтихан тапшырып, Тәүгелде авылында муллалык итә башлый. Гомеренең ахырына кадәр язмышы бу авыл белән бәйле, ул 1862 елда бакыйлыкка күчә. Шәкерт вакытында оста хаттат [каллиграф] булып танылып өлгерә, мәдрәсәдә укыганда бик күп китаплар күчереп бай китапханә туплый, әмма олы улы Сабирны солдат хезмәтеннән алып калу өчен (аның урынына кеше яллау) бу китапларын мең сумга сатарга мәҗбүр була. Мәгърифәтле хәзрәт китапсыз кала алмый, шул ук китапларны ул үз китапханәсе өчен яңадан күчерә. Хәзрәт үзе дә тирә-якта атаклы остаз булып таныла, аңа белем алу өчен шәкертләр килә торган була, Диния назәрәтендә казый булып хезмәт иткән Таҗеддин бине Максуд[17] та аның шәкертләренең берсе.

[16] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 294.

[17] Максуд бине Корбангалинең улы.

Сәгыйдь хәзрәтнең уллары да Тәтеш өязенең төрле авылларында имамлык иткән. Аның олы улы Сабит Казан артындагы Бәрәзә авылы мәдрәсәсендә Бәшир хәзрәттән гыйлем алганнан соң, Тәтеш өязенең Чирмешән авылында гомеренең ахырына – 1877 елга кадәр имам булып тора, уртанчы улы Гыймран да укымышлы кеше булган: Байморат бине Мөхәррәм, Фәхреддин бине Мостай эн-Нурлатый, Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләреннән белем алган кеше. Ш. Мәрҗанинең талантлы шәкертләреннән саналган, фикһ, кәлам, гарәп теленнән оста шәкерт була, хәтта беркүпмедер шигырьләр дә яза. Тәтеш өязе Багыш авылында мулла булып тора, 1894 елның 28 июнендә бакыйлыкка күчә. Сәгыйдь хәзрәтнең Мөхәммәдшаһ исемле углы шулай ук Ш. Мәрҗани шәкерте, китаплар авторы да, әтисе кебек үк хәттатлыкка талантлы шәхес. Олы яшькә җиткән вакытта да яшьләрчә фикер йөртеп, яңалыкны үз иткән, газета, журналлар укып, әдәбият белән кызыксынган хәзрәт әтисе урынында, Тәүгелде авылында, имамлык итә[18].



Тәтеш өязе
Исәк авылы имамы
Хәсән Мирхәйдәрев.
1899 ел. ТР ДА, 2 ф.,
2 тасв., 6086 эш.

Тәтеш өязе Әлки авылы (хәзерге Буа районы) имамы Баһаведдин Таҗетдин улы тирә-якта ихтирам казанган имам гына түгел, ә безнең зур галимнәребез белән дә таныш булган, алар белән аралашкан гыйлемле зат та. Ул күренекле галим Хөсәен Фәезхановның (1828–1866) мәдрәсәдә укыган чордан ук дусты булган кеше. Кабер ташларын өйрәнгәндә Ш. Мәрҗанигә (1818–1889) дә ярдәм иткән шәхес тә ул. Тарихчы Г. Әхмәрев (1864–1911) аның турында хезмәтендә болай дип яза: «Мәрхүм дамеллага [Ш. Мәрҗани] Тәтеш өязеннән асаре гатыйкалар [борынгы истәлекләр] хакында күбрәк хәбәрләр ул язган, имеш. Гыйльме тарихка мәхәббәт тотучыларыбыз, аз булса да, бар икән»[19], дип яза. Г. Әхмәрев тә тарихи мирас белән кызыксына башлагач, Баһаведдин хәзрәт белән элемтәгә керә, бу вакытта инде хәзрәт олы яшьтә



Тәтеш өязе Кече Болгаер
имамы Мөхәммәдзакир
Мөхәммәдҗанов.
1899 ел. ТР ДА, 2 ф.,
2 тасв., 6089 эш.

[18] Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 39.

[19] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – 191–192 б.

булса да, үзенең гыйлеме белән уртаклашып тарихчыга зур ярдәмләр күрсәтә. Г. Әхмәрев 1906 елда язган «Ватан вә милләт тарихы хакында» дигән мәкаләсендә «Тәтеш өязендә Әлки карьясенең [авылының] карт имамы Баһаветдин хәзрәт үзенең гыйльми тарихка мәхәббәтен вә иҗтиһадын хатыбызга каршы җавап язып, берничә аңлатты, һәм йөз егерме ел мөкаддәм [элек] язылган бер тәварих китабын да җибәргән иде»[20], дип яза. Г. Әхмәрев Баһаведдин хәзрәтнең хатыннан берничә юл да биреп, тарихи мирасны өйрәнүдә, саклауда аның ни дәрәҗәдә зур роле булганлыгын күрсәтә: «хатның бер-ике сәтыры [юлы] шул: "Тәварих бабында иҗтиһадыгызны [тырышлыгызны] ишетеп, бик мәмнүн булдык [сөендек], без һәм әтрафымыздагы [тирәмездәге] асаре кадимәләрне [борынгыдан калган истәлекләрне] тикшереп вә тәварих мәсьәләләре белән шөгыльләнеп, гомеребезне үткәрдек, Шиһаб хәзрәтнең тәварихында булган хәбәрләрнең күбесе безнең иҗтиһадыбыз белән булгандыр"»[21]. Шиһабетдин Мәрҗанигә ул чуаш авылларында сакланып калган борынгы Болгар ташларын да күрсәтеп йөри. Хөсәен Фәезханов тә тарихи истәлекләрне өйрәнгәндә Баһаветдин хәзрәт өенә кунакка килә. Х. Фәезханов «... Казан губернасының Тәтеш өязе Әлки дигән татар авыл мулласы (мәдрәсә дустым) өендә чәй эчкәндә дүрт-биш яшендәге кызын минем яныма китереп күрсәтте. Аның якасында очраклы рәвештә мин ике тәңкә күрдем, һәр икесе 15 тиенлек зурлыгында»[22], дип тәңкәдәге язуларны укырга тырыша. Баһаветдин хәзрәт мәдрәсә дустын шул төбәктә булган, хәзерге Чуаш республикасы җирлегенә кергән авылларда Болгар кабер ташлары булуы хакында сөйли һәм алар бергәләп Байтирәк, Олы Яльчик һ.б. авыллардагы кабер ташларны карап чыгалар.

Баһаветдин Таҗеддин улы имамлыкка Указны 1846 елның 26 июнендә ала[23], шуннан башлап озак еллар авылда имамлык итә, хәтта 1894 елгы документ буенча да ул авылның беренче имамы буларак хезмәтен дәвам иткәнлеге мәгълүм. 1891 елның 13 июнендә улы Мөхәммәднәҗип Баһаветдинев Указ алып авылның икенче имамы вазыйфаларын башкара[24].

---

[20] Әхмәрев Г. Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. – 1906. – 12, 14 апр.

[21] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи документаль җыентык /төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – Б. 191.

[22] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б.253–254.

[23] ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 8 эш, 36–52 кгз.

[24] ТР ДА. 2 ф., 2 тасв., 4961 эш, 288–318 кгз.

Тәтеш районына карый торган Әтрәч авылы имамнары арасында да татар тарихына кереп үз урынын алырлык шәхесләр булган. XX йөз башында Олы Әтрәч авылында хәзерге Кама Тамагы районына кергән Бишалаб (Казыево-Бишалаб) авылы кешесе – иганәче Минһаҗетдин Сайхунов яңа мәчет төзетә һәм 1910 елның 18 июнь указы белән мулла итеп үз улы Әхмәтҗан Минһаҗетдин углы Сайхуновны куя[25]. Ул 1884 елның 26 сентябрендә туган бу хәзрәт Казанның 4нче мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлаган. 1914 елның азагына кадәр ул икенче мәхәллә имам вазыйфасын башкарган[26]. 1915 елда 30 яшендә авыру сәбәпле вафат була. Аның эшен Тәтеш өязе Казыево-Ключище авылында туган Миңнекамалетдин Мөхәммәдҗан углы Мостафин дәвам итә. Хәзрәт Казан шәһәренең 4нче мәчет каршындагы мәдрәсәсен һәм Иске Бистә мәдрәсәсенең рус классында белем алган. Камалетдин хәзрәт Олы һәм Кече Әтрәч авылларында 1915–1916, 1920–1930 елларда имамлык итә. Кызы Хәлимә ягыннан булган дәвамчылары татар профессиональ музыка өлкәсендә танылган шәхесләр. С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин, Җ. Фәйзи, Н. Җиһанов, А. Ключарев белән бергә белем алган Габделхәмит Әбүбәкерев татар халкының беренче профессиональ виолончисты, ә Габделхәмит улы Фуат Әбүбәкерев Татарстанның халык артисты, композитор, дирижер буларак танылган музыкант.



Тәтеш өязе
Әлки авылы имамы
Мөхәммәдсадыйк
Баһаветдинев. 1902 ел.
ТР ДА, 2 ф., 2 тасв.,
6434 эш.



Олы Әтрәч
имамы Әхмәдҗан
Минһаҗетдин улы
Сайхунов. 1908 ел.
ТР ДА, 2 ф., 2 тасв.,
8168 эш.

Тәтеш белән күршедә генә булган Сембер губернасына керә торган атаклы Олы Тархан авылында 39 ел дәвамында имамлык иткән Нуреддин бине Мифтахетдин бине Мостай (1830–1901) тумышы белән Тәтеш өязе Тутай авылы (хәзерге Апас районы) кешесе. Казанда төрле мөгаллимнәрдән белем алганнан соң, гомере буе авылда имамлык итә, тирә-якта ихтирамлы хәзрәт булган, вафатыннан соң

[25] Бу мулланың эшчәнлеге хакындагы архив документлары кушымтада бирелә.
[26] БР МА, И–295 ф., 6 тасв., 1687 эш, 7 кгз.

җеназасын Буа мөдәррисе Нургали бине Хәсән укый. Үзеннән соң муллалык вазыйфасы улы Шәрәфелисламга кала. Чордашлары аның зур китапханәсе булуы хакында, китапка мәхәббәтле хәзрәт булуы турында язалар[27].


МЕТРИЧЕСКАЯ ВЫПИСЬ

| №№ по метрической книгѣ | Мѣсяцъ и день рожденія | Имя родившагося | Званіе, имя, отчество и прозваніе (фамилія) отца, а у внѣбрачнаго матери | Если родившійся умеръ, то годъ, мѣсяцъ и день его кончины |
|---|---|---|---|---|

Зур Әтрәч авылында имамлык иткән Татарстанның халык артисты
Фоад Әбүбәкеровнең бабасы Миннекамалетдин Мөхәммәдҗан углы Мостафинның
туу турындагы метрика язмасыннан күчермә. 1884 ел.
ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 9633 эш.

[27] Фәхреддин Р. Асар. 3–4 томнар. – Казан: Рухият, 2010. – Б. 413.


Свидѣтельство.

По указу Его Императорскаго Величества, въ присутствіи Оренбургскаго Магометанскаго Духовнаго Собранія, вслѣдствіе просьбы крестьянина Казанской губерніи, Тетюшскаго уѣзда, деревни Казыево-Ключища Камалетдина Мухамедьянова Мустафина и согласно 1424 ст. XI тома 1 части (изд. 1896 г.) было ему, Мустафину, учинено испытаніе въ знаніи правилъ магометанской религіи, по которому оказался быть способнымъ: имамъ-хатибомъ и муаллимомъ.

Въ удостовѣреніе чего и выдается ему, Мустафину это свидѣтельство, съ тѣмъ, что оно, показывая о его познаніяхъ, не предоставляетъ ему права исправлять духовныя требы впредь до утвержденія его въ духовномъ званіи губернскимъ начальствомъ въ приходѣ, въ который будетъ избранъ. Городъ Уфа, Іюня 4го дня, 1908 г. Гербовымъ сборомъ оплачено.

За Предсѣдателя Оренбургскій Муфтій (Хаджи)

Члены-Ахуны:

У сего печать.

4598

Оренбург Диния назарәте тарафыннан
Камалетдин Мостафинга бирелгән шаһадәтнамә. 1908 ел.
ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 9633 эш.



Тәтеш өязе Олы Әтрәч имамы Мөхәммәдһади Мөхәммәдсабир улы. 1911 ел. ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 8838 эш.



Тәтеш өязе Казый-Ключище авылының Мөхәммәдбарый Закиров. 1911 ел. ТР ДА, 471 ф., 1 тасв., 37 эш.

Казанның дүртенче, халык телендә «Зәңгәр мәчет» дип аталган мәчетендә, хезмәт иткән имамнарның тулы бер династиясе дә Тау ягы кешеләре. Бу династияне башлаган Габденнасыйр Рахманкулов Тәтеш өязе Бәки авылыннан (Кама Тамагы районы). Ул Оренбург төбәгендәге Каргалы мәдрәсәсендә белем алып, 1825 елда Казанга кайтып дүртенче мәчет имам-хатыйбы һәм мөдәррисе булып хезмәт юлын башлый. Бу мәчет каршында ул мәдрәсә оештырып җибәрүче кеше дә. Мәдрәсә өчен сәүдәгәрләр Йосыф һәм Корбангали Арсаевлар аерым бина төзеп бирәләр, моны атаклы «Халиди» мәдрәсәсенең оешу факты итеп тә санарга була. Ш. Мәрҗани аның турында: «Хуш кыяфәтле, хуш йөзле, Коръән укуы гүзәл, тавышы бик килешле булып, Коръәнне моңлы вә тәэсирле укуы белән үзен һәм башкаларны елатыр иде. Җөрьәт, ныклык вә куәт, гайрәт вә тәкъвалык һәм суфыйлык белән мәшһүр иде. Фикһ мәсьәләләре белән мәшһүр иде. Ләкин хөтбәләрендә ялгыш гыйбарәләр беленә иде. Сәгыйдь бистәсендә гыйлем алуда сабакташы булу мөнәсәбәте белән мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим илә мәхәббәт һәм дуслыкта булып, мөфти Әхмәд исемле углын моның хозурына укырга җибәргән иде. Ләкин аралары бозылып, дошманлык пәйда булды. Хәтта ахунлык вазыйфасыннан азат ителсә дә, вафаты сәбәпле, указы алынмый калды. Вафат иткәндә яше 63 иде»[28], дип яза. Габденнасыйр хәзрәт вафатыннан соң аның эшен энесе Хәбибулла бине Рахманколый әл-Җәбәли әл-Бики дәвам итә. Мелла беренчел белемне этисеннән алганнан соң Казанда мелла Әбүбәкер бине Йосыф мәдрәсәсендә, аннан Нигъмәтулла Гобәйдуллин-Бубида укып белемен тирәнәйтә. Аннан укуын Каргалыда мелла Габдрахман әл-Кирмәни һәм үзенең бертуганы Габденнасыйр бине Рахманколыйда дәвам итә. Шул заманның күп кенә имамнары кебек үк ул да Коръән уку остасы Вәлиэддин әл-Багъдадида яттан Коръән уку ысулларын үзләштерә. Атасы исән вакытта ук туган авылына кайтып Бәки авылында имам булып хезмәт итә башлый. Бу авылда ул озак еллар шәкертләр укыта, мәдрәсәсе була. Үзенең бертуганы Габденнасыйр

[28] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 146.

Рахманкулов (1835 елда вафат була) вафат булгач, Казанның дүртенче мәхәллә мәчетенә имам, мөдәррис һәм хатыйб булып килә, гомеренең соңгы мизгелләренә кадәр бу вазыйфаны башкарып, 1850 елда бакыйлыкка күчә. Хәтта бертуганы Габденнасыйр хәзрәттән белемлерәк тә һәм дәрәҗәлерәк тә булган, диләр. Ул мелла Фәхреддин бине Мостафа эн-Норлати, мелла Гали бине Мәхмүд, мелла Габделгалләм бине Салих әл-Чыршыви, мелла Габдессаттар бине Габделгаффар хаҗи, мелла Шаһиәхмәд бине Йосыф бине Хәмид әл-Кавали һ.б. остазы булган кеше[29].

Дүртенче мәчетнең имамы булып Хәбибулла хәзрәттән соң да, Тау ягы кешесе – Тәтеш өязе Яңа Сала авылының (Кама Тамагы районы) Хаммад Халитов тора[30]. Шәригать белеме буенча зур белгеч булган әлеге хәзрәт Бохара белеме алган. Бохарадан Казанга кайткач, беркүпмедер Казанның икенче мәчетендә имам булып торганнан соң, туган авылы Яңа Салага кайтып ималык итә, укыта. Хәбибулла хәзрәт вафат булганнан соң кияве Әхмәд бине Сәгыйдь димләве, мирза Шаһиәхмәд бине Мөхәммәд ярдәме белән дүртенче мәчет имамлыгына килә[31]. Ул 1864 елда вафат була, аның вафатыннан соң имамлыкны Рахманкулов династиясенең имамлыкта соңгы вәкиле булган Хәбибулла хәзрәтнең улы – Гаязетдин алыштыра. Ш. Мәрҗанидән белем алган Гаязетдин хәзрәт бу остазның яраткан шәкертләреннән булган. Ул бары тик 6 ел гына ималык итеп калып, 1870 елда бакыйлыкка күчә. Шушы вакыттан алып, инкыйлабка кадәрге чорга кадәр икенче династия, шулай ук нәсел тамырлары Тау ягы белән бәйле хәзрәтләр – Х. Халитов дәвамчылары имамлык итә. 1870 елда Мөхәммәдзакир Хаммад улы Халитов беренче имам буларак билгеләнә, бередә ул 1865 елдан башлап икенче имам вазыйфаларын башкарып килгән була. Аның вафатыннан соң, 1894 елда, улы – Ибраһим Халитов билгеләнә, икенче имам да Халитовлардан – Мөхәммәдсадыйк Хаммад улы була. Мөхәммәдсадыйк хәзрәтнең улы – Габдрахман хәзрәт тә атасы вафатыннан соң бу мәчеттә икенче имам булып торган[32].

Тәтеш өязенең муллалары читкә китеп тә руханилык вазыйфаларын башкарганнары күренә. Мисал өчен, 1894 елда Тәтеш өязе Бик-Үти авылының мулласы Камалетдин Таҗетдинов Ставрополь төбәгенә сәүдәгәр Хөсәен Алиевның Мулловка авылы янындагы фабрика мәчетенә мулла булып командировкага җибәрелә, авыл мәхәлләсе зурайганнан соң, 1900 елда, аңа яңадан авылга әйләнеп кайтырга боерыла[33].

[29] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 306.

[30] Беренче татар драматургы Фатих Халидиның (1850–1923) бертуган абыйсы.

[31] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 329.

[32] Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р. Исторические мечети Казани. – Казань: Татар.кн. изд-во, 2005. – С. 81–82.

[33] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 4942 эш, 6 кгз.



Тәтеш өязе Кече Әтәч авылы мәчетенең проекты. 1893 ел.
БР МА, И-295 ф., 3 тасв., 13457 эш.



Тәтеш өязе Салтыган авылы имамы Мөхәммәдзакир Камалетдинев. 1901 ел. ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 6436 эш.



Тәтеш өязе Кече Болгаер имамы Мөхәммәдзакир Мөхәммәдҗанов. 1899 ел. ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 6089 эш.

Тау ягы, аерым алганда, Тәтеш өязе татар җәмгыятенең рухи үзәкләренең берсе, бу төбәкнең имам, мөәззиннәре, дини руханиларының танылу даирәләре шактый киң. Бу яктан чыккан имам нәселләре илнең бик күп төбәкләрендә хезмәт иткәннәр. Дини вазыйфалардан кала, аларның күбесе җәмәгать эшлеклесе һәм галим булып та танылалар.

## § 2. *Тау ягының язма мирасы*

Төбәкнең рухи халәте, халык арасындагы аң-белем дәрәҗәсен күзалдына китерүгә шул җирлектә табылган кулъязма, басма китаплар мөмкинлек бирә. Китап булган икән, халык инде рухи югарылыкта гомер иткәнен бик ачык күрергә була. 1969 елда М. Госманов җитәкләгән археографик экспедиция генә дә Тау ягыннан 500 дән артык кулъязма таба. Бу экспедициянең табышлары тулысынча Казан университетының кулъязмалар һәм сирәк китаплар фондына керә, шуларның бер өлеше – татар әдипләре һәм галимнәренә кагылышлы булганнары хакында А. С. Фәтхиев тасвирламалары аша танышу мөмкин[1]. Алга таба Апас төбәгенә 1978 елның июнь-июль айларында галим М. Әхмәтҗанов сәфәр оештыра. Ул Олы Кайбыч, Кече Кайбыч, Иске Чәчкаб, Кошман, Салтыган, Мөрәле, Борындык, Шуширмә авылларыннан шактый күп язма мирас туплый. 1979, 1984 елларда аның Тау ягына кыска вакытлы аерым экспедицияләре була. М. Әхмәтҗанов җыйган мирасның тасвирламалары һәм саклану урыны хакында авторның хезмәтләре аша ачыкларга мөмкин[2]. 1979 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты булган чорында, Н. Вәлиев тә Апас районының Борындык, Энәле авылларыннан борынга кулъязма табышлары белән кайта[3]. 2010 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эш планы кысаларында Апас районы авылларыда А. Гайнетдинев 10 көнлек экспедициядә булып, халык кулында сакланган шактый кулъязма мирас һәм китаплар туплый. Экспедициянең нәтиҗәсе буларак, 480 китап һәм дәфтәр институтның Мирасханә фондын тулыландыра. Автор билгеләвенчә, шуларның 90 ы кулъязма, 100 ләбе гарәп графикасында язылган дәфтәрләр һәм хатлар, ә калганнары басма китаплар[4]. Соңгы экспедиция нәтиҗәләреннән чыгып, күпме вакыт үтсә дә, экспедицияләр булып торган булса да, язма мирас әле дә халык кулында булуын, үзләренең өйләрендә ядкәр буларак саклаганнарын әйтә алабыз. Соңгы экспедициядә булган А. М. Гайнетдинов күрсәтүенчә, табылган язмалар арасында дини китаплар да, шул исәптән, күпсанлы фольклор әсәрләре

---

[1] Фәтхиев А. С. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. КДУ Фәнни китапханәсенә 1959–1969 елларда кергән кулъязмаларның тасвирламасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1986. – 161 б.

[2] Әхмәтҗанов М. И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе. Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2005. – 221 б.; Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе. Соңгы еллардагы археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары (1972–2012). Дүртенче кисәк. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе. Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2014. – 199 б.

[3] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 51.

[4] Шунда ук. – Б. 57.

(бәет, әкият, җырлар, табышмаклар, башваткычлар һ.б.) бар. Сирәк китаплардан, автор Хатаи Сакыйның «Кыйссаи Әхтәм» поэмасының күчермәсен, Әхмәд Зыятдинне әл-Казани әл-Болгари әт-Тархани әсәрләрен, Гатаулла Яһудинең шәхси китабын, Мөхәммәдшакир бине Габделҗәббар Кулиевның автографы һәм шәҗәрәсен, Шиһабетдин бине Шәһретдиннең автографын атый[5].

Әлбәттә халык арасындагы кулъязмаларны бары экспедицияләр кысаларында гына җыеп бетерү мөмкин түгел, халык та кадерләп саклаган ядкәрләрен алай тиз генә биреп җибәрергә ашыгып тормый, күп кенә язмаларны халык яшереп калдыра, бигрәк тә, гарәп язулы язмаларны җыеп яндырганны күргән халык фәнни экспедициягә ышанып та, ачылып та бетми. Бу төбәктәге язма мираска беренчеләрдән булып шушы төбәк кешесе – тарихчы-галим Г. Әхмәрев игътибар итә. Ул халык арасында сакланган кулъязмаларны, китапларны барлый. Болар хакында ул халыктан сораша башлагач, халыкның тарихи язмаларга әлләни исләре китмәве, кешене көндәлек мәшәкать басканын күреп борчыла: «шул заман Тәтеш өязендә Олуг Болгар[6] карьясенең [авылының] мулласын күреп тарихи хәбәрләр сорашмак булдым (чөнки бу авыл халкы, үзләренең ата-бабаларыннан килгән хәбәр буенча, әүвәлдә шәһре Болгардан күчеп утырганнар, имеш). «Казанда дүрт малай укый, аларга икмәк ташудан бушап булмый, иске хәбәрләр тикшерергә вакыт юк», – дип көлеп җавап бирде. Дәхи Келәш[7] карьясенең бер мулласыннан сораштым. Искерәк тарих китаплары хакында: «Ул язган китапларны муллаларның сәке астында әллә кайчан тузан басып бетергән, – диде»[8]. Шулай булса да, халык борынгы китапларны ташламаган, кадерсезләмәгән, аларны ничек кенә булса да саклап калган. Китапның, борынгы язмаларның кадерен, аларның кыйммәтен белгән муллалар да, гади крестьяннар да җитәрлек булган. Хәзерге Буа районына керә торган Әлки авылының имамы Баһаветдин хәзрәт бик гыйлемле, үткән белән кызыксынучан кеше була. Алар хатлар аша аралашалар, Г. Әхмәрев үтенече буенча хәзрәт борынгы кулъязма җибәрә: «Тәтеш өязендә Әлки карьясенең карт имамы Баһаветдин хәзрәт үзенең гыйльме тарихка [тарих гыйлеменә] мәхәббәтен вә иҗтиһадын хатыбызга каршы җавап язып, берничә аңлатты, һәм йөз егерме ел мөкаддәм [элек] язылган бер тәварих [тарих] китабын да җибәргән иде»[9], дип яза галим. Г. Әхмәрев язмасында имамның нинди китап җибәрүен конкретлаштырып тормый, XVIII йөздә язылган бу тарих китабы Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария»сенең бер күчермәсе булуы ихтимал, бу тарихи язма булудан бик ерак торса да, халык аны яратып укыган, күпсанлы күчермәләрен булдырган.

---

[5] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 57.

[6] Апас районына карый торган Олы Болгаер авылы күзалдында тотылса кирәк.

[7] Тәтеш районына керә торган авыл.

[8] Әхмәрев Г. Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. –1906. – 12 апр.

[9] Шунда ук.

Татар әдәбиятында борынгы әсәрләрдән саналган 1358 ел истәлеге – атаклы «Нәһҗ-ел-фәрадис» татарлар арасында яратылып укыла торган язма, аны китап күчерүчеләр дә, шәкертләр дә кулдан күчереп халык арасында тараткannар. Менә шул бер күчермә варианты Буа төбәгендә 1968 елда табыла. Апас районы Дәүләки авылында уникаль әсәр – төрек шагыйре Әхмәдинең «Йосыф вә Зөләйха»[10] поэмасы килеп чыга. Профессор Габдрахман Таһирҗанов сүзләренә караганда, исем-псевдонимы Әхмәд Гирмияни дигән төрек авторының, башка әсәрләреннән кала, әлеге әсәре хәтта Төркиянең үзендә бер генә нөсхәдә дә сакланмаган. Гап-гади татар авылында төрек авторының мәшһүр әсәре табылу – халкының дәрәҗәсен, аларның мәдәни үсешен, аралашу даирәсен күзаллау өчен искитмәле дәлил.

Китап күчерү белән укымышлы кешеләр һәм дә мәдрәсәдә шәкертләре шөгыльләнгән. Алар күчергән кульязма китаплар үзләре белән туган ягына кайткан, яисә инде аларны башка кешеләр соравы буенча күчерәләр, шулай итеп бер җирдә эшләнгән китап территориаль яктан бөтенләй башка төбәктә дә табылырга мөмкин. Мисал өчен, Буа районы Күл Черкене авылында табылган «Мишкәт-ел-әнвар» китабы Тау ягы Норлат авылында 1854 елның 15 маенда дамелла Фәхреддин бине Мостай әл-Болгари мәдрәсәсендә күчерелеп беткән, шул ук китапның башка күчермәсе, 1776 елда Бәрәскәдә мелла Бикчәнтәй мәдрәсәсендә күчерелгәне, Тәтеш районы Аллабирде авылында табылган. 1770 елны Тау ягы Кариле (хәзерге Кама Тамагы районы) авылында күчерелгән мәшһүр Сәгъдинең «Шәрхе Китаби Гөлстан» китабының татарча тәрҗемәсе Рязань өлкәсе Түбән авылында (русча исеме Шилино) табыла. Дини китаплар белән беррәттән шәрык классикасы да татарлар арасында бик популяр була. Татарлар оригиналда да, тәрҗемә ителгән күчермәдә дә укыганнар. Татар күчәргә мәҗбүр булган вакытта да аның китабы һәрвакыт үзе белән булган. Олы Әтрәч авылы шәкерте Җиһанша бине Корбанның да Казан шәһәренең Яңа бистәсендә Шаһи Әхмәт мәдрәсәсендә укыганда язган китабы галимнәр тарафыннан ачыклана. Әтрәч авылында табылган бу китапта язу вакыты күрсәтелмәгән, ә язу почеркы, кара, кәгазь төре буенча, XIX йөз урталары кульязмасы булырга тиеш. Буа районы Әхмәт авылында табылган тагын бер әһәмиятле кульязманы 1881 елда Гайнетдин исемле шәкерт Фәхретдин Пәшли мәдрәсәсендә укыганда күчергән, кызганычка каршы әлеге остаз кайсы мәдрәсәдә укытканлыгын ачыклау мөмкин булмады. Килдураз авылында (Буа районы) табылган зур күләмле – 160 кәгазьле урта форматтагы кульязманың Әхмәдҗан улы Рәхимҗан исемле шәкерт Норлат мәдрәсәсендә укыганда күчереп язган. Норлат авылы хәзерге Буа районының кечерәк кенә авылы, әмма үз вакытында бу авылда тирә-якта абруй казанган мәдрәсә эшләп килгән. Кызганычка каршы, бу мәдрәсәнең тулы тарихын торгызырлык тарихи документлар сакланып калмаган, шулай

[10] XIV–XV гасырларга карый торган әдәби әсәр.

булса да, халык сөйләме, шәкерт язмалары аша да бу мәдрәсәнең мәгърифәтчел ролен күзаллау кыен түгел.

Китап күчерүчеләр куйган тәхәллүс буенча да бу як кешеләренең татарның үткәненә, аның тарихына мөнәсәбәтен күзаллап була. Күп кенә кульязмаларда тәхәллүс итеп үз авылларының исемен күрсәтү, шул төбәккә бәйлелекне ассызыклау күренә. Мисал өчен, Черкен авылында табылган «Һидая» дип аталган кульязмада авторның исеме колофон рәвештә «Кятибәһү [моны язучы] Кәлибула ибне мелла Сәйфулла-Болгари», ә мирас буларак кульязма хуҗасы булып калган улы тәхәллүсендә җирлекне, кече Ватанын тагын да тәфсиллерәк төгәенли: «Сахибе һәза китаб Нөсратулла ибне дамелла Кәлимулла әл-Черкени әл-Болгари әл-Җәбелстани» [Бу китапның хуҗасы Нөсратулла ибне дамелла Кәлимулла әл-Черкенле, Болгарлы һәм Тау ягыныкы].

Хәзерге Апас районына карый торган Коллар авылында китап күчерүчеләр булган, бу авылда китап алу-сату шактый таралган булуына кульязма китаплардагы язмалар да ишарәли. Күл Черкене авылында табылган 1843 елга карый торган китапны да чыгышы белән Коллар авылыннан булган Казан шәһәрендә Хәбибулла хәзрәттә укучы Габденнасыйр бине Сәйфулла Колларый әт-Тави күчергән. Габденнасыйр әт-Тави милкендә булган китапның сатылу тарихы кульязмада хәтта рәсми итеп теркәлгән: «1854 нче [елда] декабрьнең унысында Бурнаш мелла Сәгыйдетдиндән бу «Мишкәт-ел-әнвар»не алдым. Бишнә илендә Әхмәд Гобәйдулла угылы. Хакы 15 сум. Алла хәерле кылыр». Шулай ук Санкт-Петербургта саклanучы бер кульязма китапта да Коллар авылы хакында языла: «1874 нче елда апрельнең 10 нчы көнендә алдым. Алдым китапчыдан: 25 тиен көмеш. Сахибәһү вә маликәһү [иясе, хуҗасы] Хафизеддин әл-Колларый әл-Болгари»[11].

Кульязмаларның эчтәлегенә карап, нинди китапларның халык арасында таралуы, халыкның ихтыяҗы булган китапларны барлап, шул чор кешеләренең яшәү халәтен, кызыксынуларын да күреп була. Мәдрәсәләрдә укытыла торган грамматика китаплары, төрле дәреслекләр белән беррәттән, шәрык, татар әдәбияты әсәрләре табылуы – татар авылында яшәүче гади игенчеләрнең аң-белем дәрәҗәсен аңларга ярдәм итә. Мисал өчен, Килдураз авылында табылган кульязмада Рәхимҗан Әхмәтҗан улы гарәп теле грамматикасы, дини текстлар белән беррәттән тәрәзә ябыштыру өчен ясала торган замазка рецепты да, шул ук вакытта үзе иҗат иткән, шәкертләр стилендәге, тө ртмәле җырлар, шигырьләрен дә язган. Ә менә Буа районы Әхмәт авылы Гайнетдин исемле шәкерт язмаларында татар әдәбиятының күренекле шагыйре Габдерәхим Утыз Имәнинең «Гавариф әз-заман» поэмасының күчермәсе, Габделҗәббар Кандалыйның, Физулинең әсәрләреннән өзекләр күрергә мөмкин. Китапны төзүченең сайлаган әсәрләре буенча аның фарсы-таҗик әдәбияты: Ха-

[11] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. – Казан: Татарстан китап нәш-ты, 1994. – Б. 118.

физ, Сәгъди, Фәраби хезмәтләреннән дә, татар әдәбияты классик әсәрләреннән дә хәбәрдар булуына инанырга була[12].

Кама Тамагы районы Олы Кариле авылының Хәсән исемле шәкертнең кулъязма дәфтәре фән өчен гаять үзенчәлекле табыш. Ул – «Түләк белән Сусыл» лиро-эпик дастанының борынгы тексты. Бу уникаль текстны аның кызы саклап кала, гаиләдә башка кулъязмалар да булган, әмма еллар аша бары тик монысы гына безнең көннәргә килеп җитә алган һәм ул татар әдәбияты тарихы өчен бәһасез зур табыш[13]. «Түләк белән Сусыл» эпосын М. Гафури бастыруы билгеле, М. Госманов фикере буенча, М. Гафури бастырган вариант эчтәлеге ягыннан Олы Кариледә табылган язма белән бик якыннар һәм ул шул ук вакытта, Олы Кариле вариантының борынгылыгы, элгәрелеге сурәтләү чаралары, архаик өлешләре күп булу белән үзенчәлекле. Иң мөһиме – Олы Кариледә табылган вариант тел ягыннан караганда да борынгырак күчермә булуы хакында сөйли. Бу авылның электән үк укымышлы авыл икәнлегенә тагын да мисаллар китерергә мөмкин. Кариледә мулла булып торган Баһадиршаһ хәзрәтнең үзе язган бик күп китаплары булуы билгеле. Ул туксанга җитеп кенә вафат булган. Вафатыннан соң барлык китапларын Лаеш өязенең Күгәрчен авылына алып киткән булырга тиешләр, чөнки анда аның варислары яшәгән. Әмма, кызганыч, бу китапларның эзе шуның белән югала. Варислары гади тормышлы кешеләр булып, мулланың китапларының бәһасен белмәгәннәр[14].

Апас районы Багыш авылында табылган кулъязма татар халык авыз иҗатында аерым бер үзенчәлекле жанр – иллаһи бәетләр җыентыгы. Кызганычка каршы, татарларда бу мөһим әсәрләр күп сакланмаган, әмма алар аерым бер кызыклы, халыкның эчке рухи халәтен чагылдыра торган әсәрләр. Бу кулъязма ике кеше – Миңнегали Шакир улы һәм Хәлиулла Шакир улы күчермәләреннән тора: 65 битлек кулъязмада барлыгы 2500 шигъри юл. Бу кулъязманы табучы һәм аны тасвирлаучы галим М. Госманов фикере буенча, шуның дүрттән бер өлеше фән өчен яңалык булган юллар. Бу язманы үзендә Гани бабай Фәләхев кадерләп саклаган. Буа районы Кайбыч авылының Зариф Идрисов шәкерт вакытында, үз куллары белән күчергән язмада, 216 юллы «Үсия бәете», «Таз бәете», «Герман сугышы бәете» әсәрләре бар. Бу җыентыктагы аерым игътибарга лаек әсәр ул – «Яңа мөселман бәете», бу әсәр христианлыктан яңадан исламга кайтучы хакындагы бәет, М. Госманов моны Тау ягында еш күзәтелгән хәлнең чагылышы дип бәяли[15].

---

[12] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. – Казан: Татарстан китап нәш-ты, 1994. – Б. 118–119.

[13] Шунда ук. – Б. 228.

[14] Духовное наследие: поиски и открытия / под ред. И. Г. Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып. 4. – С. 68.

[15] Шунда ук. – С. 122.

Шәкертләр җитди текстлар белән шаян шигырьләр, хәтта шаярулы «дога текстлары» да иҗат иткәннәр. Апас районының Бортас авылында сакланган шундый текста: «Ак куй [үз] баласын күрмәсә, ничек түзмәйдер, бу кыз мине күрмәсә, шулай түзмәсен, минем артымдин калмасын – я раббем, бер раббем, бар раббем, сиңа ышанып әйтәмен»[16] дигән «дога» сүзләре бар.

Шәкертләр тарафыннан башка төрки телле текстларны күчергән кулъязмалар булу да, аларның аралашу даирәсен һәм дә башка халыкларның телен, аларның әсәрләрен белүгә бер мисал була ала. Казахстан, Үзбәкстан белән чиктәш җирләрдә генә түгел, Тау ягында казах текстын күчергән кулъязма да табылган. Дөрес, күчерүче шәкерт текстны татар теленә якынайтып, татар укучысына аңлаешлы булырлык итеп, үзгәртебрәк бирә. Шәкертләрнең мәхәббәт шигырьләре, җырлары тупланган дәфтәрләр 1960 еллардагы археографик экспедиция вакытында Буа районы Яңа Чәчкап, Югары Наратбаш, Кайбыч, Яңа Тинчәле, Апас районы Багыш, Түбән Балтай, Татар Пүчинкәсе, Шәмбалыкчы[17] һ. б. авылларда табыла. Казан татарлары арасында сирәк очрый торган «Яр-яр» җырын да шәкерт дәфтәрләре саклап калган. Төрки халыклар арасында еш очрый торган җыр булса да, Казан татарлары кулланган, алар җырлаган варианты озак вакытлар ачыкланмый. М. Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедиция аларны Кама Тамагының Иске Казиле, Апас районының Иске Йомралы авылларында таба. XVIII гасыр ахырына караган кулъязмада да әлеге җыр текстын күчерүче Аллабирде исемле татар шәкерте дип күрсәтелә. «Яр-яр» – ул җыр гына, ә тулы бер йола, татар халкының кыз бирү, кыз алу белән бәйле йоласы. Шул ук Тау ягының Чүпрәле районына караган Шатрашан авылында аның тагын да борынгырак варианты ачыклана, текст барлыгы 62 шигъри юлдан торган. «Яр-яр» җырының текстлары, вариантлары, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә табылса да, мисал өчен, А. Фәтхи Актаныш ягыннан бер вариантын тапкан була, сан ягыннан Тау ягында күбрәк очрый.

Тәтеш өязе җирләрендә табылган киң тематикалы кулъязмалар, борынгы китаплар халыкның рухи халәте, аның белем дәрәҗәсе хакында сөйли торган мисал. Китап күчерүчеләренең булуы да, китап алыш-биреше баруы да халык турында фикерләргә мөмкинлек бирә. Бу үз чиратында, авыл җиренең интелектуаль югарылыктагы шәхесләр бирә алганын күрсәтә. Шул ук вакытта бу төбәктә шәрык илләренең классик әсәрләре, дини китаплары табылу – халыкның башка культуралар, халыклар белән диалогы аша да аларның рухи югарылына күрсәткеч була ала. Экспедицияләр нәтиҗәсендә табылган язма мирас Тау ягының, аерым алганда, Тәтеш төбәгенең, китаплы як булуын раслады.

[16] Шунда ук. – С. 128.
[17] Шунда ук. – С. 146.

## *§ 3. Тәтеш төбәгендә халык бәйрәмнәре, аш-су гадәтләре*

Татар халкы үзенең гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары белән бай халык. Аларның формалашуы, үсүе, камилләшүе гасырлар дәвамында барган. Һәр вакыйганың үз йоласы, гадәте бар, аларны буыннан-буынга аны саклап килергә тырышканнар. Татарларда халыкның иң зур бәйрәмнәреннән, Җыен һәм Сабан туен атарга кирәктер. Моннан кала, көндәлек тормышта бик күп башка бәйрәмнәр дә билгеләнгән. Инкыйлабка кадәрге чорда халыкның иң яраткан бәйрәме – Сабан туеннан да бигрәк, Җыен булган. Җыен бәйрәме – ул аерым авылларныкы гына түгел, ә берничә авыл берләштереп уздыра торган бәйрәм. Шул ук вакытта Җыен ул бәйрәм генә дә түгел, ул, үз чиратында, халык үзе билгеләгән административ-территориаль бүленеш мәгънәсенә дә ия булган. Җыен округлары беркем кушуы белән бүленмәгән, ә ул гасырлар дәвамында тарихи җирлектә формалашкан. Билгеле бер авылларның бер-берсе белән аралашуы, аларның бергәләп бәйрәм уздыруы очраклы түгел. Тәтеш төбәгендә Җыен округлары халык арасында бик популяр булмаса да, бөтенләй ук югалган күренеш тә булмаган. Икенче бәйрәм – ул, әлбәттә Сабан туе. Аларның кайсы беренчел, ә кайсы икенчел дигән сорауга җавап бирү мөмкин түгел, халык аларны төрле вакытта уздырган һәм икесенең дә үз функциясе булган. Халык тарафыннан да алар бертөрле кабул ителгәннәр, әмма Җыеннан аермалы буларак Сабан туеның гомере, белүебезчә, озынрак булды. Җыен инде хәзерге татар халкы тормышыннан төшеп калды, ә Сабан туе үзенең беренчел эчтәлегеннән шактый ераклашса да, яшәвен дәвам итә, хәзер дә бәйрәм ителә.

Татарларда чәчү беткәч, зур бәйрәм үткәрү гадәте бар. Тарихчы Гайнетдин Әхмәрев фикере буенча, Сабан туе бәйрәме игенчелек белән шөгыльләнгән, озак гасырлар утрак тормышта гомер иткән халыклар яшәгән төбәкләрдә үткәрелә, аларда Сабан туеның тарихы борынгырак була. Үткәнендә күчмәлек чоры озаграк булганнарында Сабан туе түгел, ә Җыен бәйрәме популяррак булуы хакында яза. Тарихчы хәтта аларның эчтәлеге, аларда уйнала торган уеннар арасында да аерма барлыгын күрсәтә. Тәтеш төбәге татарлары, әлбәттә, Сабан туен бәйрәм иткәннәр, әмма, шулай булса да, аларда Җыен бәйрәменең дә чагылышы бар.

*Җыен*. Тарихчы Г. Әхмәрев Тау ягында – үзенең туган төбәге Яшел Үзән районына карый торган авылларның Җыен бәйрәмнәре хакында тасвирлы мәгълүмат бирә[1]. Ә Тәтеш өязенә караган җыеннар хакында халык хәтерендә саклганганны җыйган һәм өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләре аша күзалларга

---

[1] Салахова Э.К. Татарские народные праздники и традиции глазами историка // Историческая этнология. 2019. – Т. 4. – № 1. – С. 151–160.

була. Шундый зур Җыенның берсе – Кушкапка дип аталган. Шундагы халык хәтере буенча Кушкапка Җыены Апас төбәгенең бик борынгы һәм авторитетлы бәйрәме саналган. Кушкапка уздырылу вакытын халык табигать күренешләре аша билгеләгән, ягъни бу бәйрәмнең вакыты – игеннәр өлгергән, арышлар серкә очырган вакыт. Кушкапка Сабан туеннан алданрак үткәрелгән. Ул үз эченә 28 авылны алган: Югары, Түбән, Урта Балтай, Олы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чирү-Бураш, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки, Багыш, Ябалак, Коллар, Морзалар авыллары һ.б. кергән. Бу хәзерге Апас районына карый торган авылларны үз эченә алган зур Җыен округы, аның үзәге булып Түбән Балтай авылы саналган. Уздыру урыны булып Урта Балтай белән Түбән Балтай (Апас районы) авыллары арасындагы җирлек сайланган[2]. Бу бәйрәм июнь уртасында арыш чәчәк аткан вакытта үткәрелгән. «Кушкапкага яңгыр төшмәсә, халыкның иңе төшә» дигән әйтем дә булган. Җомга көнне Түбән Балтай авылында мәйдан корылган, аңа 28 авылдан да бәйрәмгә катнашырга теләге булган һәркем килә алган. Ул, бигрәк тә бала-чаганың, бик нык көтеп алган бәйрәме була. Атка утыртып бәйрәмгә алып барсыннан өчен, бала-чагалар атка печән җыя иделәр, дип искә ала җирле халык[3]. Ерак шәһәрләргә читкә китеп эшләүчеләр дә туган якларына шушы бәйрәмне туры китереп кайтырга тырышканнар.

Алданрак яшьләр өчен аерым уеннар оештырылган, ә анысын Кече Кушкапка дип атаганнар. Бәйрәмгә төрле вак-төяк сатучылар да, кәмит тә (кәмит дип бу якларда карусельләрне атыйлар) килә торган булган. Мондый кәмиткә халык инде акчасын алдан ук әзерләп куйган, җыеп барган. Җигүле кыңгыраулы атларга утырып әйләнгәннәр. Тирә-якта барабаннар кагып торып халык кәефен күтәргәннәр. Шулай итеп, халык өчен уенлы, сатып алу мөмкинлеге дә булган көтелгән бер кызыклы күренеш була. Бәйрәм башында Кушкапка буласы урында тирәли атлар белән әйләнеп чыгу гадәте дә булган. Кызыл Тау (Коллар) авылы кешеләре хәтерендә калганнар буенча, Кушкапка Җыены вакытында авыл башындагы болынга төшеп уеннар уйнаганнар, биегәннәр. Болынга төшү дә «куш капка», ягъни парлы капка рәвешендә барган, Җыен исеме дә шуннан алынган булырга тиеш. Кушкапканы уздыруны Түбән Балтай авылы (Апас районы) кешеләре дә хәтерли. Куш капка Җыены ул Сабан туена кадәр үткәрелгән. Бу Җыеннарда уйнала торган уеннар да халыкның иҗаты. Мисал өчен, Зәлидә – җырлы уен. Идрәс-Тенки авылында галимнәр тарафыннан Зәлидә дә җырлана торган җырдан өзек язып алынган. Бу уенны Наза уены дип тә атаганнар.

---

[2] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 191.

[3] Шунда ук. – Б. 192.

Сандугачым син икәнсең,
Күрмәдем килгәнеңне.
Тулган айга ошатам
Җылмаеп көлгәнеңне.
Ал бирәм алучыга,
Гөл бирәм алучыга.
Ал тирәле җаулык бирәм
Озата баручыга[4].

Яшьләр пар-пар булып тезелеп басалар да, берсе көтүче булып ялгыз тора, баштагы парлар аерылып китеп чаба башлыйлар, көтүче аларны тотарга тиеш була, ялгыз калганы аннары көтүче санала. Бу уен «Тоттырма» дип аталган һәм шул Җыен уеннарында уйналган. Яшь кызлар арасында яулыклар белән уйнала торган «Сукыр лампа», «Йөзек салыш» «Патша сикерү», «Чиша тәгәрәтү» һ.б. дигән уеннар була. Чиша – Тау ягы сөйләшендә шешә дигән сүзне аңлата. Шешәне әйләндереп җибәрәләр дә, авыз ягы кемгә карый, шул я җырларга, я биергә тиеш. «Патша сикерү» – ул җиргә сызылган шакмаклар буенча сикереп уйнау, сызыкка аяк белән тию җиңелү саналган. «Аламын кош, бирәмен кош» дигәне сату-алу уены кебек уйналган. Балаларның да, яшьләрнең дә яраткан кесә, ягъни хәзергечә әйткәндә, өстәл уены – «Чуерташ», ул 5 кечкенә чуер таш белән уйнала торган уен. Балаларның яратып уйный торган уеннары «Ызба-ызба», ягъни чыбык-чабык җыеп, шулардан өй ясап уйныйлар, ватык чынаяк кисәкләре белән дә уйнаганнар. Тау ягында өйне ызба дип атаганнарын искәртик.

Кушкапкадан соң, июнь башында Каравыл тавы дип атала тоган Бәбки, Колгана, Дәүеш, Каенлык (Апас, Буа районнары) яшьләренең җырлы-биюле һәм уеннар уйнала торган Җыены уздырылган.

Үзәге Килдураз авылы (Буа районы) булган авыллар бәйрәме Кәлти дип аталган. Кәлти җыенына Килдураз, Колгына, Кабалан, Өчмунча, Үгез Куагы (Буа районы) авыллары кергән. Җомга көнне Килдураз авылы янында ат чабышлары узган, аннан авылда зур Җыен ярминкәсе үткәрелгән. Аны 15 нче майдан башлап уздырганнар[5].

Тәтеш өязенең Каенлык авылында (Буа районы) үтә дә үзенчәлекле бәйрәм булган. Ул Майуны дип аталган. Хәзерге буын да бу бәйрәм хакында белә, хәтта хәзер дә уза. Бу шифалы үләннәр чыккач, табигатьнең җанлануына багышлап уздырыла торган бәйрәм. Кунаклар җыелгач, бергәләп урманга барып шифалы үләннәр җыйганнар, аннан күңел ачулар булган. Исеме бу май аеның 10 нчы числоларында үткәрелгәнгә шулай аталган диләр. Шунысын да әйтергә кирәк, тирә-яктагы башка авылларда мондый бәйрәм-йоланың булуы

[4] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 145–147.

[5] Шунда ук. – Б. 167.

күзәтелми, бары бу авылның гына уникаль бәйрәме ул. Гомумән, тирә-якта игенчелек белән көн күрүче татарның урман тормышына әлләни игътибары булмаганны исәпкә алсак, бу ниндидер тәэсир нәтиҗәсендә булуы, яисә халкының үзенчәлекле тарихы хакында фикерләргә урын калдыра. Галимнәр күзәтүе буенча, моңа охшаган «юа җыены» Ык буе бассейнында яшәгән халыкларда күзәтелә.

Апас районына карый торган Кара Борнаш, Дәүеш, Кошта авылларында Кече Җуа һәм Олы җуа, яисә Җуалык дигән бәйрәм уздырылган, әмма ул дару үләннәре җыю белән бәйле түгел, уздыру вакыты 20–22 нче май көннәрендә булган. Бу бәйрәм бер-берсенә кунака йөрү, кунак итү вакыты[6].

Җыен кысаларында да, авыллар бергәләп тә уеннар, ярышлар уздыру гадәте була. Шундыйлардан, елга бер мәртәбә генә – 19 нчы майда уздырыла торган Олы болын уен-ярышлары үткән. Монда Шәмәк һәм Коллар авылы (Апас районы) яшьләре катнашкан, шул ук Тәтеш өязенең хәзерге Кама Тамагына кергән өлеше авыллары: Олы Салтык, Олы Яңасала, Данышь, Олы Кариле авыллары яшьләре бергәләп Сулып җыены уздырганнар. Бу уен 1 нче июньнән башлап уздырыла торган булган, ул бер көнлек уеннар рәвешендә барган. Бу уеннарны Сирәм [чирәм] дип тә атаганнар, чөнки алар яңа йомшак чирәм чыккач, 1 июньдә, шул чирәм өстендәге уеннар буларак үткәргәннәр[7]. Мондый күмәк бәйрәмнәр халыкның бер-берсе белән аралашуына, яшьләрнең танышуына, туганлашуга, бер-берсенә кунакка йөрүләренә китергән. Мондый бәйрәм көннәрендә һәр өйдә кунаклар булган, аларны сыйлаганнар, төрле уен, җыр-бию белән дәвам иткән. Метрика язмаларындагы никахлашу даирәсенә игътибар итсәк, никахлар, нигездә, шушы Җыен кысаларында аралашкан авыл кешеләре арасында барган.

Чабыр дигән Җыен хәзерге Кама Тамагы районына керә торган Бәки, Олы, Кече Кариле, Чаллы, Олы һәм Кече Болгаер, Келәнче авылларының бәйрәме була. Ул 18 нче июньнән башлап, Христофоровка дигән алпавыт утарында үткән. Шул көннәрдә Чабыр исемендә ярминкә дә эшләгән.

Хәзерге Апас районына кергән Энәле, Карабай, Иске Җомралы авыллары 20–25 нче май көннәреннән башлап, Шыкма дигән Җыенга җыела торган булалар, ә Шыкмадан соң, июнь башында, хәзерге вакытта район үзәге булган Апас авылының үзендә Көлсит бәйрәме уздырылган. Чирү-Бураш авылында (Апас районы) Тау уен Җыены, яисә Биек Тау исемендәге уеннар бәйрәме үткән, аның кайчан уздырылуы хакында төгәл генә мәгълүмат сакланмаган. Татар авылларының бәйрәмнәре кайвакытта зур базарлы рус авыллары бәйрәмнәре белән, еш кына зур ярминкәләр узган вакытка туры китереп оештырылган. Халык бер үк вакытта сату-алу эшен дә башкарган, ял да

[6] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 167.

[7] Шунда ук. – Б. 90.

иткән. Рус Ындырчысы авылындагы ярминкә барган көннәрдә, июнь ахырында, Югары Ындырчы, Шәмбалыкчы, Болын Балыкчы, Кормаш, Үтәмеш, Түбән Биябаш (Апас районы) авыл кешеләре Кызыл Яр (Җар) Җыенына җыелганнар.

Тау ягы мәлки керәшеннәренең дә үз Җыены, уеннары булган. Алар чиркәү бәйрәмнәре белән бәйләп үткәрелгән. Мисал өчен Троица вакытында Семик бәйрәме узган, Петров көндә соңгы йомгаклау уеннарын үткәргәннәр. Аларга күрше чуаш авылы яшьләре дә кушыла торган булган[8]. Бу бәйрәм Семык исемендә мариларда да бар, алар аны җәй башлану бәйрәме буларак үткәрәләр.

Пасха узып 7 атна үткәннән соң, куаклар чәчәк ата башлаган вакытта, Чуаш Ковалында үткәрелгән ярминкәгә татарлар да бик теләп кушылганнар. Бакырчы, Сүнчәләй, Акъегет, Олы Кошман, Иске Чәчкап, Олы Кайбыч, Җабалак, Татар Исламы (Яшел Үзән районы) авылы татарлары бу Җыенны Симек (Чимек) дип татарчалаштырып атап йөрткәннәр. Чимек Апас районына карый торган Балтай авылында да үткән, 3–4 көн дәвамында барган. Тарихчы Г. Әхмәрев тә татарлар арасында бу Җыен бәйрәм ителүен, халыкның бу бәйрәмгә яратып йөрүен яза. Татарларга христиан динен тотучы халыклар белән тыгыз элемтәдә, күршедә яшәү нәтиҗәсендә кергән, дип саный. Бу, үз чиратында, җирле халыкның нинди халык булуына, нинди дин тотуларына карамастан, бер-берсе белән дустанә мөнәсәбәттә булу нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Симек ул аерым бер дин белән бәйле күренеш түгел, ә Җыенның бер формасы, бер чагылышы итеп саный[9].

Тау ягының хәзерге Яшел Үзән һәм Кайбыч районына караган өлеше Тәтеш өязенә кермәсә дә, ул җирләрдә булган Җыеннарны да әйтеп китәргә кирәк, чөнки халык тормышы рәсми административ-территориаль бүленеш белән чикләнми. Тәтеш өязе татарлары Зөя, Чуел өязе авылларындагы туганнары, якыннары белән аралашып яшәгән, аларга кунакка йөргән. Шулай ук Г. Әхмәрев тасвирлап калдырган «Таган асты», «Кала ала уен» Күгәй Әрә, Айдар Тау иле, Мамадыш, Карашәм, Татар Наратлысы авыллары яшьләренең уеннары белән барган күңел ачу бәйрәмнәре була. «Таган асты» бәйрәмендә таган атыну (карусель) бәйрәмнең иң матур мизгеле саналган. Норлат, Мулла иле, Бузый авылларының Тикен бәйрәме христианнарның «День Тихвинской Божьей Матери»га туры китереп эшләнгән. Тикен дигән исеме шуннан татарчалаштырып бирелгән. Бу бәйрәм 22 нче июньгә туры килгән, ә 23 июнь нче көнне Утяшка авылында ярминкә узган. Тикен бу конфедерациянең

[8] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 91.

[9] Әхмәрев Г. Болгар тарихы. – Казан: Бәянелхак, 1909. – 128 б.

соңгы Җыены булган, аннан урак эшләре башланган, бәйрәм итәргә вакыт калмаган. Шуңа да «Тикен җитте – эш җитте», дигән гыйбарә бар[10].

*Сабан туе.* Җыен бәйрәмнәре инкыйлабка кадәрге чорда гөрләп торса да, зур әтрафны биләсә дә, совет чорында бу бәйрәм югала, татар авылларының болай берләшеп, зурлап җыелып аралашуы хупланмый, ул совет власте өчен кирәкмәгән гамәл булган. Сабан туе бәйрәмнәренең бу яктан язмышлары бәхетлерәк, аларның гомере озынрак. Тау ягында, аерым алганда Тәтеш төбәгендәге Сабан туйлары, аерым бәйрәм генә түгел, ә ярминкәле, уенлы-ярышлы тулы бер комплекслы мероприятия була. Болын-Балыкчы авылы кешеләре хәтере буенча, Кызыл яр дигән урында ат чабышы да, көрәш тә, кәмит һәм ярминкәсе булган Сабан туе уздырганнар. Зөя буенда сарык чалганнар, хәтта халык хәтере буенча, бу вакыгага сыра да әзерләгәннәр. Күп кунак чакырылган. Чынлап та, Сабан туенда, татар авылларында да, кызганыч ки, сырага урын булган. Тарихчы Г. Әхмәрев «Тәтеш өязенең Күл-Черкене карьясендә [авылында] быелгы Сабан туенда 117 чирек аракы эчеп бетергәннәр, имеш», дип язган газетадагы хәбәргә җавап итеп Сабан туе турында махсус аңлатма мәкаләсе яза. Әйе, кызганыч, андый хәлләр дә булуы, ихтимал, әмма аерым очракларны күпертеп Болгар чорыннан ук килгән, татарларның кадерле бәйрәмнәренә тап төшерү дөрес булмас иде, бәлки болай таплау махсус та эшләнүе мөмкин дигән фикерен белдерә[11]. Сабан туе – ул кунаклар чакырыла торган бәйрәм, туган-тумача, нәселдәшләр бергә җыелып аралаша торган, бәйрәм итә торган чара. Мисал өчен, Багыш авылында Сабан туе чәчүгә кадәр үк үткәрелгән, зур эш башланганчы, бәйрәм ясап, көч туплап куйганнар, ә инде эшне төгәлләгәч Кушкапка Җыены вакыты җиткән. Дәүләки авылында Сабан туе июньдә, чәчү беткәч оештырылган. Һәр авылның үзенә җайлы үткәрү вакыты булган, аның датасына табигать шартлары да тәэсир иткән. Апас районы Багыш авылы кешеләренең хәтерләре буенча, Сабан туена кабартмалар, җуачалар (бавырсак) пешергәннәр, бәлеш салганнар, токмач басканнар. Кыш чыккан каклаган казны Сабан туе өчен саклап торганнар. Җыен уеннарында күбрәк яшьләр катнашса, Сабан туе ул олыларны да берләштергән бәйрәм була. Яшьләр матур киемнәрен киеп күңел ачсалар, олы буын бу уеннарны карарга килгән.

Бәйрәмнәргә бүләк җыюда да һәрбер төбәкнең үз үзенчәлеге булган. Мисал өчен, Сабан туе, яисә карга боткасына йомырка җыйган вакытта кайбер өлкәләрдә җыючылар җәяү йөрсәләр, кайберләрендә бүләк җыючылар ат белән йөриләр. Ат белән җыю күбрәк Уржум, Уфа якларында булса, ә җир эше белән көн күрүче игенчеләр яшәгән якларда җәяү йөреп бүләк җыйганнар. Тәтеш өязендә бүләкне яшьүсмерләр җәяүләп җыя торган булганнар.

[10] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 166–167.

[11] Әхмәрев Г. Сабан туе // Казан мөхбире. – 1906. – 7 май.

Апас районына карый торган Тутай авылында Сабан туена бүләкне җигелгән атларны бизәп, гармун уйнап, җырлап, биеп җыйганнар. Сабан туеның төп бүләге яулык, йомырка булган. Яшь киленнәр үзләренең кул эшләрен дә Сабан туе бүләге итеп биргәннәр. Сабан туе – ул яшь киленнең уңганлыгын күрсәтә торган урын, һәр килен үзе чиккән сөлгене бүләк итеп тапшырырга тырышкан. Шул ук районның Болын-Балыкчы авылында бүләкне җәяү генә гармуннар белән колгага бәйләп җыйганнар. Чәчүгә чыкканчы, Сабан туе, бәйрәме кысаларында, Урта Балтай, Кече Балтай (Апас районы) халкы атлар чабыштырган. Атларның көчен карау максатыннан да, яхшы атларны авыл янындагы Каравыл тавына чаптырып менгәннәр. Дәүештә Кыз тавына менә торган булганнар[12].

*Халык уеннары.* Зәлидә уенына аерым игътибар итәсе килә, чөнки ул инкыйлабка кадәр татарларның җырлы-биюле уеннарында төп урынны алып торган, Зәлидә хәзерге хореографиядә дә тарихи күренеш буларак яктыртылып килә. Тау ягында Зәлидә уены уйналган, аның бу якта үткәрелү тәртибе кызыклы. Зәлидәне Сабан туенда да, ташу киткәндә дә, кичке уеннар вакытында да уйнаганнар. Мисал өчен, Дәүеш авылында Кыз тавына менеп, корырак җирне сайлап Зәлидә уены өчен әзерли торган булганнар. Уртада берәү торган, тирә-яктагылар аңа җыр җырлаганнар, ул әйләнеп, биеп, кем янына килеп баса – ул уртада кала. Шул ук уеннар кысасында «куышлы уен» уйнаганнар. Ул үзенә күрә, күңел ачу да, шул ук вакытта яр сайлауга да ярдәм иткән. «Тоттырма чабу» уенында егетләр кызлар белән куышлыда үзенә ошаганнарны пар итеп сайлаганнар[13].

Басуларны чәчү алдыннан татарларда үз йолалары булган, кайсыдыр якта чәчү алдыннан уңыш әйбәт булсын дип, җиргә йомырка күмгәннәр. Тәтеш өязенең Черкен авылында (Буа районы) үзенчәлекле йола була: ишек алдыннан чыгар алдыннан атның башына он сипкәннәр, ипи каптырганнар. «Атлар хакына да икмәк булсын», дигән ышану белән эшләнгән. Уңыш әйбәт булсын дип, я муллага, я ярлырак кешегә сәдака итеп оннан, яисә йомыркадан ясалган ризык илткәннәр[14]. Керәшен татарларында йомырка белән ипи кисәген буразнага күмеп кую йоласы булган. Тәтеш өязе Иске Корбаш авылы (мәлки) керәшеннәре чәчү алдыннан сыер корбан иткәннәр. XIX гасырның 60 нчы елларында уңыш булсын, дигән теләк белән хәтта ат чалганнар. Бу йоланы алар «сабан корманы [корбаны]» дип атаганнар. Корбаннарны, еш кына зиратларда, бигрәк тә иске зиратларда, ә Тәтеш өязенә кергән Олы Кариледә (Кама Тамагы районы) корбанны арыш басуында чалганнар.

[12] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 190.

[13] Шунда ук.

[14] Уразманова Р. К. Обряды и праздники татар Поволжья и Приуралья (Годовой цикл XIX – нач. XX вв.). – Казань: ПИК «Дом печати», 2001. – С. 58.

Чәчкәндә бер төрле йола үтәлсә, уңыш яхшы итеп үссен, мул булсын дип башка йолалар да үтәлгән, җәй көне үтә торган йолалардан яңгыр теләү, яңгыр чакыру йоласы. Бу йола, нигездә, керәшен татарларында очраса да, Тәтеш өязе татарларында да мондый йола, сирәгрәк кенә булса да, күзәтелгән. Ул йола «яңгыр келәве, яисә, яңгыр теләү» дип аталган[15]. Мисал өчен, татарлар гомер итә торган Черкен авылында (Буа районы) бу йола үтәлгән[16], бу гадәтнең әле хәзергә көнгә кадәр дә үтәлүен Килдураз волостена кергән авылларда күзәтергә була. Теләүләр белән булган бу гадәтләрдә мәҗүсилек чалымнары бар, әмма ислам кабул итүгә бик күп вакыт үтсә дә, халык тормышында мәҗүсилек чорыннан калган гадәтләр дә үтәлгәне күренә. Халык аларны үзләренең борынгы гадәтләре итеп кабул иткән, муллалар да моңа әлләни каршылык күрсәтмәгән. Мисал өчен, Кече Карамалы авылында (Кама Тамагы) хәтта бүгенге көндә дә «Келәү куагы» дигән урын бар. Ел саен Шилек дигән йола үтиләр, корбан итеп тавык суялар, теләкләр телиләр.

Халык бәйрәмсез яшәмәгән, бәйрәм ул халык тарафыннан тудырылган һәм гасырлар дәвамында формалашып, камилләшеп килгән тарихи үткәненең чагылышы. Бәйрәмнәр халыкның менталитетын, аның үзенчәлеген, тарихта үткән юлын күрсәтә. Кызганыч, бәйрәм ул язма чыганак түгел, халык яшәткәндә – яши, кулланылмый икән – югала. Шуңа да күп кенә бәйрәмнәр хакында хәбәрләр инде югалган. Биредә тасвирланганнары язма чыганакларда, яисә халык күңелендә сакланып калганнары гына, булганнарның барысы да түгел. Халык бәйрәмнәре җирле халыкның менталитетын аңларга, аларның борынгы тарихи үзенчәлеген күзалларга да мөмкинлек бирә торган чыганак. Шуңа да, халык тормышын өйрәнүдә бу аспектларга аерым игътибар бирү кирәк. Тау ягы халкының үзенчәлекле бәйрәме – Майуны гына да бу төбәк тарихының борынгы тарихын өйрәнүдә аерым бурычлар куя ала, авыл халкының башка төбәкләр белән, башка мәдәният белән диалогы булуга мисал булуы, ихтимал.

*Аш-су традициясе.*

Татар халкында аш-суның төрлелеге, аның үзенчәлеге дә тарихи вакыйгалар, татарның үткәне белән бәйле. Беренче карашка, гади генә әйбер кебек тоелса да, аш-су традициясе буш урында барлыкка килми. Татар милли ашларының зур өлешен камыр азыклары алып торса, барлык төп азыкларның нигезендә ит белән бәрәңге булу, балык ризыклары, яшелчәләрнең бик аз кулланылуы – үзе үк татарларның игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнүнең ачык чагылышы. Татарда бәрәңгене икенче икмәк дип атау бар икән, ул да буш урында гына барлыкка килмәгән. Бу очракта Урта Иделдә яшәүче татарлар турында сүз бара. Башка төбәктә гомер итүче татарларда шул төбәкнең үзенчәлеге өстенлек ала. Кухняның беркүпмедер төрлеләнүенә халык-

---

[15] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 66.

[16] Шунда ук. – Б. 144.

ларның бер регионнан күчеп икенче регионда яши башлаулары, аралашулары тәэсир иткән. Шулай ук сәүдә итешү, тышкы мөнәсәбәтләр дә ашау-эчү традициясе формалашуга йогынты ясаганнар. Мисал өчен, татарларның чәй эчүләре чәй җитештерүче илләр белән сәүдәсен күрсәтә. Шул ук вакытта, җирле халык чәй урынына кура җиләге яфрагын һәм эт борынын [гөлҗимеш] төнәтеп эчкәннәр. Тау ягының бәлеше дөге, йөзем белән пешерелә икән, бу да аларның Урта Азия белән булган сәүдә мөнәсәбәтләренең нәтиҗәсе. Шулай ук борынгы вариант буларак тары, карабодай бәлешләре – җир кешесенең җитештергән продукциясеннән эшләнгән. Гомумән, тары татарда күп чәчелә торган бөртекле культура. Тары боткасы да, тарыдан ясалган якмыш [кыстыбый] та электән пешерелә торган ризыклар. Идел буе татарларында яшелчәлек әлләни зур үсеш алмаганлыктан, яшелчә белән эшләнә торган ризыклар чикле, шалканны, кабакны, чөгендерне парда пешереп ашаганнар. Алай да кабактан ризыклар ясау булган. Мисал өчен, Апас районының Олы Күккүз авылында кабак турап тары ярмасыннан бәлеш салганнар[17]. Кара Борнаш (Апас районы) авылында кабак бәлешенең төбенә камыр салынмаган, бары өстен генә камыр белән каплаганнар. Мондый ризык «җабык ындыр» дип аталган. Тау ягының үзенчәлекле камыр азыгы – ул кәлҗемә. Әдәби телдә бөккән дип атала торган әлеге ризыкның эчлеге төрле булырга мөмкин, әмма Күкшем авылында (Апас районы) аны кабак белән киндер орлыгы кушып пешергәннәр. Шулай ук киндер орлыгы камыр азыгында киң кулланылганы билгеле, аны изеп, бәлеш (пирог) эчлеге буларак та кулланганнар. Гомумән, ашау-эчү культурасы белән халыкның шөгыльләре турыдан-туры бәйләнгән. Татар халкында терлекчелек продуктлары белән булган ризыклар да бик күп. Тау ягында пешерелә торган сызык сумсасы дигән ризык та шуның мисалы була ала. Сызык – ул терлек маен эреткәннән соң калган масса, аны сумсаның эчлеге итеп кулланганнар. Мисал өчен, Колгына авылында сызык сумсасын, гадәттә иртәнге чәй ризыгы буларак ашаганнар. Тау ягының бәйрәмнәрдә сыйлана торган, туйларга алып бара торган камыр азыкларының берсе – җуача. Аны кайбер якларда чәк-чәк дип тә атыйлар, әмма ул үзенчәлекле, чәк-чәктән аермалы. Туң майда (терлекнең эретелгән эч мае) пешерелгән кечкенә шарчыклар рәвешендә ясалган камыр. Гадәттә, ул бал белән катырылмаган, әмма кайбер очракта шикәр эретеп баллы суда тотып эшләнгән вариантлары да очраштыргалый. Мичтә пешкән камыр ризыкларыннан, әлбәттә әпи, ягъни ипи, икмәк. Тау ягы халкы аны нәкъ менә «әпи» дип атый. Әпи куас белән эшләнгән, әпи пешерә башлаганчы камырдан «әпи башы» алып куялар, ул – икмәк ачыту өчен калдырыла торган камыр. Арыштан пешерелгән икмәкне «әчикмәк» дип атаганнар. Мич ягып икмәк пешерү зур эш, утын ягыннан расходлы эш тә, шуңа күрә бер салганда әпине күп итеп сала торган булганнар, кабартмалар да ясаганнар. Шул ук вакытта Шәшәрә

[17] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 180.

дигән ризык та пешереп алганнар. Ул – төче камырдан эшләнгән күмәч. Мич ягып әпи салу көне гаилә өчен бәйрәм кебек булган. Кечкенә ипи дә салганнар, аны «игәрче» дип атаганнар. Гадәттә, ул сәдака өчен пешерелгән. Мохтаҗларга биргәннәр, элек муллага сәдака буларак та шундый ипи бирелгән. Тау ягының визит карточкасы буларак, шул якта гына иң оста итеп пешерелә торган камыр ризыгы, әлбәттә, җука. Ул төче камырдан пешерелә торган яка гына итеп таба зурлыгында җәелгән җаймәләр. Бигрәк тә, Апас төбәге бу ризыгы белән хәзерге вакытка кадәр дан тота. Гомумән, Тәтеш өязенең үзенә хас ризыгы ул. Җука ул гадәти көнне дә ашала торган, туйга да алып барыла торган, мәет ашына савым итеп бирелә торган ризык. Чирмешән авылында (Апас районы) туйларга бик күп санда җука пешерелә торган булган, кунакларга тараткannар, туйга аны парлы санда алып барганнар, ә мәет ашына так санда булырга тиеш булган[18].

Хәзерге вакытта татар ашларыннан милли аш буларак токмач ашын атасак, элеккерәк чорда башкачарак булган. Татарлар кәбестәле ашны бер вакытта да ятратмаганнар, аны «урыс ашы» дип атый торган булганнар. Тау ягында сөтле, яисә катык каткан чумара ашын яратканнар. Чирмешән авылы кешеләре хәтере буенча «әпи камырыннан чумара ясап, борчак белән пешерәләр»[19], ягъни камыр борчак онынnan ясалган.

Солыны кесәл ясау өчен кулланганнар, солы белән күәс камырын пешереп кесәл ясаганнар. Эчемлекләрдән сыра дигәне дә булган. Күңел ачу бәйрәмнәрендә, туйларда кулланганнар. Сыра – ул өйдә ясалган эчемлек. Арыш онын әчетеп аны арыш саламы белән сыра чүлмәгенә тутырганнар, шуны мичкә куеп тотканнар, сезеп алганына чүпрә һәм колмак кушып эчемлек ясаганнар.

Тау ягы ашау-эчү гадәтләре, аларның ризык төрлеге – халыкның тарихи үткәнен күрсәтүче бер билге дә була ала. Аларда борынгы төркилек тә, башка халык гадәтләрнең, аралашу даирәсе тәэсире дә чагыла. Бу – гадәти генә бер күренеш түгел, бу гадәтләр үзенә күрә тарихи бер чыганак та була алалар. Аларның үзенчәлеге – төбәкнең үзенчәлеген дә чагылдырганны билгеләү кирәк.

Халыкның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, аның ашау-эчү традициясенең тарихи тамырлары һәрвакыт бик тирән була, алар формалашу өчен күп гасырлар кирәк, ягъни нәкъ шушы чыганаклар халык тарихын өйрәнүдә төп чыганакларның берсе булырга тиеш. Язма чыганаклардан аермалы буларак, бу чыганакларда субъективлык юк, алар вакыйгаларны ничек бар – шулай күрсәтә алу үзенчәлегенә ия. Тау ягы халкының яшәү тарихын бу ракурстан да карау халыкның үзенчәлеген күрсәтү, борынгы тарихын ачуда мөһим адым дип саныйбыз.

[18] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 175–176.

[19] Шунда ук. – Б. 180.

# IV бүлек

# XIX–XX ЙӨЗ БАШЫНДА ТӘТЕШ ӨЯЗЕНДӘ МӘГАРИФ

## § 1. *XIX–XX йөз башында өяз авылларында мәгариф торышы*

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктаганнан соң, Казан шәһәрендә яшәгән укымышлылар, хәллерәк кешеләр Казаннан читтәрәк, тынычрак җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Казанның зыялылары Казан арты авылларына күченә, шуңа да Казан артындагы күп кенә авылларда мәдрәсәләр ачыла. XIX–XX гасырлар аралыгында татар авылларында эшләгән шактый атаклы мәдрәсәләр билгеле. Мәдрәсә буш җирдә була алмый, аны оештыручы укымышлы кешесе, шәкертләрне ераклардан җәлеп итәрлек хөрмәткә лаек остаз һәм бу мәдрәсәләргә матди ярдәм күрсәтеп торырлык маллы кешеләр булырга тиеш. Мисал өчен, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан губернасында 30 мәдрәсә, 680 мәктәп эшләгән. Алар арасында танылганнары Казан шәһәренең 13 мәдрәсәсе арасыннан 5 мәдрәсәсе, Кышкар авылы мәдрәсәсе (ул 5 йорттта урнашкан була), Курса авылы, Чистай шәһәре мәдрәсәсе, Чистай өязенең Әлмәт, Кизләү авылы, Сары Күкшәй өязе Ура авылы, Мамадыш өязенең Сатыш, Кече Сөн, Саба авыллары мәдрәсәләре[1].

XIX–XX гасыр башында Тау ягында мәдрәсәләр күп булмый, әмма һәр мәчет каршында мәктәпләр эшләп килгән. Һәр авыл мәдрәсә тота алмаган. Мәдрәсә – ул урта яисә югары белем бирә торган дини уку йорты. Мәдрәсәләр, нигездә, шәһәрләрдә яки хәлле авылларда гына эшләгән. Чөнки мәдрәсә булу өчен уку йортының үз бинасы, белем бирә торган остазы булырга тиеш. Уку йортының педагогик составы, кабул ителгән уку программасы, уку тәртибе булу шарт. Мәчет каршында эшләгән мәхәллә мәктәпләре башлангыч белем биргән. Алар һәр авылда да булган, кайбер авылларда һәр мәхәлләнең мәчете каршында эшләп килгәннәр. Ир балаларны мулла, мөәззин, хәлфәләр мәктәптә укытса, кыз балаларны аларның остазбикәләре өйләрендә укыткан-

[1] ТР ДА, 92 ф., 2 тасв., 23954 эш., 106–107, 108–110 б. кгз.

нар[2]. Халык телендә дини уку йортларының барысын да мәдрәсә дип атау кабул ителгән. Шунлыктан, башлангыч уку йорты булган – мәхәллә мәктәпләрен дә татар телле чыганаклар мәдрәсә итеп күрсәтәләр, әмма аларны югары белем бирә торган мәдрәсәләр белән бутарга ярамый.

Тау ягында мәдрәсәләр күп булмаса да, булганнары шул төбәкнең белем үзәге булып торганнар, алар тирә-як авыл мәчет, мәктәпләре өчен маяк булып, шул як авыллары өчен муллалар тәрбияләгәннәр. Халыкны укытуда, тәрбияләүдә аларның роле зур[3]. Кайбер очракта мәдрәсә дәрәҗәсендә булмаган уку йортлары – мәктәпләр дә мәдрәсә башкарган кадәр укыту, тәрбия эшен алып барганнар. Мисал өчен, Тәтеш өязенә кергән хәзерге Апас районына карый торган Болын-Балыкчы авылы мәктәбе шул заманның атаклы уку йортларыннан саналган, анда гыйлем иясе Бикчәнтәй хәзрәт белем биргән. Бу мәктәптә киләчәктә танылган педагог, тарихчы булган Гайнетдин Әхмәрев Татар Наратлысы авылыннан (Яшел Үзән районы) килеп белем алган[4].

Тау ягындагы Сембер өязе Шәйморза дигән авылда яшәүче кари, Коръән хафиз Әбүбәкер хәзрәткә җәй айларында Коръән укырга өйрәнү өчен Россиянең төрле төбәкләреннән шәкертләр җыела торган булган. Җамал Вәлиди язуы буенча, ул бу авылда зур мәдрәсә тоткан[5], бу авыл әлеге төбәкнең рухи үзәге була.

XX гасыр башында Буа шәһәре мәдрәсәсенең ролен аерым билгеләп үтү кирәк. Бу мәдрәсәнең тарихы бик борынгыдан килә, ул 1805 елда ук шәһәрнең мөселман мәхәлләсе акчасына булдырыла. XIX гасыр ахыры – XX йөз башында имам-хатыйб, мөдәррис Нургали Хәсәнев дәресләр биргән. Бу мәдрәсә Буа сәүдәгәре Габдулла Шарин йортына урнашкан була[6]. Моннан кала, Буа өязенең шушы як төбәк авылларының рухи тормышына хезмәт иткән, халыкка белем биргән уку йортлары Буа районы авыллары Янтуганда ике мәдрәсә, Волный Станда 3 мәдрәсә, Ташкичү, Кырык Садак, Югары Лашчы, Норлат авылларында, Чүпрәле районының Чепкас-Илмәт, Үби (Үби-Начарово),

---

[2] Медресе Казанской губернии второй четверти XIX – начала XX вв.: сборник документов и материалов /отв. сост. Л. В. Горохова; сост.: Р. А. Гимазова, О. В. Федотова, Н. И. Шарангина; под общ. ред. Д. И. Ибрагимова. – Казань: Главное архивное управление при Кабинете Министров Республики Татарстан, 2012. – Б. 263–287.

[3] Салахова Э. К. Деятельность учебных заведений Горной стороны в дореволюционный период // Роль ислама в стабилизации социальных процессов. VI Международная научно-практическая конференция. – Наб. Челны, 2021. – С. 65–70.

[4] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Җыен, 2011. – С. 14.

[5] Медресе Казанской губернии второй четверти XIX – начала XX вв.: сборник документов и материалов /отв. сост. Л. В. Горохова; сост.: Р. А. Гимазова, О. В. Федотова, Н. И. Шарангина; под общ. ред. Д. И. Ибрагимова. – Казань: Главное архивное управление при Кабинете Министров Республики Татарстан, 2012. – Б. 285–286.

[6] ТР ДА, 92 ф., 1 тасв,. 19936 эш, 5 б.–6, 10 б.–6, 10 б.–11, 11 б.–17, 18 б.–19 кгз.

Ишмурзино-Суринск авылларында 50–80 шәкере булган мәдрәсәләр эшләп килгән[7]. Сакланып калган архив документлары нигезендә бу мәдрәсәләрнең тарихы XIX гасырның беренче яртысыннан билгеле дип белдереп була, әмма кайберләренең тарихы күпкә борынгырак та булуы ихтимал.

XIX гасырның 70 елларында ачылган Чуел өязе Акъегет авылы Яшел Үзән районы) мәдрәсәсе Тау ягының мәгариф үзәгенә әйләнә[8]. Себер ягында сату итеп мал туплаган бертуган Шәфигуллиннар һәм Архангельск шәһәрендә сәүдә иткән Акъегет авылы кешесе Закир Ишмәмәтев акчасына булдырыла һәм алар ярдәме белән яши[9]. 300 шәкерткә белем биргән зур мәгариф учагы бу төбәкнең белем һәм мәдәни үзәге булып кына калмыйча, XX йөз башында барган үзгәрешләрдә яңа фикер туу урыны булып та җитешә. Акъегет мәдрәсәсе, ул мәдрәсәне тотучы Заһидулла Шәфигуллин тирә-як авыллары тормышына да зур тәэсир ясый. Заһидулла Шәфигуллин акчасына мәчетләр салына, мәчетләр каршында мәктәпләр ачыла.

XX йөз башында Тау ягының башка кайбер авылларында атаклы уку йортлары эшли. Бу вакытта, 1913 елгы документ хәбәр итүе буенча, Акъегет авылы мәдрәсәсендә шәкертләр саны кимүен дә бу төбәктә башка мәдрәсәләр ачылу белән аңлаталар. 1913 елның сентябрь аенда Чүти авылында мәдрәсә эшли башлый, бу авылның мәчетен салуга да, мәдрәсәсен ачуга да Заһидулла Шәфигуллин зур ярдәм күрсәтә. Бу авылда мәдрәсә ачылганга кадәр мәчет каршында мәктәп эшләп килә торган була инде. Тәтеш өязе Чирмешән авылы (Апас районы) мәктәбе XX гасырның башыннан ук эшләп килгән, ул Садыйк Сабитов акчасына булдырыла. 1908 елда хәзерге Буа районына карый торган Норлат авылы мәдрәсәсе ачыла, ул тирә-якта танылган уку йортына әверелә[10], әмма кайбер чыганакларда бу уку йорты 1840 елда ачылган дип күрсәтелә[11]. Безнең фикеребезчә, ул алдан мәктәп булып, XX йөз башында мәдрәсә югарылыгына күтәрелгән булырга тиеш. Тәтеш өязе Яңа Чәчкап авылы (Буа районы) мәдрәсәсе бик зур булмаса да, шәкертләр үз иткән атаклы уку йорты була[12]. Кызганычка каршы, бу уку йортлары эшчәнлеге белән бәйле материаллар безнең көннәргә кадәр сакланып калмаган. Без алар хакында бары тик тикшерүче органнарның документациясе, яисә халык хәтерендә калган истәлекләр аша гына күзаллый алабыз.

Мәдрәсәләрнең тулысынча халык, мәхәллә әһелләре сәдака акчасына яшәвен исәпкә алсак, аларны тоту җиңел булмый. Халыкның матди хәле

---

[7] ТР ДА, 92 ф., 1 тасв., 19936 эш., 5 б.–6, 10 б.–6, 10 б.–11, 11 б.–17, 18 б.–19 кгз.

[8] Сәлахова Э.К. Бертуган Шәфигуллиннар һәм татар мәгарифе // Фәнни Татарстан. – 2018. – № 2. – С. 127–133.

[9] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 6183 эш., 6–8 б. кгз.

[10] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1576 эш., 270–272. кгз.

[11] ТР ДА, 92 ф., 1 тасв., 19936 эш., 5 б.–6, 10 б.–6, 10 б.–11, 11 б.–17, 18 б.–19 кгз.

[12] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. – Казан: Татарстан китап нәш-ты, 1994. – 463 б.

уңыш уңу-уңмауга да, төрле афәтләргә дә бәйле булган. Мәхәлләгә ярдәм итәрлек хәлле иганәчеләр, хәйриячеләре булган мәхәлләләр, мәдрәсәләр булган әлбәттә, әмма мондый кешеләр бөтен авылга да җитмәгән. Мисал өчен, XX йөз башында Тәтеш өязе Әлки авылы халкының мәдрәсә тотарлык хәле беткәч, авыл халкына ярдәм итәргә килгән Кызыл Хаҗ җәмгыятеннән бер рус ханымы бу хәлне күреп, мәдрәсәне төзекләндерүгә ярдәм итә. Шулай итеп, балалар яңадан мәдрәсәгә йөрү мөмкинлеге ачыла[13].

XX гасыр башына караган мәгълүматлар буенча, Тәтеш өязендә 112 мәктәп эшләгән, шуларның бары берсе генә дәүләт органнары тарафыннан рөхсәт ителгән булган[14], гадәттә мондый уку йортларын теркәү, тиешле документлар нигезендә ачу мөмкин дә булмый. Бу сан астында зур, билгеле мәктәпләр исәпкә алынган, моннан кала, һәрбер мәчет каршында үзенең кечерәк мәктәпләре эшләп килгән. 1913 елгы караган мәгълүмат буенча, Тәтеш өязендә 132 кадими мәктәп саналган, Тәтеш өязе уку йортлары саны ягыннан бары тик Казан (201 уку йорты), Мамадыш (171 уку йорты) өязеннән генә калышкан. 132 мәктәптә 7827 ир бала, 5456 кыз бала белем алган. Белем бирүдә 132 мулла, 131 остазбикә көч куйган[15]. Әлбәттә, бу уку йортларының зур күпчелеге кадими уку йортлары була, 1910 елгы мәгълүматта Тәтеш өязендәге 1 уку йорты җәдиди метод белән эшләгәне күрсәтелә[16].

XX йөз башында Тәтеш өязе мәктәпләрендә укыткан муллалар, хәлфәләр үз заманы өчен яхшы белем алган, атаклы мәдрәсәләрне тәмамлаган кешеләр була. Мисал өчен, Идрәс Тенки (Апас районы) авылы имамнары, укытучылары Әхмәтҗан Габделгаффаров, Олы Кариле (Кама Тамагы районы) авылының Шаһиәхмәд Нурмөхәммәтев, Атабай (Кама Тамагы районы) авылының Шаһимөхәммәд Госманов Казан шәһәрендә Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаганнар. Келәнче (Кама Тамагы районы) авылының Шиһабетдин Мифтахетдинев Буа шәһәре мәдрәсәсе шәкерте булган, Олы Тормы (Тәтеш районы) авылының Зыяэтдин Шарафетдинев Казан шәһәрендә атаклы Апанай мәдрәсәсен тәмамлаган. Атабай авылы мулласы, хәлфәсе Шаһимөхәммәд Госманов яңа уку методы белән эшләнгән җәдиди уку дәреслекләре авторы булу белән билгеле. Ул яңа система буенча укыту, яшьләрне тәрбия кылу буенча нәсихәтләр эшләгән имам. Аның китаплары атаклы сәүдәгәр Әхмәт Хөсәенев акчасына басылган һәм яңа метод белән укырга теләүчеләргә бушлай таратыла торган булган[17]. Шушы муллалар, мөгалимнәр Тәтеш өязендә ысулы саутия белән белем һәм тәрбия бирүче уку йортлары тотканнар. Аларның шәкертләре алга

[13] Бикмиев Әхмәдҗан. Авылда мәктәпләр // Казан мөхбире. – 1906. – 11 сентябрь.
[14] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 3932 эш, 106 кгз.
[15] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 103–104 кгз.
[16] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 5482 эш, 115 кгз.
[17] ТР ДА, 1 ф., 6 тасв., 99 эш, 29–34 б кгз.

таба үзләре дә укытуны дәвам иткәннәр. Андый үзәкләр татарлар гомер иткән бик күп төбәкләрдә була[18].

Тәтеш өязе авылларында эшләгән барлык дини уку йортлары да шул типтагы башка уку йортларыннан берни белән дә аерылмаган. 1906 елда Тәтеш өязләре мәктәпләрен тикшерү отчетында мәдрәсә һәм мәктәпләр, гадәттә, җәмәгать яки хосусый йортларда урнашкан булуы хакында языла. Анда: «Уку йортлары чиста һәм якты. Муллалар укыткан өчен хезмәт хакы алмыйлар, бары тик шәкертләр, аларның аталары биргән хәер акчасы белән генә канәгатьләнәләр. Кызларны муллаларның хатыннары үз өйләрендә, шулай ук хәер акчасы хисабына укыталар. Барлык мәдрәсә, мәктәп тә җәмәгатьчелек һәм мәхәллә халкы хисабына яши»[19], диелә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә укулар авыл җирендә эшләр тәмамланып беткәч кенә, көз соңында гына башланган, укулар кар эри башлау белән үк тәмамланган да. Тикшерүчеләр мәдрәсә-мәктәптәге үрнәк дисциплинага, муллаларның укыту эшенә чын күңелләре белән бирелгәнлекләренә аерым да игътибар иткәннәр.

Уку дәреслекләренә килгәндә, татар теленнән шул заман мәктәпләрендә иң популяр булган дәреслек Әхмәдһади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл»е, «Әдәпле бала», «Насыйхәт», язудан «Хөснел хат», шәригать белеменнән: Коръән, Һәфтияк һ.б укытылган[20].

Мәгълүм булганча 1870 елның 26 мартында «О мерах к образованию населяющих Россию инородцев» дип исемләнгән Кагыйдә буенча рус булмаган халыкларның мәгарифенә дәүләт тарафыннан яңалык өстәлә. Шәһәр һәм күпләп татарлар яшәгән авылларда дәүләт хисабына башлангыч уку йортлары ачу күздә тотыла. Шул чор халык мәгарифе министры Д. А. Толстой сүзләренә караганда «конечной целью образования всех инородцев, живущих в пределах отечества, беспорно, должно быть обрусение их и смешение с русским народом»[21] дигән максат куела. Кабул ителгән тәртипләр буенча, рус теле укытучысы хөкүмәттән хезмәт хакы алган, әмма татарларга бу уку йортында, теләгән очракта, дин дәресләре укытырга рөхсәт ителгән, әмма инде ул хезмәт мәхәллә халкының үз өстеннән түләнергә тиеш булган. Ә мәхәллә мәктәпләренең эшләү шарты булып, аларда рус сыйныфы булу таләбе куелган.

Хәлләре болай да җиңел булмаган мәхәллә мәктәпләренә бу чыгымнар да өстәлә, моннан кала рус теле укытуны руслаштыруның, иманны алуның бер куркынычы итеп тә күрәләр. Шуңа да рус теле укытучысына җиңел булмый,

[18] Модернизационные процессы в татарско-мусульманском сообществе в 1880–1905 гг.: документы и материалы. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. – С. 394–395.

[19] ТР ДА, 97 ф., 1 тасв., 123 эш, 2, 15–16 кгз.

[20] Шунда ук.

[21] Список постановлений по Министерству народного просвещения. Том. 4. – СПб.: Типография Императорской академии наук, 1871. – С. 1555–1566.

мәхәллә халкы аны гел кимсетергә генә торган, дошман күргән. Хөкүмәт документларында рус теле укытылмаган мөселман дини уку йортларының сыйфат дәрәҗәсе «түбән» дип күрсәтелә. Тәтеш өязе уку йортларын 1905 елгы тикшерү отчетларында «мөселман уку йортларында уку-тәрбия эшенең куелышы һәряктан караганда да берьяклы итеп кенә оештырылган. Мөселманнарның фикеренчә, уку бары үз диннәренең тәртипләрен һәм гадәтләрен өйрәнү генә максат итеп куела. Алар бары тик укуда дини якны гына карыйлар, ә башка предметларны уку икенчел итеп куела, аларга тиешле игътибар бирелми. Максатны шулай тар аңлаулары аркасында авылларында рус теле дә укытыла торган уку йортлары ачуга бик авырлык белән генә ризалашалар»[22], диелә. Булганнарында да рус сыйныфларындагы шәкертләрнең русча белүләре бик чамалы дип күрсәтелә. Әмма монда, гомумән, уку йортының белем бирү дәрәҗәләре түбән булган дигән ялгыш караш формалашырга тиеш түгел. Татар авылларының һәрберсендә, хәтта һәрбер мәхәлләсендә, мәктәпләр булган. Авылның һәрбер кешесенә белем алырга мөмкинлек бирелгән, ул укырга-язарга өйрәнгән, ә җәдиди уку йортлары ачыла башлагач дөньяви фәннәрдән дә белем алганнар[23].

1912 елга караган статистик мәгълүмат буенча, Тәтеш өязе мәктәп-мәдрәсәләрендә 12061 кеше белем алган, шуларның, әлбәттә, зур күпчелеге ир балалар – 8418 кеше, кызлар – 3643 кеше. Тәтеш өязе бу саннар буенча бары Казан һәм Мамадыш өязеннән генә калышкан. Чагыштыру өчен бу вакытта Тәтеш өязендә 122770 кеше гомер иткәнен дә күрсәтеп китәргә кирәктер. 1912 елда Тәтеш өязендә 135 мөселман мәхәлләсе булган, шуларның 132 сендә җәмигъ мәчет, 3 се биш вакыт намаз укый торган мәчет була. Мөселман халкына 279 дин әһеле: 141 хатыйб, 47 имам, 91 мөәззин хезмәт күрсәткән, өяздә 246 мөселман уку йорты эшләгән[24]. Саннарга караганда хәтта һәр мәхәлләдә уку йорты булган дип кенә дә әйтү аз була, кайбер мәхәлләләрдә берничә мәктәп эшләгәне ачыклана. Саннар үзләре үк мөселман халкының белем дәрәҗәсе хакында сөйли, ягъни мәхәлләнең һәр кешесенә белем алу өчен тулы мөмкинлек була. Бу мәктәпләрнең зур күпчелеген кадими мәктәпләр тәшкил иткән, кадими мәктәпләрнең үз заманы өчен зур ролен, халыкны укырга-язарга өйрәтүдәге хезмәтен танырга кирәк.

Кызганычка каршы, авылларда эшләп килгән, халык акчасына ачылып, халык арасында популярлык казанган мәдрәсәләр турында мәгълүматыбыз аз, чөнки алар хакында рәсми документларда материаллар юк, ә бары тик халык хәтере генә алар турында истәлекләр саклап килгән, әмма инде алар да вакыт үтә-үтә онытыла, халык хәтереннән җуела бара. Сакланып калган

---

[22] ТР ДА, 97 ф., 1 тасв., 123 эш, 2, 15–16 кгз.

[23] Шунда ук.

[24] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1577 эш, 231, 235 б–236, 238, 240, 242, 244, 246, 248, 250, 252 кгз.

кулъязмалар аларның кайберләре турында безгә ачыклык кертә ала. Кулъязма китапларны, нигездә, мәдрәсә шәкертләре күчереп язганны исәпкә алсак, язучының исеме, аның кайсы мәдрәсәдә күчерелүе кулъязмаларда еш кына теркәлә[25]. Яңа Чәчкап, Түбән Наратбаш авылы хәзерге Буа районына карый торган авыллар. Түбән Наратбаш Буа шәһәренә бик якын урнашкан авыл, ә Буа шәһәре мәдрәсәсенең көчле уку йорты икәнен беләбез, шәкерт Буаны узып, Яңа Чәчкап авылына укырга килгән икән, бу инде Яңа Чәчкап авылы уку йортының югары дәрәҗәдә булуы хакында сөйли.

Авыл мәдрәсәләренең тормышы җиңел булмаган, аларның хөкүмәттән бер тиен дә алмыйча, халык, мәхәллә акчасына көн күргәнен исәпкә алсак, бу уку йортлары тиңдәшсез уку йортлары булуга тагын бер кат инанабыз. Мәктәп-мәдрәсәләрне яшәтүдә, аларны тотуда аерым кешеләрнең ярдәме аеруча игътибарга лаек, бай ярдәмчеләре булган уку йортларының хәле бер төрле булса, андый ярдәмчеләре булмаган очракта бөртекләп җыелган ярдәм мисаллары татар халкының мәгарифкә хөрмәтле мөнәсәбәтен күрсәтә. Шундый бер мисалны Тәтеш өязенә кергән Черкен авылыннан (Буа районы) күрсәтергә кирәк. Имам Габделхәким мәдрәсәсендә балалар түзә алмаслык хәлдә салкын була, имам ягарга утын юклыгына зарланып халыкка мөрәҗәгать иткәч, шушы авылдан чыккан Мариуполь заводында эшләүче Гайнетдин Таҗетдинев иптәшләре арасында 16 сум акча җыеп җибәрә. Бер эшченең бу эшкә шулкадәр тырышлыгы аркасында күпме баланың белем алуга мөмкинлеге туына газета аша рәхмәт белдерәләр[26].

XX йөз башында шәһәрләрдә татар балаларына рус теле буенча да белем бирә торган уку йортлары шактый булган[27], ә татар авыллары бу мәсьәләгә шактый сак килгәннәр, традицион карашлы авыл халкы бу яңалыкны кабул итәргә ашкынып тормаган, моннан кала чукындыру сәясәтенең аяныч нәтиҗәләре хәтердә тирән яра эзе калдырганны берсе дә онытмаган. 1871 елда ук Казан губернасы халык мәктәпләре инспекторы В. В. Радлов Казан уку округы попечителе П. Д. Шестаковка бу проблеманың кискен торуына, мәктәпләрне ачу авыр булуына, укытырга кеше юклыкка зарлана[28]. Бу проблема татар җәмәгатьчелеге арасында да бәхәс ителә: «Йолдыз» газетасында «авылларга школа кирәкме?» дигән сорауга фикерләшү бара. Андый мәктәпләр ачыла, әмма алар һәрвакытта да халык каршылыгына да, имам нәфрәтенә дә очрый. Еш кына авыл имамы белән мәктәпнең рус теле укытучысы арасында зур конфликт булуы, имамның балалары рус классларында укучыларны кагуы хакында хәбәрләр күп ишетелә. Заман таләпләре буенча, мондый уку

---

[25] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Казан: Татарстан китап нәш-ты, 1994. – Б. 100.

[26] Тәшәккер // Йолдыз. – 1912. – 17 гыйнвар.

[27] 1870 елның 26 марты «О мерах к образованию населяющих Россию инородцев» Кагыйдәсе нигезендә ачылган уку йортлары турында сүз бара.

[28] ТР ДА, 92 ф., 1 тасв., 10464 эш, 4–7 б. кгз.

йортлары да үз урынын табарга тиеш була, чөнки Россиядә көн күрү, үзенең даирәсен киңәйтү өчен рус теленә ихтыяҗ туа. Моның кирәклеген раслап «Урысча белгән балаларның һәммәсе бер эшкә керә ... белмәгән балалар гади авыл кешесе булып кына калалар»[29], дип яза мәкалә авторы. Бары тик 8 яшьтән 12 яшькә кадәр генә русча уку булачак та, мөселман баласы белемсез кала дигән ялгыш фикер дә таралып өлгергән була авыл халкы арасында. Автор газета аша, моның алай түгеллеген, 1908 елгы программа буенча 2 сәгать рус теленә бирелсә, 3 сәгате дин сабагына калдырылачак, ә моннан кала татарча язу, сызу, хисап гыйлеме булачагын искәртә. Рус теле укытыла торган мәктәпләр ачу форсатын кулдан ычкындыру дөрес булмас иде, ди. Авторның бу сүзләре белән килешми мөмкин түгел, чөнки беренчедән халык хисабына мәктәпләр тоту бер яктан бик күркәм хәл булса да, икенче яктан халык өчен матди яктан җиңел түгел, ә бу хөкүмәт мәктәпләре аша дин сабагы өйрәнү дә, дөньяви белем алу мөмкинлеге дә булачак. Моннан кала, капитализм мөнәсәбәтләре ныклап урнашкан вакытта татар кешесенең үз яшәешенең матди нигезен ныгытуга да ярдәм булачак. XX гасыр башында Казан өязендә 130 рус-татар мәктәбе (русско-татарская школа) эшләгән[30]. Мондый мәктәпләр Тәтеш өязе авылларында да булган. Мисал өчен, Тәтеш өязе Ындырчы авылында (Апас районы) рус-татар мәктәбе 1881 елда ук ачыла, укулар крестьян Фәтхуллин өендә алып барылган. Бина кечкенә булу сәбәпле, бер вакытта 12 баладан да артык кеше сыймаган. Шунлыктан, укытучы балаларны өч сменада кабул итергә мәҗбүр булган. Аннан бу мәктәп хуҗасы Громыкин булган элеккеге почта станциясенең бинасын сатып ала. 1884 елда Халык мәгарифе министрлыгы бина алу һәм аны ремонтлау өчен 500 сум акча бүлеп бирә[31]. Болын-Балыкчы авылында (Апас районы) 1911 елны ачылган шундый мәктәп бер ел гына эшләп ала да, рус теле укытучысы юклыктан эшен туктата, хәтта авыл мулласы Каюм Бикчәнтәев газета аша үз авылына рус теле укытучысы булырлык кеше эзли[32].

1870 елның 26 мартында «О мерах к образованию населяющих Россию инородцев» Кагыйдәсе нигезендә иң беренчеләрдән булып ачылган рус-татар мәктәбе Апас районына карый торган Чирмешән авылында эшли башлый. Ул 1878 елның 16 февралендә үк Уфа татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Мөхәммәдсафа Биккенин тырышлыгы белән ачыла, ул аның беренче укытучысы була. Ачылган елны ук мәктәпкә 35 бала кабул ителә. Бу мәктәпкә 1894 елның 1 сентябрендә укытучы буларак Зәңгәр мәчет, «Касыймия»[33] мәдрәсә-

[29] Авылларга школа кирәкме? // Йолдыз. – 1912. – 15 гыйнвар.
[30] Шунда ук.
[31] РДТА, 733 ф., 171 тасв., 878 эш, 1–4 кгз.
[32] Идарәдән мәктүпләр // Йолдыз. – 1912. – 31 гыйнвар.
[33] Кайбер мәгълүматлар буенча «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте.

ләре, Казан татар укытучылар мәктәбендә (КТУШ)[34] белем алган Габдрахман Рафиков билгеләнә. Авыл халыкы аны бик сагаеп каршы алган булса да, мөгаллим үзенең белеме, тәрбиясе белән бик тиз арада авыл халкының абруен казана[35]. Ул эшләгән елларда уку йорты тирә-якка танылып өлгерә.

Тау ягы, аерым алганда, Тәтеш өязе мәгарифе үсешендә атаклы мөгаллим Мөхәммәдкасыйм Габделгалләм улы Салихов (1871–1954)[36] роле аеруча зур. Аның шәкертләре арасында бу төбәктән чыккан егетләр бик күп була. Мәгълүм булган 166 шәкерте арасында Тәтеш өязе Күккүз авылында (Тәтеш районы) имам булып торган Габделбарый хәлфә Нәбиулла хаҗи хәзрәт улы, Нотфулла хаҗи Габидулла хәзрәт улы, Шәйморза авылы (Буа районы) имамы булган Мөхәммәд карый дамелла Әбүбәкер карый хәзрәт улы, Фәйзеррахман карый, Тәтеш өязе Наратбаш авылының (Буа районы) Габдрахман хәзрәт, Яңа Сала авылыннан Нәҗип Вәлиев, Нәҗип мулла Зариф улы, Каратай авылыннан Касыйм хәзрәт, Тәүгелде авылыннан (Апас районы) Хәбибулла Шәфиулла хәзрәт улы, укытучы Шәфигулла, Кече Бакырчыдан (Апас районы) Габделкәрим, Зәки хәзрәтләр, Урта Балтайдан (Апас районы) Шакир Минһаҗетдин хәзрәт улы, Дәүеш авылыннан (Апас районы) Хөҗҗәтелислам Габделхәлим улы, Фәхреислам Габделхәким улы, Мөхәммәдгали Хәким улы Сөләйманов, Ябалак авылыннан (Апас районы) Габдулла Харис улы, Буа районына карый торган Аксу авылыннан Кәрим хәзрәт, Апас районының Кошман авылыннан Борһан Хәйреддин улы, Сатмыш авылыннан Габделмәлик Исмәгыйль улы, Танай авылыннан Хасибан Зәйнулла улы Гайнуллин. Бу исемлекне 1975 елда Мөхәммәдкасыйм хәзрәтнең улы Габбас хәзрәт төзи. Шулай итеп, бу атаклы хәзрәттә укыган күренекле шәхесләр арасында Тау ягы кешеләре, татар тарихында үз урынын тапкан хәзрәтләр дә, укытучылар да бар[37].

XX гасыр башында, бигрәк тә, инкыйлабка якынлашкан елларда, татар мәктәп-мәдрәсәләренә дә инкыйлаби фикерләр, гадәти халәттән риза булмаулар артканнан-арта бара. Казан шәһәрендә шәкертләр хәрәкәте барган вакытта, авыл мәктәп-мәдрәсәсе шәкертләре дә дөнья вакыйгаларыннан бихәбәр булып ята алмыйлар. Шәкертләр хәрәкәтенең кайтавазы булуын Апас районына карый торган Чирмешән авылында булган хәл белән дә бәйләп күрсәтеп була. Бу авылда булган хәлләр мәгариф мәсьәләре белән генә чикләнеп калмыйча, сәяси бунт дәрәҗәсенә күтәрелә. 1903 елга кадәр Чирмешән авылында дәүләт карамагындагы бер мәктәп эшләп килгән, анда, әлбәттә,

---

[34] Рус-татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү максаты белән 1876 елда ачылган уку йорты.

[35] Муртазина Л. Династия Рафиковых. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – С. 4–5.

[36] Салихов Мөхәммәдкасыйм Габделгалләм улы (1871–1954) – дин эшлеклесе, Апанай мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлаган, 1899 елдан башлап шул ук мәчеттә имам-хатыйб вазыйфасын башкарган. 1918 елга кадәр «Касыймия» мәдрәсәсендә мөдәррис булган.

[37] Җәбәлстан. Ачык сырт/ төз. Абзалина Р. – Казан, 2021. – Б.102–106.

мәҗбүри рәвештә рус теле укытылган[38]. Шушы мәктәптә 130 шәкерт белем алган. 1912 елда Икенче Чирмешәндә Минһаҗетдин Хөснетдин улы үз акчасына татар мәктәбе төзетә, мәктәп ачылу белән дәүләт карамагында булган мәктәптән барлык укучы да диярлек шунда күчеп бетә, бары 5 укучы кала. Яңа ачылган мәктәпкә заманча фикерләүче, Казанда Галиев («Мөхәммәдия») мәдрәсәсен тәмамлаган, элекке укытучының адашы Габдрахман Шиһабетдинев билгеләнә. Ул авылның икенче мәхәллә имамы да булып торган. Мәктәптә дин гыйлемен Фатых Шәмсетдинев укыта. Әлбәттә анның мәктәбе популяр булуга, шәкертләрнең бөтенесе диярлек шунда күчүгә дәүләт карамагындагы мәктәп укытучылары Мөхәммәдсафа Биккенин һәм Мөхәммәдсабир Гаффаров тыныч кына карый алмыйлар. Алар бу мәктәпне рөхсәтсез эшләүдә гаепләп, халык мәктәпләре инспекторын чакыралар, инспектор Алатырцев белән бергәләп килеп карыйлар, аннан инспектор киткәч татар мәктәбенең өч шәкерте аларның уку йортына килеп патшанын сурәтен алып ташлаганнар, дип гаеп тагалар. Бу хәлдә шушы авыл крестьян балалары – 16 яшьлек яшьүсмерләр: Шәһәретдин Минһаҗетдинев, Сабир Вәлиев, Салаватулла Гафуровлар гаепләнә, ә егетләр исә бу нахак гаепне танымыйлар. Вакыйга мулла Габдрахман Шиһабетдиневне «сәяси ышанычсыз» итеп табу һәм аны 3 елга Тула губернасына сөргенгә сөрү белән тәмамлана. Авыл халкы бу трагик хәлгә җавап итеп Габдрахман муллага багышлап бәет яза. Бу бәет «Татар халык авыз иҗаты. Бәетләр» томына да кертелгән[39].

Тумышы белән хәзерге Буа районы Тәүгелде авылы (элекке исеме – Яңа Күлкәш) кешесе Габдрахман Шиһабетдинев заманча тәрбияләнгән, укымышлы, белемле кеше булган. Аның тормыш иптәше шул ук өязнең Әлки авылы (Буа районы) атаклы имамы Баһаветдинев кызы – Бибираимә Баһаветдинова. Мулланың анасы – Бибилатыйфа Сираҗетдинева бик көчле рухлы ханым, 60 яшендә булуына карамастан, үз улыннан гаепне алдыртуга ирешә. Мулла үзенең хокуклары чикләнмәгән статуста туган төбәгенә кайта[40]. Бу вакыйгалар бер яктан мәгариф эшендәге каршылыклар – укыту системасына булган төрле караш һәм төрле ысул көрәше итеп күренсә дә, чынлыкта исә, җәмгыятьнең үзгәрүе, килеп туган ситуациягә анализ аша карый башлавы күренә. Шул ук вакытта татар җәмгыятенең каршылыкларында бер-берсенә булган көнчелек һәм шуның белән бергә матди ихтыяҗлар ятканын да ачык күрергә була. Әмма, ничек кенә булмасын, татар җәмгыятендә барган үзгәрешләр, аерым

---

[38] Бу мәктәпнең элекке укытучысы Габдрахман Рафиков авыл халкының рус теленә булган каршылыгын җиңеп, үз шәхесе аша халыкта бу уку йортына уңай караш булдыруга ирешә. Г. Рафиков 1896 елның 21 ноябреннән эшчәнлеген Казан шәһәрендә дәвам иткән.

[39] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. – Казан: Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011. – Б. 22.

[40] ТР ДА, 1 ф., 4 тасв., 886 эш, 2–93 кгз.

алганда мәгарифендәге алгарышлар үзәктән шактый ерак урнашкан гап-гади татар авылларында да барганлыгының ачык мисалы.

1917 елгы инкыйлаб чоры татар мәгарифенә дә үзгәрешләр алып килә. Өяз мөселманнары арасында заманча белем алуга омтылыш бермә-бер күтәрелеп китә, чөнки халык җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне күрә, вакыйгалар агышында югалып калмас өчен белем кирәклеге инде бәхәссез була. Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре мөдире Исхак Казаков өяздәге хәлләрне, белем дәрәҗәсен ачыклау өчен авылларга Шиһап Шәрәф, Җәләл Таһиров, Шаһит Гаделшин, Мозаффар Мөштәриев, Сабир Салихов һәм Абдуллиннар җибәрә. Алар авыл мәктәпләре буйлап йөреп, мәгълүмат җыеп, «Мәктәпләр шурасы»на доклад бирергә тиеш булалар[41]. Нәтиҗәдә авылларга ким дигәндә 262 мөгаллим җитмәгәнлеге ачыклана. «Тәтеш оешмасы» газетасында «Бәгъре Янган» дигән псевдоним астында бер автор «Бу нинди гаҗәп эш! Урыс кулына кергәннән бирле бер уянмый йоклаган бөтен Тәтеш өязе мөселманнары бүген уянганнар. Бүген үзләренең дөньяда яшәргә омтылуларын күрсәтәләр, бүген үзләренең өстенә капланган кара пәрдәләрне ертып, ак, пакъ дөньяга чыгарга ашкыналар. Өяздә укытырга теләп, Мәктәпләр шурасына 250 мөгаллим вә мөгаллимә укытырга урын сорыйлар!»[42] Хәтта чит җирләрдә укытып йөргән Тәтеш төбәге мөгаллимнәренең үз җирләренә кайтып эшлисе килүләре, кайберләре эш хакының күпме булуына да карамастан, бүгеннән күчеп кайтырга риза булучы мөгаллимнәр булуы ачыклана. «Мәктәпләр шурасына» бер остазбикә түбәндәге эчтәлекле хат юллый: «Сезне һәр җирдә мәктәп ачасыз, дип ишеттем. Безнең авылымызны кызлар мәктәбе ачудан мәхрүм итеп калдырмасаңызла. Мин үзем картайдым, укыта да алмыйм, күзем дә күрми. Безнең авылга кызлар мәктәбе ачсаңыз, Аллаһ ризалыгы өчен, мин дә картымнан калган йортымның яртысын кызлар мәктәбе өчен бушлай биреп торыр идем. Зинһар, кызларымызны укытудан мәхрүм итмәсеңезлә»[43], дип яза. Кызганыч, чыганактан кайсы авыл турында сүз баруы ачыкланмый, әмма бу мисал өяздәге кызларга белем бирүгә теләкнең нинди көчле булуын күрсәтүче факт. «Бәгъре Янган» псевдонимы астындагы автор бу остазбикәне «Бу нинди изге карчык! Бу – Аллаһның җиргә төшкән бер фәрештәсе!»[44] дип зурлый. «Бу гаризаны укыгач, шатлыгымнан ике күземә мөлдерәп яшьләр килде. Бөтен вөҗүдем шатлык берлән, өяземезнең алга атлавына ышанган бер рәхәт берлә тулды. Шул кузгалган авылларны бер күз белән барысын күрәсем килә башлады. Күңелем аның каршысына барып кулларын үбеп рәхмәт укырга әзерләнә башлады»[45].

---

[41] [Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре] // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 26 сентябрь.
[42] «Бәгъре Янган». Өяздә укытуга сусау// Тәтеш оешмасы. – 1917. – 10 октябрь.
[43] Шунда ук.
[44] Шунда ук.
[45] Шунда ук.

1917 нче елның 27 сентябрендә Тәтеш өязе мөселман укытучыларының өченче гомуми җыелышы була. Җыелыш Гариф Халиди рәислегендә эшли, Президиумга Исхак Казаков, Кариб Вәли, Шәһит Гаделшин, Кадыйр Халидовлар сайлана. Җыелышта көн тәртибенә мөһим сораулар чыга: шуларның берсе – муллаларны рәсми мөгаллим итеп тану дөресме, юкмы? Бу мәсьәлә аерым секция утырышында каралып, 4 маддәле резолюция кабул ителә: «1) рәсми укытучы булып, мөгаллим-мөгаллимәләрдән башка кешеләрнең укытуга катнашырга һич хаклары юк; 2) әүвәлдән яңа тәртип белән укыткан бер мулла, моннан соң да рәсми мөгаллим булып калырга теләсә, ул мулла үзенең муллалык лөзүмен ташларга тиешле; 3) әгәр бер мулла моңар кадәр кимчелексез яңа тәртип белән укытып килгән булса, рәсми рәвештә ачылачак мәктәпләргә аңлы укытучылар җитешкәнчегә кадәр, аңар шул авылда мөгаллимлек итеп торырга имкян [мөмкинлек] бирелер; 4) һәр мулла, үз мәхәлләсендәге рәсми мәктәпкә дин мөгаллиме сыйфаты белән керергә хаклы булып, земство тарафыннан үзенә билгеләнгән вазифәсен [хезмәт хакын] алыр, укытучы вазифәсенә катнашмас...»[46].

1918 елның 25 нче июнендә Мозаффар Мөштәриев рәислегендә Тәтеш өязе укытучыларның съезды үтә. Рәис урынбасары итеп Кариб Вәли, сәркәтиплеккә Фәйрүзә Маликова, аның урынбасары итеп Маһруй Мозаффария сайланалар. Җыелышның карарлары: «1) Тәтеш өязе укытучыларының оешмасын тәшкил кылырга, идарә әгъзалары сайланып, устав төзүне идарәгә тапшырырга; 2) Тәтеш укытучыларына Казандагы «Мәркәз бюро»га кушылырга; 3) әгъзалык бәдәле [хакы] өчәр сум алынып, шуннан 50 шәр тиен «Мәркәз бюро»га бирелергә; 4) укытучылардан Мәктәп шурасына сайланган әгъзалар: Мозаффар әфәнде Мөштәриев, Кариб әфәнде Вәлиулла, Нәгыймә туташ Байдамшина, Латыйф әфәнде Маликов, Сафа әфәнеде Бакый; 5) Тәтеш өязе мәктәпләренең эчке һәм тышкы эшләрен юлга салуны Мәктәпләр шурасы карамагына тапшырырга; 6) Тәтеш өязендә булган мәктәпләренең хисабын җыеп алу, ил мөселман комитетлары аркылы алынып, мәктәпләр шурасына тапшырылыр; 7) сәркатипкә айга 30 сум бирергә, идарә әгъзаларына җыелыш вакытларында өчәр сум көнлек бирергә (өйләреннән чыккан көненә кадәр); 8) Тәтеш өязе укытучыларының сайланган идәрә әгъзалары: Мозаффар әфәнде Мөштәриев, Латыйф әфәнде Маликов, Кариб әфәнде Вәли, Нәгыймә туташ Байдамшина, Сафа әфәнде Бакый. Наибләр [ярдәмчеләр]: Кадыйр Халидов, Исмәгыйль Мөштәриев, Фәйрүзә Маликова, Шәһит Гаделшин, Гобәйдулла Хәбип; 9) тәфтиш [тикшерү] комиссиясенә сайланган әгъзалар: Солтан Гариф, Кәрим Җәгъфәрев, Маһруй Мозаффария. Наибләр: Каһир Заһиров, Сәгадәт Габдуллина, Әбелмәхҗан Шәфигуллин»[47].

[46] Тәтештә укытучылар җыены // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 1 ноябрь.

[47] Солтан Гарифуллин. Тәтеш өязе мөселман укытучыларының җыелышы // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 7 июль.

Тәтеш төбәгендә дә татарлар яшәгән һәр төбәктәге кебек үк халык тарафыннан ачылган, мәхәллә хисабына тотылган уку йортлары – мәктәп-мәдрәсәләре һәр авылда диярлек була. Әлбәттә, аларның барысын да югары дәрәҗәдә дип әйтеп булмый, бу мөмкин дә түгел, бары тик аларның булуы да төбәкнең рухи халәтен күрсәтүче билге. Гадәттә, остазы булган авыллар тирәяк халкы өчен мәгариф үзәгенә әйләнә. Бер регионда андый ике-өч мәдрәсә булу да шул төбәк халкы рухи тормышы өчен мөһим билге. Тәтеш төбәгендә Бикчәнтәй хәзрәт җитәкләгән Болын-Балыкчы мәдрәсәсен дә, Яңа Чәчкап авылы һ.б шундый мәдрәсәләрне дә атый алабыз. Акъегет мәдрәсәсе һәм аны матди яктан тотучы З. Шәфигуллин гамәлләре белән Тәтеш өязе мәктәп-мәдрәсәләренә яңача – җәдидчә уку алып килә. Бу төбәк халкы бу яңалыкны тиз кабул итеп, алага таба заманча белем бирә торган уку-укыту системасын гамәлгә куя.

## § 2. *Тәтеш шәһәрендә татар мәгарифенең халәте*

Тәтеш өязенең күпчелек халкын татар-мөселманнар тәшкил итсә дә, өяз шәһәрендә яшәүчеләрнең 94 %ын руслар булган. Шәһәрдә яшәүче татарлар бары тик 5 % күләмендә генә була, башка халык вәкилләре бары 1 % кына билиләр. Әмма капиталистик мөнәсәбәтләр үсә башлаганда, татарларга сәүдә, эшкуарлык белән шөгыльләнүгә мөмкинлек ачылган чорда аларның саны шәһәр халкы арасында арта. Аларның саны 1870 елларда 75 ир-ат, 75 хатын-кыз булса, 1908 елга аларның саны 5 мәртәбә арта, 1915 елга Тәтеш шәһәрендә инде ике мең татар гомер иткән. Алар, нигездә, икмәк пешерүчеләр, ат белән йөк ташучылар, вак-төяк сатучы лавка тотучылар була. Тәтеш шәһәрендә татарлар арасыннан зур эшкуарлар билгеле түгел[1]. Монда яшәгән татар балаларына белем бирү, аларны укыту мөмкинлеген табу, аны булдыру төп мәсьәләнең берсенә әйләнә. Тәтеш шәһәрендә рус телендә укытучы уку йортлары шактый булган, татарлар да үз акчаларына шәһәрдә мөселманнар өчен уку йорты ачу мөмкинлеге булдыралар. Теләк белдергән татар балалары өчен рус теленнән дә белем алу мөмкинлеге ачыла. 1886 елда Тәтештә татар-мөселман балалары өчен рус классы булдырыла. Ул казна тарафыннан финансланган уку йорты, аны тоту өчен елына 550 сум акча бүлеп бирелгән. Монда 30 ир бала белем алган. Шулай ук мәчет каршында мәдрәсә эшләп килгән.

XIX гасырның ахырында халык мәгариф министрлыгы акчасына Тәтеш шәһәрендә рус-татар училищесы эшли башлый. Бу Тәтеш шәһәре татар балаларына белем бирүдә зур роль уйнаган уку йорты булып җитешә. Төрле елларда бу уку йортында татар дөньясыда танылган шәхесләр белем бирә. Булачак билгеле педагог, җәмәгать эшлеклеләре М. Т. Мөштәриев (1885–1887), Г.Н. Әхмәрев (1891–1903), И.М. Казаков (1900–1911, 1917–1918) һ.б. үзләренең эшләрен шушы уку йортыннан башлап җибәргәннәр[2].

Тумышы белән Тау ягыннан (Яшел Үзән районы Татар Наратлысы авылы) булган Гайнетдин Әхмәревнең укытучылык эшенең зур өлеше Тәтеш шәһәренең рус-татар мәктәбендә үтә. 1891 елның 1 мартыннан ул әлеге мәктәпкә рус теле укытучысы итеп билгеләнә, әмма мондый мәктәпләрдә укытучы рус теле белән бергә арифметика, уку, ана теленнән дә дәресләр биргән. Дин дәресләрен укыту муллага йөкләнелгән[3]. Тәтештәге хезмәтнең һәрбер елы, ун еллык сәламәтлегемне бетерерлек дәрәҗәдә авыр булды дип искә ала ул мондагы хезмәтен. Бу елларда татар-мөселманнар арасында рус теленә

[1] Миронова Е. В. Уездный город Тетюши во второй половине XIX – начале XX века. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 28.

[2] Шунда ук. – С. 99–100.

[3] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 977 эш, 46 кгз.

карата булган катлаулы мөнәсәбәтне искә алсак, бу аңлашыла да. Хөкүмәт тарафыннан алып барылган сәясәт, татар-мөселманнарның иманына, диненә булган куркыныч халык күңелендәге ышануны какшаткан була. Рус теле аша алар нәкъ менә руслаштыру, диннән яздыру куркынычын күрәләр. Беренчедән, җәмәгатьчелекнең мөнәсәбәте булса, икенче яктан, мулла, дин әһелләренең рус теле укытучысына булган карашы. Алар йөзендә дәүләт сәясәтен алып баручыны да, үзләренә конкурентны да күз алдына китерәләр. Шәһәр мулласы Хәсәнгата Бикташев белән Гайнетдин Әхмәрев арасында, шәкертләр белән рус-татар укучылары арасында даими рәвештә аңлашылмаучанлыклар булып тора. Мулла Хәсәнгата Бикташев, аннан аның кияве Гыйззәтуллин Г. Әхмәрев эшчәнлегенә бик нык аяк чалалар. Мулла, үз нәүбәтендә, халык арасында да мөгаллимгә карата тискәре караш оештыруга зур өлеш кертә[4]. Хәсәнгата мулла «бик актив» кеше булган, аның төрле оешмаларга Г. Әхмәрев өстеннән җибәрелгән донослары, шикаятьләре архив документларында күпләп сакланып калган. Гайнетдин Әхмәрев зыялы, тәрбияле һәм сабыр укытучы булган, ул бервакытта да мулла белән ачык конфликтка керми, аның өстеннән бернинди документ та язмый, бары тик аның Хәсәнгата мулла язган шикаятьләргә биргән җавап хатлары гына бар, төпле, итагатьле итеп җавап бирә белгән. Монда мулланы да гаепләү дөрес булмас иде, чөнки мулланың үз максаты, үз бурычлары, инде ничә гасыр барган, инде урнашып җиткән кадими уку системасына конкурент булган укыту, җитмәсә, яшьләргә рус телен өйрәтү, әлбәттә, аларда курку уяткан. Монда бары тик бер үкенеч кенә була ала: ике якның уртак тел табып, уртак максатка бергәләр хезмәт итүне булдыра алмавы.



Тәтешнең кызлар гимназиясе бинасы.
XX йөз башы почта открыткасы



Тәтешнең ир балалар гимназиясе бинасы.
XX йөз башы почта открыткасы

[4] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 185 кгз.; ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 698 эш, 19 кгз.

Мәдрәсә шәкертләре рус-татар мәктәбендә укучыларны үрти, кайвакытта кимсетә торган да булганнар. Монда да мулланың роле булгандыр. Рус-татар мәктәбендә укучы ир балаларны мәчеттә намаз вакытында төртеп аудару да, рус бәйрәмнәре җиткәч, алардан бу бәйрәмгә ничә дуңгыз суйдыгыз, дип көлү дә, бармакларын тәре формасында куеп үртәүләр дә, мәктәпнең тәрәзәсенә сугып китүләр дә һ.б. була. Абыйлары рус-татар мәктәбендә укыган кыз балаларны да абыстай каккан, «абыйларыгыз укый торган җиргә барыгыз», диюләр дә булган. Болар – барысы да җәмгыятнең шул чордагы халәте. Халыкның башка төрле тормыш рәвешен шулай кабул итү нәтиҗәсе.

Гайнетдин Әхмәрев укучыларның дисциплинасы булмавын, кыр эшләре башлану белән авылларына таралуын, мәктәпкә соң көздә генә кире кайтуларын да яза. Бу да электән килгән мәктәп-мәдрәсәләрдә була торган хәл, монда төгәл уку программасы, уку елының башлануының ачык вакыты булмавы инде билгеле. Авыл малае өчен, укудан бигрәк, кыр эше ул вакытта мөһимрәк булган. Шулай булса да, авырлыкларны җиңеп, Гайнетдин Әхмәрев бу уку йортын үрнәк уку йортлары дәрәҗәсенә күтәрә. Укытучы булып эшләү елларында мәктәп дәреслекләренә ихтыяҗ зурлыгын аңлый. 1890 елда аның «Татарлар өчен беренче урыс әлифбасы», «Татарлар өчен беренче кыйраәт китап»лары дөнья күрә. Болар өчен ул Казанның фәнни-сәнагый күргәзмәсе комитеты тарафыннан мактау кәгазе, укытучылык хезмәтен оста башкарганы өчен 1899 елда көмеш медаль белән бүләкләнә. Ул җитәкләгән Тәтеш мәктәбе Казан уку округы тарафыннан тәкъдим ителеп, 1900 елда Парижда узган Бөтендөнья күргәзмәсендә җиңеп чыга һәм комитетның мактау дипломына лаек була[5]. Тәтеш шәһәрендә кызлар өчен рус-татар мәктәбе дә Г. Әхмәрев һәм аның хезмәттәше Җ. Мускеев тырышлыгы белән ачыла[6].

Г. Әхмәрев Тәтештә эшләгән еларында шул төбәк тарихын өйрәнүче, аны фәнни югарылыкка күтәрүче. Туган як тарихын, шул якта сакланып калган тарихи истәлекләрне өйрәнү дә Тәтешнең рус-татар мәктәбе кысаларында барган дисәк тә ялгыш булмас.

Г. Әхмәрев эшләгән елларда уку йорты Тәтеш шәһәренең Мало-Троицкий урамындагы мәрхүм сәүдәгәр Александр Серебрянников варислары мөлкәтендә булган агач йортта эшли. Мәктәп 1900–1905 еллар арасында әлеге бинада урнаша, 1905 елда бу бинаның инде шактый иске, бүлмәләренең кечкенә булуы билгеле. Бу вакытта мәктәптә 63 бала укыган, бер өлешендә өяз авылларыннан килеп укучы балалар яшәгән. 1905 елда бу мәктәп инде канәгатьләндерми, ә яңа мәктәп төзергә кирәклеге күтәрелә. Яңа бина ирләр мәктәбен дә, кызлар мәктәбен дә сыендыру ихтималы карала, шул ук вакытта

[5] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1017 эш, 148, 179 б кгз.
[6] Шунда ук.
[6] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 907 эш, 68 кгз.

бинага укытучы бүлмәсе, китапханә сыярга тиеш була. Шушы чорда казнадан ирләр мәктәбе 652 сум 41 тиен, кызлар мәктәбе 720 сум алган[7].

1903 елны Гайнетдин Әхмәрев Тәтеш мәктәбеннән Казанга күченә. Мәктәпнең җитәкчесе итеп Г. Әхмәревтән соң Исхак Казаков билгеләнә. И. Казаков мәктәпкә яңа сулыш кертә, бу мәктәп укучылары, шулай ук Казаков та мәктәптә революцион җырлар җырлаган өчен штрафка тартылган булалар. И. Казаковның улы үзенең «Неугомонная жизнь» дигән очеркында әтисе турында «ул мәгарифне үзгәртүгә кереште: дини догматизмны һәм гарәп текстларын ятлауны алып ташлады»[8], дип яза. Мәктәптә дөньяви фәннәр күбрәк укытыла башлый. Телләр өйрәнү арта, табигать белеме, география, химия, физика укытыла, кул эшләренә өйрәтәләр. Кызлар өчен кул эшләре һәм кулинария нигезләре дигән предметлар керә башлый[9].



Тәтеш шәһәре, рус-татар мәктәбе укучылары. XX йөз башы

[7] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1067 эш, 28–30 б кгз.

[8] Миронова Е. В. Уездный город Тетюши во второй половине XIX – начале XX века. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – С. 100.

[9] Шунда ук.



Тәтеш шәһәре, рус-татар мәктәбе укучылары
фотога төшү өчен бер сыйныфка җыелганнар. XX йөз башы

Тәтеш мәктәбенә мөнәсәбәт берьяклы гына булмаса да, бу мәктәп халык ихтирамын яулап ала ала. Чөнки бу мәктәптә балаларны дөньяга әзерли алганнар, алар һөнәр, белем алганнар, тел өйрәнгәннәр. Алдан 40 балага гына исәпләнгән бу уку йортында укучылар саны арта бара, 1908 елда аларның саны 100 кешегә җитә. Әлбәттә инде, монда шәһәр балалары гына түгел, ә авыллардан да килеп укыганнар. Шуңа да аларны каядыр яшәтү проблемасы да булган, авыллардан килгән крестьян балаларының фатирга түләп яшәү мөмкинлеге юк. 1908 елда укытучыларның дәүләт оешмаларына язган мөрәҗәгатьләренең нәтиҗәсе булып, мәктәпнең үз тулай торагын булдыру тора. Татар-мөселман балаларының укуларына, яшәүләренә матди ярдәм итү өчен мөселманнар тарафыннан төрле хәйрия чаралары оештырыла. Мисал өчен, 1910 елда Тәтеш мөселман ир балаларына ярдәм йөзеннән укытучылар катнашында спектакль күрсәтелгән[10].

---

[10] Миронова Е. В. Уездный город Тетюши во второй половине XIX – начале XX века. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 151 с.

Тәтеш шәһәре мөселманнары мәгарифе үсешенә үзеннән зур өлеш керткән шәхес татар җәмгыятендә билгеле педагог Мозаффар Таҗетдин улы Мөштәриев (1863–1937). Тумышы белән Тәтеш өязе Үтәмеш авылыннан, Истанбулда белем алган, аннан 1915 елга кадәр Казанда мөгаллимлек иткән. Туган ягына кайтып, Тәтештә һәм Келәнче авылында мөгаллимлек итә. 1917 елда Тәтеш өязендә укытучылар курсы оештыра. Алга таба ул мөгаллимлек эшен Оренбург, Ташкент, Казан шәһәрләрендә мәктәп мөдире, татар һәм рус телләре укытучысы буларак дәвам иткән. 1917 елның 15 июлендә ул оештырган курсларга сиксәнгә якын укучы килә. Укучыларны үзләренең белемнәренә карап ике бүлеккә аерып укыталар. Ә бөтенләй укый-яза белмәгән олы агайлар өчен дә кичке курслар ачыла, курсны Сафа әфәнде Бакый һәм Хәмид Мозаффар Мөштәриевләр алып баралар. Хәмид Мозаффар улы Мөштәриев (1900–1981) татарлар арасында беренче физика-математика фәннәре докторы, профессор буларак билгеле. 1946–1972 елларда СССР ФА Казан филиалының физика-техника институты директоры булган галим[11].

Тәтеш шәһәре инкыйлабка кадәрге чорда уку-укыту системасы камилләшкән, югары дәрәҗәгә күтәрелгән белем бирү системасы булган өяз шәһәрләренең берсе булган. Анда дини белем дә, русча өйрәтү мәктәпләре дә, һөнәр үзләштерү мөмкинлеге дә була. Инкыйлабка якынайган елларда мәктәп системасына критик фикерләр, үзгәрешне таләп итү рухы да үтеп керә. Тәтеш татар җәмгыятендә, ил күләмендә барган вакыйгаларның бер мөһим үзәге булып җитешә. Бу шәһәрдә һәм өяздә киләчәктә атаклы педагоглар булып танылачак шәхесләр беренче тәҗрибәләрен алалар, профессиональ юлларын биредә башлыйлар.

[11] «Тәтеш оешмасы» газетасы // Безнең мирас. – 2020. – № 2. – Б. 25–29.

## § 3. *Мулла белән укытучы: заман көрәше*

XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар тарихында үзенчәлекле бер чор, ул җәдидчелек күренеше белән башланган үзгәрешләр. Нинди генә уңайсызлыклар булса да, үзгәреш беркайчан да беркатлы гына кабул ителмәгән. Традицион тормыш белән заман таләп иткән үзгәрешләр җәмгыятьнең бар өлкәсендә дә бер-берсе белән каршылыкка килми калмаган. Әмма ләкин бервакытта да традиционлыкка яңалыкны каршы куярга ярамый, берсе бик әйбәт булып, икенчесен бик начар итеп бәяләү бервакытта да үзен акламый. Һәр нәрсәнең уңай ягы булган кебек үк, һәр нәрсәнең җитешмәгән, кайвакытта хилаф ягы да була.

Тәтеш өязендә дә бу ике каршылык Тәтеш шәһәрендәге мәдрәсә белеме белән, рус телен өйрәтүче мәктәп арасында бара, әлбәттә бу – ике уку йорты кысаларында гына булган күренеш түгел, ә җәмгыятьнең үзендәге халәт. Аның каршылыклары, киеренкелеге беренче чиратта уку системасында күренә. Тәтеш төбәгенә якын булган данлыклы уку йорты – Буа мәдрәсәсенең белем бирү системасы традиционлыкка корылган, ягъни ул дини белем бирү үзәге була. Ул бу җирлекнең дини мәгариф, гадәтләрен тотып тора торган, саклый торган үзәк. Тәтеш төбәгендәге имамнар да дини-традицион караштa нык торган руханилар булган, җәмгыятькә килеп кергән үзгәрешләр бу төбәккә Казан артына караганда, соңрак та килә, алай ук зур тәэсир дә ясый алмый. Хәзерге Яшел Үзән районына караган Акъегет авылы мәдрәсәсенең яңача укыту рәвешенә күчә баруы, аның тәэсирендә башка авыл мәдрәсәләренә җәдидчелек үтеп керә башлаган дәверендә генә хәлләр үзгәрә башлый.

Бу ике замана арасындагы аңлашылмаучанлык Тәтеш шәһәренә рус теле укытучысы буларак килгән Гайнетдин Әхмәрев һәм Тәтеш шәһәре мулласы – традицион фикерендә нык торучы шәһәр мулласы Хәсәнгата Бикташев мөгалләмәсендә күренә. Бу капма-каршылык ике шәхес арасында барган аңлашылмаучанлык кына түгел, ә шул вакыт җәмгыятенең ике карашы итеп кабул итәргә кирәк.

Илгә капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керә башлагач, татарлар да бу экономик процесста, киң даирәдә аралашуда активлашкач, әлбәттә, рус телен белү ихтыяҗы бермә-бер арта башлый. Шунлыктан, рус телен өйрәнергә теләүчеләр, үз эшләрен киңәйтү өчен дә, үз ана теленнән башка телләр кирәклеген дә тоя башлый. Читкә китеп эшләүләр дә рус теле белүне таләп итә, мобильлерәк яшь буын бик теләп рус сыйныфларында да укый башлый. Хәтта кадими уку йорты буларак ачылган Акъегет авылы мәдрәсәсендә дә рус сыйныфлары ачыла. Ул сыйныфлар һәм өстәмә курслар телне өйрәнергә теләүчеләрне сыйдыра да алмый башлыйлар. Татарларның киңкырлы белемгә тартылулары, рус телен әйбәт белүләре хакимиятне сагайта да. Тәтештә дә

Г. Әхмәрев рус теле укытучысы буларак килгәч, аңарда укырга теләк белдерүчеләр шактый күп була. Әмма мулла Хәсәнгата Бикташев һәм аның абыстае татар балаларының рус телен өйрәнүләренә каршы булалар, төрле юллар белән моны булдырмаска тырышалар. Бу очракта бу ике якны бер-берсенә каршы кую дөрес булмас иде. Г. Әхмәрев тә, шул ук Хәсәнгата Бикташев да халык өчен борчыла, берсе – аның алга таба үсешен, заман үзгәрешенә яраклаша алуын алгы планга куйса, икенчесе – бу шаукымда халык үз йөзен югалтмасын, юлыннан тайпылмасын дип тырыша. Икесенең дә максаты бер – халыкның бербөтенлеге, аның киләчәккә ныклы адым белән баруы. Алар бары тик бер мәсьәләгә төрле яктан карап, максатка үзләре инанган юл белән барырга тырышалар. Мулла рус телен өйрәнүче яшьләрне, аларның гаиләләрен үз авторитеты белән куркытып та карый. Мисал өчен, алар уздырган ашларга бармый, алар сораган дини ихтыяҗларны хәл итүдән баш тарта, абыстай да, әгәр дә гаиләдә бер ир бала рус теле өйрәнүгә йөри икән, гаиләдәге кызларны үз мәктәбенә алмый башлый. Мулла белән абыстай бу үзгәрешләргә бердәм булып икәүләшеп көрәшәләр. Аларның абруе да, шәһәр халкына тәэсир дә зур булганлыгы күренә, алар мулла абзыйдан шүрләгәннәр. Рус сыйныфына җыелган 52 баланың бары тик 5 се генә шәһәрнеке булу – күп нәрсә турында сөйли. Рус телен өйрәнүгә килүчеләрнең зур күпчелеген авыл балалары тәшкил иткән. Мондый эштә бай катлам – шул ук сәүдәгәрләр дә үз капиталы белән үзләренә отышлы булган юлга бора алганнар. Бу хәлдә дә Тәтеш шәһәренең сәүдәгәре үз кызларын абыстайда укытмыйча, кызларны укытырга татар мөгаллимәсе китертүгә рөхсәт сорый. 1899 елның беренче яртысында Тәтеш сәүдәгәре Җиһанша Хәйретдин улы Мускеев канаты астында эшли торган татар хатын-кызлары мәктәбе ачыла. Мөгаллимә буларак Кече Әтрәч авылының Бибиҗәмал Агамәрданова китерелә (русча докуметларда фамилиясе Агимарданова).

Мулла Хәсәнгата Бикташев үз позициясендә нык торучы традицион карашлы мулла булган һәм үзенең бу мәсьәләдә хаклы булуын расларлык бик актив гамәлләр кыла. Хәтта ки, шәһәр мещаннарына каршы барып, рус теле укытуны яклаганнарга мулла буларак үз хезмәтен күрсәтми. Аның бу гамәленнән мещан Хөснетдин Курамшин, Шәмсеҗәмал Мостафина, Гыймадетдин Хәтәмев, Сатыйга Баһаветдинова һ.б. мәхрүм булалар. Хөкүмәт уку йортында дин гыйлеме буенча укытучылык иткән Җәләлетдин Таһиров та рус сыйныфы укытучысы Гайнетдин Әхмәревкә ярдәм иткән өчен тәнкыйтьләнә. Хәсәнгата Бикташев Г. Әхмәревне «шәйтан» дип атый. Г. Әхмәрев тә Тәтештә эшләгән елларын, иң авыр еллар итеп искә ала. Һәр елы 10 еллык гомеремне кыскартты дип бәяли ул вакытны[1]. Мулла бу мәктәпне бетергән балалар «ни татар, ни урыс» булмый, андыйларны әле чукындыралар да дип

[1] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык /төз.-авт. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Җыен, 2011. – С. 15.

куркыта. Ул махсус куркыту түгел, ә борчылып әйтелгән сүзләр итеп кабул итү дөресрәк булыр. Халык та яңа тормышка караганда, аның фикеренә күбрәк игътибарлы булган, XIX йөз ахыры – XX йөз башында Тәтеш шәһәрендә белем алучы татар ир балаларының күп өлеше нәкъ менә мулла мәдрәсәсенә йөргән. 1897 елгы халык санын алуда да Хәсәнгата Бикташев каршылык күрсәткән, үз гамәлләре белән халыкны «чукыну куркынычыннан» яклап-саклап калам дип инана. Яңадан ислам диненә кайткан 20 керәшен баласын үз мәдрәсәсенә укырга ала.



Тәтеш шәһәре мулласы
Хәсәнгата Бикташев.
ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 7249 эш.



Гайнетдин Әхмәрев
(1864–1911)

Татарларны «рус мәктәпләрендә укуларына каршы котыртуы өчен» мулла өстеннән жалоба бирелә. 25 ел Указлы имам булып торган, 13 ел дәвамында дини гыйлем биргән мулла үзен гаепләүне кабул итә алмый, монда ул аңа каршы булган кешеләрнең кулы уйнавы итеп кабул итә. Мулланың беренче шиге төшкән кешеләр – сәүдәгәр Мускеев һәм дә рус теле укытучысы Г. Әхмәрев. Хәсәнгата хәзрәт фикере буенча, Мускеев шәһәр мулласы итеп үз кияве – Олы Мәрәтхуҗа (хәзерге Кама Тамагы районы) имамын куярга тели. Г. Әхмәрев белән дә фикер каршылыклары зур булганга, укытучының да мулланы урыныннан алу теләге булу ихтималын белдерә. Тәтештә яшәүче байлар, сәүдәгәрләр мулла Х. Бикташев өстеннән шикаять-

ләр язалар. Алар арасында Җиһанша Хәйретдин улы Мускеев, аның ир туганы Габдулла, абыйлары Йосыф Төхвәтулла улы Мускеев, аларның приказчиклары Гафур Нәфигов, шулай ук Мускеев канаты астында эшләүче уку йортының дин гыйлеме укытучысы Җәләлетдин Гыймаддин улы Таһиров, Мускеевнең туганнары – Исмәгыйль Сибагатуллин, кодасы мещан Гатаулла Гизеев һ.б. була. Аңа каршы булган әлеге гаепләү махсус оештырылганга да ошый, чөнки аның өстеннән язучылар барысы да туганлык җепләре белән бәйле кешеләр. Аннан кала, Ситдика Баһаветдин кызы карт әтисе Баһаветдин Ярсәлимов белән, аның ире Мөхәммәтулла Габдулла улын куркытып мулла өстеннән прошения яздыралар дип белдерә. Муллага эш ачу, җәза бирү буенча Гафур Нафиковтан, Җәләлетдин Таһировтан, Гайнетдин Әхмәревтән, Мөхәммәдиша Ярсәлимовтан, Гыймадетдин Хәтәмевтан, Шәмсеҗәмал Габитовадан, Габдрахман Кәримовадан, моннан кала, имамнар – Олы Тормы авылының (хәзерге Тәтеш районы) Зыятдин Шәрәфетдиневтан, Мәрәтхуҗа (хәзерге Кама Тамагы районы) имамы Бәдретдин Шәрәфетдиневтән, Келәш (Тәтеш районы) мулласы Хәмидулла Бакучевтан, Борнаш (хәзерге Апас районы) мулласы Мөхәммәдвәли Миңлевәли улыннан сорау алулар була. Бу вакыйга – ике заман каршылыгы шактый зур таралыш алып, тирә-як өчен тетрәндергеч бер хәл икәнлеге күренә. Мулла 1900 елның 18 сентябрендә 2 елга мөселманнар яшәми торган төбәккә сөргенгә сөрелүгә хөкем ителә. Ул сөрген хөкемен Сембер губернасы Сызрань шәһәрендә уздыра. Мулла китер алдыннан мәхәллә халкын җыеп, үзе булмаганда мәхәллә халкына мулла итеп, вакытлыча, Бакырчы мулласы Габдулла Гыйззәтулла улы Сөләймановны сайларга өнди. Кызын аңа кияүгә бирергә ризалыгын бирә. Гыйззәтуллин[2] Бикташевның кызына өйләнеп, Тәтеш шәһәрендә мулла вазыйфаларын да башкара, мәдрәсәдә дини гыйлем дә бирә башлый. Әмма Гыйззәтуллин имам эшенә дә каршы чыгучылар табыла, беренчедән, аның мәдрәсәсендә мәкрүһ [киредән исламга кайтучылар] балалары да белем алуы (исламга кайткан 20 баланы үз мәдрәсәсенә Бикташев имам алдырган иде) һәм дә Гыйззәтуллинның дини белемне Россиядә түгел, ә Төркиядә алуы ризасызлыкка бер сәбәп була. Сөргендә булса да, Хәсәнгата Бикташев Тәтеш мөселманнары белән араны өзми, аның хатыны Фатыйма абыстай Сызрань белән Тәтеш арасында йөреп, Тәтеш мөселманнарына мулланың язган хатларын кайтарып тора. Хәсәнгата Бикташев шактый бунтарь, кискен имам була, аның аралашу, туганнары даирәсендә дә властьлар белән каршылыкка кергән кешеләр булган. Мисал өчен, кыз туганының җәмәгате – Зөя өязе Салтыган (Кайбыч районы) мулласы Таҗетдин Мөхәммәдьяров XIX йөзнең 70 нче елларында ук Себергә сөрелә, соңгы хатынының атасы – Спас өязе Түгелбай авылы мулласы шулай ук Себергә сөрелгән, бертуганы Зариф Бикташев шулай ук качак, ул солдат хезмәтеннән качып Төркиягә киткән

[2] Документларда алга таба бу фамилия белән күрсәтелә.

була. Таҗетдин Мөхәммәдьяров турында исламга кайту көрәшенең лидеры булуы һәм Турухан төбәгенә сөрелгән башимәс каһарманнарның берсе икәнлеге китапның махсус бүлегендә тәфсилләбрәк сөйләнәчәк.

Х. Бикташевны кулга алганда аның 9 китабын һәм хатларын алалар, әмма ул бары 4 китабын гына үзенеке итеп кабул итә, калганнарыннан баш тарта, 5 китап һәм хатлар Баһаветдин Хәмзә улы Вәисевнеке дип таныла. Мулланың Вәисиләргә бәйләнеше булганмы? Бу хакта тикшерү органнары да төпченеп тормыйлар.

Тәтеш мулласының нахакка сөрелүен белдереп тиешле органнарга прошение бирелә, аны 23 Тәтеш мөселманы имзалый. Шулай булуга да карамастан, Бикташев үзе хөкем ителгән 2 еллык сөргенне үтәргә мәҗбүр була. Кайткач, ималыкка бирелгән Указын да алалар. Тәтешкә мулла кую, кемне билгеләү мәсьәләсе яңадан килеп баса, Мускеев белән мулла арасындагы каршылык 2 ел элек булганы белән яңадан күтәрелә. Гадәттәгечә, сәүдәгәр мулланың кияве Гыйззәтуллинны мулла итмәскә, ә үз кияве Олы Мәрәтхуҗа авылы мулласын куярга тырыша. Алар үзара тарткалашкан вакытта Келәш авылы мулласы вакытлыча гына булса да, Тәтеш мөселманнарына хезмәт итә[3]. Муллалык вазыйфасы алынгач та, тәтешлеләргә дини хезмәт күрсәткән дип яла ягарга тырышулар да күренә. Ул нинди генә булмасын, Тәтеш мөселманнары арасында нык позицияле, үз карашына тугры булган, бар авырлыкларны күтәреп, яңадан туган җиренә кайтып, мәхәллә халкын үз тарафына аудара алган мулла буларак таныла.

Рус теле укытучысы Гайнетдин Әхмәрев Тәтештә эшләгән елларында инде тарих белән кызыксынып, фәнни эзләнүләргә кереп китә. Аңа да инде мулла белән көрәшеп яту кирәк булмый. Мулла Бикташев һәм аның кияве Гыйззәтуллин Г. Әхмәрев өстеннән бик күп шикаятьләр биреп өлгерә. Бу ике шәхес 10 ел дәвамында ике заман, ике караш көрәшен гәүдәләндерә.

Әйткәнебезчә, бу вакыйгалар ике шәхес арасында барган күренеш кенә түгел, ә бу ике шәхес, аларның тирәлеге арасында барган вакыйгалар җәмгыятьнең көзгесе. XIX–XX йөзләр чигендә традиционлык белән яңарышның көрәше ни дәрәҗәдә кискен торганлыгы, бу көрәш тарафдарларының үз позицияләренең ныклыгы чагыла. Үзгәреш озак һәм катлаулы бара торган процесс. Заман үзгәреш таләп итсә дә, традицион позициядә торучыларның моңа саклык белән килүләренә дә объектив бәя бирергә кирәк. Татар җәмгыяте уртак максатка ирешү өчен төрле юллар белән барган. Тәтеш мөселманнары арасындагы әлеге хәлләр җәмгыятьнең шул чордагы үз юлын табу омтылышы, җәмгытьнең җиңел генә бармаган үзгәреш юлын күзалларга мөмкинлек бирерлек мисал.

[3] ТР ДА, 1 ф., 3 тасв., 11384 эш. 1–65 кгз.

## § 4. Л.Н. Толстой белән аралашкан Тәтеш мөгаллиме

XX йөз башында җәмгыятьтә фикер төрлелеге барлыкка килә башый, хөрлеккә омтылыш, үзгәреш теләү алгы планга чыга. Бу хәлләр уку йортларында бигрәк тә ачык чагылыш таба, чөнки яшь кешеләр дөньяга киңрәк карыйлар, алар заман үзгәрешләре белән бергә барырга телиләр, шуңа да элекке укыту тәртипләре белән килешмиләр. Элек катгый итеп кабул ителергә тиешле дини тәгълиматларны да анализлый, фикерли башлыйлар. Татар мәдрәсәләренең барысында да диярлек үтеп кергән шәкертләр хәрәкәте шуның нәтиҗәсе. Аннан инкыйлаби фикерләрнең тәэсире дә көчәя. Мөгаллимнәр, шәкертләр арасында да жандарм күзәтүенә эләккән яшьләр арта башлый.

Тәтеш мәктәбе дә бу хәлләрдән читтә калмый. 1903 елда Г. Әхмәрев Тәтештән күчеп киткәч, мәктәпкә җитәкчелеккә шунда укыткан Исхак Казаков (1876–1939) килә, аның улының хәтирәләре буенча, ул килү белән үк укыту системасын үзгәртә башлый, дини предметларны, догалар ятлауны кыскартып, алар урынына телләр өйрәнү, табигать белеме, география, химия, физика, кул эшләре буенча дәресләр кертә. Исхак Мостафа улы Казаков Тәтеш мәктәбендә 1900–1911, 1917–1918 еллар аралыгында эшли, ул эшләгән елларда Тәтеш мәктәбенә инкыйлабый фикерләр керә башлый. Белүебезчә, ул күренекле татар революционеры Мулланур Вахитовның абыйсы, гаиләдәге сәяси карашларның тәэсир көче булган, күрәсең. Шушы ук нәсел кешесе – Рабига Казакова Акъегет авылы мәдрәсәсенә 1910 елда рус теле укытучысы булып килә, әмма аның инкыйлаби карашлы булуы властьларны канәгатьләндерми, аның укытучылык кандидатурасын алалар[1].

Тәтеш мәктәбендә шушы елларда башланган үзгәрешләрдә монда белем алган укучылар да катнаша. Казаковны хөкүмәткә каршы алып барган пропаганда, укучылар белән бергәләп сәяси характердагы җырлар җырлаган өчен 1911 елның июнедә кулга алып, төрмәгә утырталар, аннан ул гаиләсе белән Сембер губернасына сөрелә, алга таба укытучылык итү хокукыннан мәхрүм ителеп, Оренбург тарафына җибәрелә[2]. Казаков шәһәрнең сул карашлы татар яшьләре арасында бик популяр, хөрмәтле кеше булган.

И. М. Казаков кулга алынганнан соң, аның урынына Тәтешнең ике сыйныфлы рус-татар мәктәбе белән идарәгә килгән Шәмсетәбриз Салиховка

---

[1] ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1578 эш, 3 кгз.

[2] Хузеева Л.В. «Мне нужна только свобода и свобода…» // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2002. – № 1/2. – С. 101–106.

карата 1913 елда укучылар белән «Рәсәйнең сәяси дәүләт төзелешенең үзгәреше» турында сүз алып барганы өчен дигән яла ягыла. Мәктәпнең югары сыйныфында 1912 елның декабрендә уздырган дәресенә сылтама итеп аның өстеннән шикаять итәләр. Бу хәлләрне тикшерүдә шул мәктәптә белем алучы Иске Карамалы авылының (Кама Тамагы) 18 яшьлек Ярулла Исмаев, Чирү-Бураш авылының (Апас районы) 19 яшьлек Мөхәммәдша Заһидуллин, Самара губернасы Бөгелмә өязе Сарабиккол авылының (хәзерге Лениногорск районы) 19 яшьлек Фәтхелбари Ногманов, Олы Тормы (Тәтеш районы) авылының 18 яшьлек Садретдин Алтынбаев, Гыйльфан Гыймранов, Югары Урысбага авылының 16 яшьлек Шәһиәхмәтев һәм шул мәктәпнең дин гыйлеме буенча белем бирүче Камалетдин Мостафиннан сорау алулар була. Салихов эше буенча укучылар каршылыклы җаваплар бирсәләр, Камалетдин Мостафин берни җавап бирмичә бары елмаеп кына тора. Тәтеш мәктәбе җитәкчесе Салиховның өендә, ул Казаков өендә яши торган була, тентү уздыралар, әмма шикләнерлек берни табылмый. Тикшерү нәтиҗәсе буларак, зыялы мөгаллимгә нахак яла ягылган дигән нәтиҗә ясала.

Шәмсетәбриз Салихов чыгышы белән Малмыж шәһәре мещаннарыннан, ул заманы өчен шактый алдынгы карашлы, кызыксынучан кеше була. Тентү вакытында аның өендә атаклы рус язучысы Л. Н. Толстой тарафыннан тупланган «Мысли мудрых людей на каждый день», дип аталган китап һәм аның Л. Н. Толстой белән язышкан хатлары табыла. Л. Н. Толстой 1903 елның январь аеда авырып китеп, гадәти эшләре белән шөгыльләнә алмый башлый. Шул вакытта акыл ияләренең төрле хикмәтле сүзләре язылган бүлмәдәге календаре аны шундый типтагы хезмәт язарга этәрә. Ул бөек шәхесләрнең тормышы турындагы уйлануларын, фәлсәфәләрен туплап, кызыклы хезмәт тәкъдим итә. Бу китабына аның төрле чор кешеләре, бөекләре: Эпиктет, Диоген, Марк Аврелий, Сократ, Конфуций, Будда, Аристотель, Паскаль, Руссо, Спиноза, Кант, Шиллер, Шопенгауэр, Вольтер, Теккерий, Достоевский фикерләре тупланган. Гап-гади татар егете, мөгаллим Шәмсетәбриз Салихов дөньякүләм атаклы акыл ияләренең фикерләре, аларның дөньяга карашлары белән Л. Н. Толстой хезмәте аша таныша, хезмәтне укып кына калмыйча, үз фикерләрен, күңелендә калган сорауларны бөек рус язучысы Л. Н. Толстойга хатлар аша юнәлтә.

1910 елның августында Шәмсетәбриз Салихов Ходай турында үзен кызыксындырган сорауларын биреп, Л. Н. Толстойга хат яза. Озак та көттермичә, 1910 елның 22 нче августында ук Л. Н. Толстой җавап та бирә, хат машинкада басылган, хатка Лев Николаевич үз имзасын куйган. Ходай, аңа ышану турында фикерләгән хатында Л. Н. Толстой: «Верить надо, и нельзя не верить, потому что одно и то же во всех верах, есть признание высшего совершенства – Бога, к которому надо приближаться, и любовь ко всем

людям – братьям»[3], дип яза. Татар мөгаллименең фәлсәфи фикерләве, югары көч, хаклык эчтәлеген аңларга тырышу, дөньядагы халыкларның дини аермалыкларына карамастан да, бердәм дуслыгы, мәхәббәт һәм башка шундый төшенчәләр турында төпле фикерләре аеруча кызыклы. Шәмсетәбриз Салихов: «на мой рассудок непоколебимо шепчет мне, что Он есть, Он – добро и я Ему верю, хочу верить и верить». Мөгаллимнең икенче хатына да Л. Н. Толстой шунда ук җавап яза, Л. Н. Толстой хатында «письмо Ваше от 5 сентября я получил и прочел с удовольствием, Ваши суждения о Боге и жизни человеческой, прочел с удовольствием, чем согласен с Вами», дип үз фикерләрен белдереп, «А это одно и тоже во всех верах есть то, что все люди равны, все братья, п.ч. во всех один и тот же Дух Божий и что поэтому нужно со всяким человеком обращаться с любовью и уважением и что этого самого и хочет дух Божий, живущий в нас. Если будешь верить в это, т.е. стараться жить в любви со всеми людьми, не разбирая того, все ли или много ли людей живут так, и жить самому по этому закону, зная, что в такой жизни найдешь самое большое благо»[4].

Алар арасында барган язышу, хатлар эчтәлеге җылылык, бер-берсенә хөрмәт белән сугарылган. Бөек язучы гап-гади мөгаллимгә зур хөрмәт, сабырлык белән хатлар яза, берүк дәрәҗәдә торып фикерләрләшә, аның җавабы белән килешүен, аны кабул итүен дә күрсәтә. Салихов үз хатларында Лев Николаевичка «Многоуважаемый, Лев Николаевич», дип дәшсә, язучы үз хатларын «Любезный брат, Табриз Салихов», дип башлый. Хатына «Брат Ваш Л. Толстой», дип имза куя. Тәтеш мөгаллиме Л. Н. Толстойга язган хатларын «Уважающий брат Ваш юноша татарин, мусульманин Табриз Салехов», дип тәмамлый.

Л. Н. Толстой Салиховка 22 нче августа ук язган хатында мөгәллимгә китаплар җибәргәнен хәбәр итә: «посылаю Вам несколько книг, из которых Вы яснее поймете эту единую веру», әмма бу китаплар ни сәбәпледер адресатка килеп җитми, Салихов икенче хатында «…письмо Ваше от 22 августа сего года я получил, за что искренне благодарю Вас, но упомянутые Вами книжки до сих пор не получил, и не знаю какая тому причина»[5]. Л. Н. Толстой аңа бу китаплардан кала, алдагы, 1910 елның 18 нче сентябрендә язган, хатында да тагын китаплар җибәрәчәге турында яза: «удивляюсь, что книги мои не дошли до Вас, когда вернусь домой, я живу теперь не дома, и вернусь 22 го, узнаю почему. Теперь же посылаю Вам отсюда несколько книг»[6]. Бу җибәрелгән китапларның барысы да мөгаллим Шәмсетәбриз Салиховка килеп

[3] ТР ДА, 1 ф., 6 тасв., 838 эш, 5 кгз.
[4] ТР ДА, 1 ф., 6 тасв., 838 эш, 5–5 б. кгз.
[5] ТР ДА, 1 ф., 6 тасв., 838 эш, 5 б.–6. кгз.
[6] ТР ДА, 1 ф., 6 тасв., 838 эш, 6–6 б. кгз.

ирешкәнме – бу хакта төгәл генә әйтәсе авыр, әмма тентү вакытында аның өендә «Мысли мудрых людей на каждый день» табылган икән, бу Л. Н. Толстой аңа күндергән китапларның берсе булуы бик ихтимал.

Бөек рус язучысы, фәлсәфәчесе Л. Н. Толстой белән аралаша алырлык, аның белән әңгәмә тотарлык татар яшьләренең булуы, аларның белем дәрәҗәсе, фикерләү югарылыгы XX йөз башы татар җәмгыятенең күрсәткече була ала. Бу яшь мөгаллимнең Казаннан шактый читтә булган Тәтеш төбәгендә булуы, андагы фикер үсешенә йогынты ясавы, аның шундагы яшьләрне тәрбияләве – Тәтешнең инде гадәти генә авыл тормышы белән яшәүче төбәк түгеллеген, ә иҗтимагый фикер формалашкан, камилләшкән төбәк, татар җәмгыятенең мөһим бер үзәге булуга да ишарә ясый.

# V бүлек

# XVIII ЙӨЗ АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫНДА ТӘТЕШ ӨЯЗЕНДӘ ИҖТИМАГЫЙ ХӘРӘКӘТЛӘР

## § 1. *Чукындыру һәм иманга кайту хәрәкәте*

Тау ягы татарлар тормышына да чукындыру сәясәте кагылмый калмый. 1890 нчы елларга караган мәгълүмат буенча Тәтеш өязендә 2803 ир-ат, 2837 хатын-кыз керәшен исәпләнгән[1]. Казан яулап алынгач ук башланган чукындыру сәясәте Тәтеш төбәгенә, үзәктән ераграк урнашкан булу сәбәпле, беренче этабында ук килеп җитә алмаган. Хәзерге вакытта Тау ягында керәшеннәр күп булмаса да, бу сәясәт күп кенә авылларның тарихында, халык язмышында хәлиткеч роль уйнаган. Хәзерге Кайбыч районына керә торган авылларда керәшеннәрнең бер үзенчәлекле төркеме – Мәлки керәшеннәре яши. Алар шушы төбәкнең Мәлки, Хуҗа Хәсән, Байморза, Иске Кырбаш, Зур Тәрбит, Кыр Буасы һ.б. авылларда яшәүче керәшеннәр үз тарихларын, үз үзенчәлекләрен саклап киләләр. Аларның килеп чыгышы турында әлегә кадәр төрле фикерләр бар, инкыйлабка кадәрге әдәбиятта аларны татарлашкан чуашлар дип карау да, яисә аларның формалашуында чуашларның да, татарларның да катнашы барлыгын күрсәтү дә очрый. Ш. Мәрҗани: «Казан губернасының Тәтеш өязендә Хуҗа Хәсән дигән исемне бозып, Хуҗасән дип йөртелә торган бер чуаш авылы бар. Телләре – ар һәм төрки тел, ә гадәтләре чуашча икән. Хәзер христиан динен тоталар. Шул яктагы татарларның сүзләренә карагандა, моннан 80–90 еллар элек бу авылның ташланган бер иске мәчете дә булган»[2], дип яза. Шунысы кызыклы, Хуҗа Хәсән, Мәлки, Иске Тәрбит авыллары янында борынгы мөселман зиратлары булганлыгы билгеле, халык хәтере буенча, анда авылларны нигезләүче бабалары җирләнгән, каберлекләрен зыярәт итеп торганнар. Мәлки керәшеннәренең бер өлеше үзләренең мәчет-

[1] Крещенные татары Казанской губернии: этнографический очерк /[соч.] Н. Одигитриевского. Издание второе. – М.: Печатня А. И. Снегиревой, 1895. – С. 4–5.

[2] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1989. – Б.74–75.

ләре булуын да хәтерендә саклый. Мәлки керәшеннәре сан ягыннан күп түгел. 1719 елда аларның исәбе 1,8 мең, 1897 елда 5,9 мең, ә 1907 елда 7,7 мең, 1926 елда 7,4 мең кеше күрсәтелә[3].

Чукындыру сәясәте башлану белән төбәктә миссионерларлар активлашкач, бу афәттән качу өчен Тау ягының Казанга якынрак булган төбәкләреннән, бигрәк тә, хәзерге Яшел Үзән, Кайбыч районына караган авыллардан күчеп, халык хәзерге Апас, Буа, Чуаш республикасы ягында таба китеп яңа авыллар да корган. Авыл исемнәренең охшашлыгы, нәсел туганлыгының булуы, авылларның нигезләнү вакыты – бу хакта фикерләргә җирлек бирә.

Тәтеш өязендәге керәшен саналганнар татарлар «яңа керәшеннәр» («новокрещенные») дигән төркемгә карый. Бу вакытта инде көчләп чукындыру көтелгән нәтиҗәләр бирми башлагач, үгетләү, ташламалар белән кызыктыру һ.б. шундый алымнар кулланыла. Авыр тормышта яшәгән крестьяннарга бу юлга басарга этәргән сәбәпләр, әлбәттә җитәрлек булган. Җир азлыктан интеккән крестьян да, ярты гомерен солдатта үткәрергә теләмәгән татар да, төрле налоглар белән күмелгән авыл кешеләренең бер өлеше христиан динен кабул итеп, тормышта беркүпмедер җиңеллек табарга теләгәндер. Җинаять җаваплыгыннан котылу, хәтта кемгәдер үч итеп тә иманын алыштырырга җөрьәт итүчеләр булган. Авылның бер өлеш халкын рәсми документларда керәшен итеп санау, аларга рус исемнәре кушып, аларны чиркәү метрика кенәгәләренә теркәү – бу сәясәттә иң еш кулланыла торган практика була. Мондый керәшеннәр еш кына үзләренең керәшен икәнен белмәгәннәр дә, белсәләр дә, аңа әлләни игътибар итәргә тырышмаганнар. Авылның мөселманлыкта калган өлеше дә аларның күңел халәтенә тыкшынмаска, рәнҗетмәскә тырышкан. Әмма керәшеннәр саналган кешеләрне авыл мулласы мәчеткә кертмәскә, аларны мөселманча җирләмәскә, аларга никах укымаска, бала исеме кушмаска тиеш була. Гасыр дәвамында бербөтен итеп яшәгән авыл җәмгыяте каты контроль булмаганда бу тиешләргә әллә ни игътибар биреп тормый, әмма муллага үч итүчеләр булганда мулланың бу гамәлләрен үз файдасына кулану очраклары булып торган. Мулла керәшеннәрне мәчеткә кертте, аларга никах укыды дип өстеннән жалоба язып, Указларын да алдырту, яисә сөргеннәргә җибәрү очраклары да күзәтелә. Кәгазьдә керәшеннәр саналганнар өчен дә бу хәлләрнең үз кыенлыклары була, рәсми документ кирәк булганда авылдагы мәчеттә түгел, ә бик еракта гы чиркәүдә теркәлгән керәшеннәр туу, никахлашу турындагы документларын каян алырга да белмиләр. Беренчедән, еш кына үзләрен кайда теркәүдән бихәбәр булсалар, икенчедән үзләренә алардан башка гына кушылган рус исемнәрен алар, гадәттә, белмәгәннәр дә. Ә кайбер керәшеннәр, бигрәк тә балалар тугач, бөтенләй дә теркәлми калырга мөмкин, аларны чиркәү

[3] История и культура татар-кряшен (XVI–XX вв.). – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – С. 225–227.

документларында да табып булмый, мәчет метрика язмаларында да була алмыйлар. Хәзерге вакытта нәсел тарихын барлаганда да, бу ситуациядә булган татарларның нәсел шәҗәрәсенең җеп очлары югалуның бу бер сәбәбе дә.

Бу сәясәт нигезендә керәшеннәрнең саны бермә-бер артса да, властьлар сыйфат ягыннан уңышка ирешә алмыйлар. «Яңа керәшен» аталганнар иң тотрыксызы була. Җае чыкканда исламга кайту ягын гына караган бу төркем төрле башкүтәрүләргә китерә, властьлар өчен алар зур проблемага әйләнә башлый. «Яңа керәшен» дип аталганнар исламдан киткән очракта да христиан булып җитешмәгәннәр. Аларга христиан руханиларының тел аермалыгы булу сәбәпле, тиешле игътибары булмый, кайберләре үз гомерләрендә дә бер христиан рухание күрмиләр, яисә христиан рухание акча бәрабәренә күп нәрсәне күрмәмешкә салышкан. Икенче яктан керәшен саналганнарның мөселман татарлар белән туганлыгы, якынлыгы, күршеләр булып яшәүләре, хәтта имамнарның рухи хезмәте дә аларның тәмам христианлашуына ирек бирми[4].

Яңадан үз диннәренә кайту, иман өчен көрәшү башлана. Император Александр I вакытында – 1802 елда Түбән Новгород Епархиясендә аерым очраклар күренсә, 1803 елдан башлап кире үз диненә кайту өчен көрәш Казан Епархиясе карамагында булганнарга да килеп җитә. 1827 елда үз диненә кайту күренеше күзәтелә башлый, бер ел эчендә 138 авыл христианлыктан чыга, бу хәл 1870 нче елларга шулай дәвам итә. 1850–1860 еллар үз диненә кайтуның иң көчле дулкыны булган вакытлар. Халык арасында «үз динеңә кайтырга рөхсәт бар икән», дигән хәбәр таралу шундый зур дулкыннар тудыра[5].

Тәтеш өязендә керәшеннәр яшәгән бер генә авыл да тулысынча керәшен булмый, авылның бер өлеше генә керәшен саналган. Кире үз диннәренә кайту башлангач, 1827–1911 еллар аралыгында Тәтеш өязенең 74 авылындагы «яңа керәшеннәр» үз диненә кайтуга ирешә. Болар Атабай, Әҗем, Алабирде, Әлки, Әлмәндәр, Апас, Аюкүдергән, Байкүл, Байморза, Бәйрәш, Бик авылы, Аксу, Олы Әтрәч, Олы Бакырчы, Олы Болгаер, Олы Бортас, Олы Каяри,Олы Күккүз, Болын-Балыкчы, Сәүтек, Бортас, Үгез Куагы, Дәүләки, Дәвеш, Идрәс Тенки, Избахты, Ишим, Казый, Ташкичү, Камыгино, Карабай, Караборнаш, Кара ил, Каратолк, Карамалы, Суык Су, Келәш, Кормаш, Коштаулы, Кыртан, Лашчы, Мазиково, Кече Әтрәч, Кече Бакырчы, Кече Болгаер, Кече Күккүз, Мәмәтхуҗа, Морзалар, Яңа Күлкәш (хәзерге Буа районы Кыр-Тәүгелде авылы), Яңа Чәчкап, Кыр Буасы, Иске Энәле, Иске Кармалы, Иске Күлкәш (Апас районы Тәүгелде авылы), Иске Казиле, Танай Турай, Бишелан, Тутай, Ураз-

[4] Крещенные татары Казанской губернии: этнографический очерк /[соч.] Н. Одигитриевского. Издание второе. – М.: Печатня А. И. Снегиревой, 1895. – М.: Печатня А. И. Снегиревой, 1895. – С. 16–17.

[5] Шунда ук. – С. 18–19.

лы, Үти, Чепбаш, Икенче һәм Өченче Чиремшән, Бәбки, Черки Ишмәк, Чүл, Чирү-Бураш, Шәмбалыкчы, Йомралы, Ясаклы Барыш авыллары[6].

Көчләп чукындырылган халык документта христиан дип саналып йөрсә дә, керәшеннәрнең мөселманнарга караганда нинди дер өстенлекләре, ташламалары булса да, алар җае чыккан саен кире дән үз диннәренә кайту өчен мөмкин булган бар юлларны да файдаланырга тырышалар. Бигрәк тә янгын куркынычсызлыгы өчен дип кертелгән таләпләр чукындырудан болай да өркеп торган мөселманнарга тагын да курку гына өсти. Мәчетнең ишеген чиркәү ишеге кебек тышкы якка ачыла торган итеп ясау таләбе «мәчетләрне чиркәү итәчәкләр, манарасына чаң эләчәкләр, икона куячаклар», икән дигән имеш-мимешләр халыкны куркуга сала. Чистай өязендә башланган халык ризасызлыклары, үз диненә кайтырга рөхсәт сорап җибәрелгән үтенечләр турындагы хәбәрләр Тәтеш өязенә дә килеп җитә. Тәтеш өязе авыллары керәшеннәре дә үз үтенечләрен яза башлыйлар. Бер Чистай татары «без үтенеч биргән идек, әмма рөхсәт булмады, үтенечне 1866 ел кергәнче биреп өлгерергә кирәк, аннан соң рөхсәт булмый икән», дип сөйли. Бу сүз таралгач, Тәтеш өязе авыллары керәшеннәре тамгалар җыя башлыйлар, әмма үзләре тамга салучыларны җәза көтү ихтималыннан да куркалар. Чистай өязенең Тубылгытау авылы крестьяннарының үтенеченә уңай җавап килмәгәнне ишеткән Тәтеш өязенең Өч Балтай авылы керәшеннәре үтенеч бирүдән тукталып калалар. Олы һәм Кече Әтрәч керәшеннәре мондый үтенечне 1865 елның җәендә үк бирәләр, прошение өчен халыктан 20 шәр тиен акча җыялар[7].

Әтрәч авылында (Тәтеш районы) XIX–XX йөзләрдә керәшен дигән катлам авыл халкының якынча 15%ын тәшкил иткән (688 кешенең 97 се – керәшен)[8]. 1908 елда Д.А. Корсаков материаллары буенча Иске Әтрәчтә (Олы Әтрәч) ясаклылар 101 кеше дип бирелсә, авылның 90 кешесе керәшен буларак языла. Кече Әтрәч буенча (документларда исеме Мертюбяк) 84 дәүләт крестьянына бары тик 9 керәшен генә күрсәтелә. Күрше Аллабирде авылында 136 ясаклы һәм 36 керәшен татары яшәгән[9]. Саннарга караганда чукындыру сәясәте борынгы Болгар каберлекләре булган урында башка тирә-як авылларга караганда да көчлерәк алып барылган булып чыга.

Халык арасындагы ризасызлык һәм буталышларны теләсә нинди вакыйга барлыкка китерә алган. Мисал өчен, Тәтеш өязе Чирмешән авылында (Апас районы) 1878 елның 13 февралендә Халык мәгариф министрлыгы тарафын-

---

[6] Исхаков Р. Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (Последняя треть XVIII – начало XX в.). – Казань: Татар.кн.изд-во, 2011. – С. 218–219.

[7] Сәлахова Э. К. Әтрәч авылы тарихы (Әтрәч авылының XIX–XX йөз башы тарихыннан кайбер сәхифәләр // Безнең мирас. – 2017. – № 4. – Б. 26–30.

[8] Сәлахова Э. К. Әтрәч керәшеннәренең ислам өчен көрәше // Безнең мирас. 2020. – № 12. – Б. 60–64.

[9] Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в. /под ред. Д. А. Корсакова. – Казань: Типо-лит Императорского ун-та, 1908. – С. 328.

нан мөселман балаларына да рус теле буенча белем бирә башлау халык арасында нык ризасызлык тудыра. Бу хәбәр Казан губернаторы Н. Я. Скарятинга да мәгълүм була. Халык мәктәп эшчәнлеген, әлбәттә чукындыруның бер ысулы итеп кабул иткән. Халыкның ризасызлык хәрәкәте бары тик Чирмешән авылы белән генә чикләнеп калмыйча, тирә-як авылларга да тарала. Ялган хәбәрне махсус таратуда гаепләнеп, Болгаер авылында (Апас районы) Казан мещаны Хөсәен Халит улы Әҗемев һәм Мамадыш өязе Түбән Симет (Саба районы) Гыйззәтулла Ибәтуллин 1878 елның 28 нче декабрендә кулга алыналар[10].

Халык хакимиянең күп гамәлләренә шикләнеп карый башлый, бер җирдә башланган канәгатьсезлек хакында икенче төбәккә дә хәбәр таралып өлгерә. Тәтеш өязенең Каратун авылындагы базарда да 1860 елларда төп сөйләшү булып, киредән исламга кайту мөмкинлеге хакында, көрәш турында бара. «Патша исламга кайтырга рөхсәт биргән икән, бу хакта газетада да язганнар», дип хәбәр таратучылар була. Бик тиз арада губерна күләменә таралган бу хәбәр халык арасында буталышлар китереп чыгара, керәшен татарлары үз исемнәрен теркәп властьларга мөрәҗәгатьләр, хатлар яудыра башлыйлар.

Тәтеш өязе керәшеннәренең күтәрелешенә Чистай өязе керәшеннәренең мөселманлыкка кайту өчен көрәшләре үрнәк булган, тәтешлеләр чистайлыларга карап эш итәләр. Чистай өязе керәшеннәреннән булган Гали исемле кеше Тәтеш өязе авыллары буйлап йөреп «керәшеннәргә мәчетләргә йөрергә, мәчетләр төзәргә рөхсәт бар» дигән хәбәр тарата, мөселманлыкка кайту өчен үтенечләр язарга, христиан диненнән азат булу өчен көрәшергә чакырып йөри[11].

Һәр төбәктә халык күтәрелешен туплаучы, әйдәп баручы кешеләр була. Тәтеш өязендә шундый кешеләрдән, иң атаклысы, Танай Турай авылыннан Габдерәфик Мөхәммәтев. Аның сөйләве буенча, «1854 елда шундый закон чыккан икән, ул закон буенча кеше нинди дин тели – шуны тота ала». Бу сүзләре белән ул Тәтеш өязенең бик күп авыллары керәшеннәрен кузгалтып җибәрә, аның тәэсире белән үтенечләр яза башлыйлар, шул ук вакытта үтенечкә тамгаларын куйсалар да, халык бу гамәлләре өчен эзәрлекләнүдән курка. Габдерәфик Мөхәммәтев бер керәшен вафат булганнан соң аны мөселманча җирләргә әмер итә. Вафат булганнарны, гомумән, соңгы юлга мөселман гадәтләре буенча озатырга тырышканнар, әлбәттә инде бу эшләрдә муллалар катнашмаган, алар властьлардан курыкканннар. Халык бар җаваплыкны үз өстенә алып, үзе башкарып чыккан.

Габдерәфик Мөхәммәтев аксакалларны җыеп барып христиан руханиена «башка керәшен татарлары янына килеп йөрмәскә, аларны чукындырмаска»,

---

[10] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 379.

[11] РГИА, 821 ф., 8 тасв., 759 эш, 1 б. кгз.

дип әмер биреп кайтуга җөрьәт итә. Ул берничә иске керәшен татарының исламга кайту мәшәкатьләре белән Казанга килгәнен ишетеп, тәрҗемәче Дәүләткильдиевны алып, Казанда Хәсән Гафуров өенә бара. Ул кергәндә татарча киенгән 9 кеше өстәл тирәли утырып нидер язып утыра торган булганнар. Габдерәфик Мөхәммәтев (фамилиясе кайбер документларда Әлмөхәммәтев дип күрсәтелә) шушы җыенда язылган үтенеч-таләп кәгазен Тәтеш өязе исправнигына тапшыра[12].

Керәшеннәргә исламга кайту көрәшендә актив катнашкан, аларны әйдәгән, хәтта керәшен саналганнар арасында мулла булып торган Икенче Чирмешән авылы кешесе Мөхәммәдша Зимутдинов үзенең ир туганнары белән, шул ук авылдан Габдүш Госманов, Хамидулла Габдерәхимов, Бәбки авылыннан Фәтхулла Абдуллаевлар кулга алыналар һәм аларны авылларыннан куырга дигән карар чыгарыла[13]. Шулай ук бу хәрәкәтне җитәкләүче билгеле шәхесләрдән, Ташкичү кешесе Аит Сәмитев, Икенче Чирмешәннән Шаммас Шәмсетдинев, Олы Әтрәчтән Яуметдин Юнысов һ.б. булган.

Керәшеннәрнең күпләп исламга кайту хәрәкәте башлангач, Ефим Малов Тау ягына, шул исәптән Тәтеш өязенә, бу күренешне урынга барып карау, халыкны күзәтү, алар белән сөйләшү өчен авыллар буйлап сәяхәткә китә. Зөя өязе авыллары Мулла иле, Үтәш, Әҗеле, Олы Кошман, Бишево авылларыннан үтеп, Түбән Биябаш, Ябалак, Дәүләки, Югары Балтай, Шәмәк, Коллар авылы аша үтә. Ташкичүдә туктала, аннан Тимәш, Әлки, Исәк, Сориле, Начар-Үби, Татар Согыты, Чуаш Согыты, Чепкас, Торын (хәзерге Чувашия республикасы җирләре) авылларына барып, җәмгыятьнең халәтен күзәтә, монда ул күпләп керәшеннәрнең исламга кайтуына үзе дә шаһид була. Аннан Әлки, Ташкичү аша үтеп, 1866 елның 2 нче гыйнварында, яңадан Түбән Биябашка килә, Кырлангы, Морзалар иле, Ябалак аша үтеп, «исламга кайту мәсьәләләрен еш куерта торган» Каратун базарына да сугылып чыга, Кара-борнаш, Кошта авылы, Килдураз, Лашчы, Өчмунча, Казма, Черкен, Наратбаш авыллары аша узып, 12 нче гыйнварда Шәмбалыхчыга килә һәм шуннан Казанга китә. Керәшен саналучылар өязнең төрле төбәгендә яшәгәнлектән, аларны җыеп аңлату, «керәшенлектән китәргә бернинди рөхсәт булмаганлыгын» җиткерү өчен өяздә дүрт үзәк билгеләнә. Алар: Олы Әтрәч, Болгаер, Икенче Чирмешән һәм Дәүләки авыллары[14].

Керәшен итеп язылганнар беренче чорда «патшага гариза» язып үз хокукларын белдерергә тырышсалар, тора-бара власть аларга бернинди дә дин иреге бирергә җыенмаганлыкны аңлап, конкрет эшләргә керешә башлыйлар. Мисал өчен, керәшенлектән исламга кайтуда иң актив авылларның берсе –

[12] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 234–235.

[13] РДТА, 821 ф., 8 тасв., 759 эш, 129. кгз.

[14] Шунда ук.

Икенче Чирмешәндә 1880 елның 2 нче ноябрендә Корбан бәйрәме вакытында йөзләп керәшен татары мәчеткә килеп кереп Гает намазында катнашалар һәм шуннан соң даими рәвештә мәчеткә йөри башлыйлар. Әлбәттә инде икенче мәхәллә авыл имамы Мөхәммәдсафа Биккенин бу хакта властьларга хәбәр итә. Ул «бервакытта да бу хәлнең болай булганы юк иде, быел алар мәчеткә килеп керделәр», мин бу очракта нишләргә тиеш дигән кебек сүзләр яза. Мулла әйтүе буенча, намазны өзәргә, сөйләшергә ярамый, ә керәшеннәр намаз бетәр алдыннан мәчеттән чыгып та китәләр, ул алар белән сөйләшеп тә өлгерә алмый калам, дип белдерә. Әлбәттә инде мулланың хакимият органнарына язган бу хатында формальлек сизелә, ул керәшен саналганнарның мәчеткә килеп Гает намазында катнашуларына борчылмый, бары шатлана гына. Шул ук вакытта ул үзенең куркынычсызлыгы өчен хакимияткә бу хакта хәбәр итми дә булдыра алмый. Мәчеткә кереп Гает намазын укучылар арасында авыл старостасы, шулай ук керәшен булып язылган, Җәләлетдин Әминев тә була, ул да халыкка бернинди каршылык күрсәтми, бу авылдагы 110 керәшеннең мәчеткә йөрү-йөрмәвеннән хәбәрдар түгеллеге һәм үзенең алар арасында булмавын да белдерә, әлбәттә инде ул да күңеле белән исламга кайтырга омтылса да, хакимият кешесе буларак бу теләген ачыктан-ачык әйтә алмый. Бу авылның керәшен итеп язылган кешеләре үзләренең рус исемнәрен белмиләр, ислам дине таләп иткән бар гамәлләрне дә гомер-гомергә башкарып килгәннәр. Шушы вакыйгага охшаган күренеш Әтрәч авылында (Тәтеш районы) булган. 1876 елны Әтрәч керәшеннәре Корбан гаете көнне мәчеткә килеп мөселманнар белән беррәттән Гает намазын укыйлар. Авыл старостасы шунда булуына карамастан, берни дәшмәгән булса да, авыл мулласы Мөхәммәдсадыйк хәзрәт өстеннән шикаять итүче табыла. Бер авылда бердәм булып яшәгән, әмма сәясәт аркасында ике тарафка куелган халык һәрвакыт бер-берсен саклап, яклап килгән. Бу очракта да керәшеннәр үзләрен мәчеткә килмәгән, ә үз эшләре белән мәчет яныннан узып барган кебек күрсәтәләр, берсе, мин авыру абыемның хәлен белеп кайтып бара идем, ә икенчесе мин зиратка бара идем, дип белдерә. Шулай итеп, мулланы гаепләүдән саклап калалар[15].

1866 елның декабрендә Тәтеш өязе Бәбки авылының крестьяннары: Бикмөхәммәт Миниев, Ишми Якупов, Гайнулла, Хайбулла, Фәтхулла Абдулловлар, Мөхәммәт, Рәхмәтулла Мөхитовлар, Минкам Мохтаров, Фәйзулла Вәлитовлар җирле христиан руханиларының җәберләүләреннән саклауны сорап жандармерия җитәкчесе князь В. А. Долгоруковка мөрәҗәгать итәләр[16]. Алар Тәтеш өязе Фролово рухание Беляев безне христиан гадәтләрен үтәүдән баш тартуда гаепли дип зарланалар. Казаннан килгән тикшерүче чиновник та

[15] Салахова Э. К. Судьба крещенных татар деревень Атряси и Алабердино // Кряшенское историческое обозрение. – 2017. – № 1. – С. 120–158.

[16] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 242.

крестьяннарны властьларга каршы торуда гаепләргә тырыша. Шул ук вакытта авыл крестьяннары мондый хәл килеп чыгуда рухани Беляевның сигез ел буена да авылга килеп карамавын, аларның христиан иконлекләрен искә дә төшермәвен, ә бары үз белдеге белән авыл кешеләренә христиан исемнәре генә язып чыгуга ризасызлыкларын белдерәләр[17].

Тау ягында исламга кире кайту хәрәкәтенең зурлыгы, аның көчлелеге 1867–1868 елларда Казан губернасыннан дин өчен, исламга кайту өчен көрәшкән лидерларны, мулла, имамнарны Себер ягына сөрә башлагач күренә. Тәфкил Вафинның «Мәкрүһләр» исемле мәкаләсе 2008–2009 елларда «Казан утлары» журналында, аерым китап итеп тә бу авыр еллар вакыйгалары сурәтләнде[18]. Т. Вафин язуы буенча, 1867–1868 елларда Казан губернасыннан Турухан губернасына 45–47 кеше сөреләә. Бу кешеләр, Казан губернасының төрле өязеннән булган, алар арасында Тау ягы – Зөя, Тәтеш, Чуел (Цивиль) өязенә караган хәзерге Апас, Кайбыч, Яшел Үзән, Тәтеш, Кама Тамагы районнары авыллар имамнары, крестьяннары шактый. Халыкны «котыртуда», чукындырудан качып, Төркиягә китәргә өндәгән кешеләрдән, Сембер губернасы Сембер өязенең Зур Чынлы авылының Айзатулла Ибәтуллин һәм Маклауш авылының Сафатдин Мәрдиев, Казан губернасының Әлмәт авылы кешесе Гатаулла Нигъмәтуллин[19] да, Апас аша Чирмешән авылына килгән Пәрәү ишаны Габделҗәббар хәзрәт тә билгеле[20]. 1869 елда Сембер губернаторы В. И. Чарыков «керәшеннәрне котыртучы» буларак Буа өязе Боерган авылы кешесе Нигъмәтулла Йосыповны (керәшенлектәге исеме – Родион Осипов) да Туруханга сөрүне сорый, аңа кадәр инде ул кулга алынган була[21].

Тау ягындагы «керәшеннәрнең күпләп исламга кайту» күренешенә Чистай өязендә башланган хәрәкәт йогынты ясый, анда ул иртәрәк башлана һәм масштаблырак бара. Тау ягы халкына Чистай ягы керәшеннәренең тәҗрибәсе нык булыша. Патшага үтенечләрне дә алар үрнәгендә бирәләр, берберсенә йөреп халык белән аралашалар. Тау ягында да халыкны үз артыннан ияртә алырлык атаклы лидерлар, авторитетлар булган.

Әлбәттә бу хәрәкәтнең «иң куркыныч лидерлары» булып Габделлатыйф Алкин исәпләнелә, аның якын һәм көчле көрәштәшләре итеп, Зөя өязе Азбаба авылы кешеләре – Антон Иванов, Николай Никитин, Иван Петров, Янгильде

[17] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 243.

[18] Вафин Т. Отпавшие, или насильственное крещение татар. – Казань, 2011. – 158 б.

[19] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 214–215.

[20] Вафин Т. Отпавшие, или насильственное крещение татар. – Казань, 2011. – С. 171.

[21] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 278.

авылыннан Василий Иванов күрсәтелә[22]. Рәсми документта алар керәшенлектәге христиан исемнәре белән бирелгәннәр.

Габделлатыйф Алкин (1805 елда туган, вафат булу елы төгәл билгеле түгел)[23]. Ул хәзерге Кайбыч районына керә торган Иске Чәчкаб авылы кешесе, атаклы нәсел вәкиле. Аның уллары да татар рухи тормышында зур роль уйнаган кешеләр. Олы улы Сөнгатулла (1846 елгы) Иске Чәчкаб авылында мулла булып торган, оныгы Нургали (1872 елгы) Каюм Насыйриның туган авылы Кече Шырданда 1908 елларда имамлык иткән[24]. Сибгатулла улы да авылда мәчет төзегәндә килеп чыккан авырлыкларны үз җилкәсенә алган кеше.

Жандармия документларында Чәчкаб ишаны Габделлатыйф Алкин керәшен татарларын православиядән ваз кичтерүдә иң актив кеше булуы, аның авторитеты һәм тәэсире Зөя, Тәтеш һәм Чар өязе авылларында көчле булуы хакында әйтелә[25]. «Имам Абдуллатиф Алкин, по характеристике губернского донесения «деятельный совратитель крещенных татар из православия в магометанство», крупный татарский кулак через своих многочисленных агентов распространяющий «нелепые слухи и грозные воззвания»[26], дип характерлана.

1860 елларда Тәтеш өязе мөхтәсибе Таҗетдин Шамбас улы Мәҗитев Эчке эшләр министрлыгына Сембер губернасы Буа өязенең кайбер мөселманнары ислам диненә тугры булмаган гадәтләр буенча гамәл кылалар, алар бу эшләренә Тәтеш өязе мөселманнарын да тарталар дип хат җиткерә. Алкинның Чистай өязенә барып йөрүен, ниндидер «изге су» алып кайтуын, аннан кайтып, Тау ягы авыллары буйлап йөрүен яза. Керәшен балаларына мөселманча исем кушарга җөрьәт итә дигән гаебе күрсәтелә. Тикшерү эше барышында, төрле як фикерен сорашканнан соң, аңлашылганча, халык аны яклап кала. Бу эшкә бай татарлар катнашкан булырга тиеш, чөнки Мәҗитевнең үзен гаепләүләр башлана, аның Сәйдәшев һәм Сәгыйтевкә начар сүзләр әйтүе, аларны кыйнавы, гомумән, аның начар холкы хакында дәлилләр китерелә. Мәҗитевкә каршы буларак, аның Тәтештә тукталган Одесса хәрби музыкантларын Тәтеш мәчетенә чакырып музыка уйнатканын күрсәтәләр[27]. Бу инде мөселманнарда ризасызлык уята.

Г. Алкинның керәшеннәрне исламга кайтарудагы эшчәнлегенең даны тирә-якка тарала. Аның белән Казан губернасының башка өяз имамнары да

[22] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. 246.

[23] ТР ДА, 3 ф., 2 тасв., 519 эш.

[24] Галимов К. Эзле Чәчкаб. – Казан, 2004. – Б. 122.

[25] РДТА, 821 ф., 8 тасв., 759 эш.

[26] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х годов XIX в. Часть I. – М.: Изд-во АН СССР, 1936. – С. LI.

[27] РГИА, 821 ф., 8 тасв., 995 эш.

элемтәдә торган, аңа карап эш иткәннәр. 1867 елның 6 маенда Казан губернаторы Н. Я. Скарятин Эчке эшләр министры П. А. Валуевка җибәргән хатында «керәшенлектән чыгарга котыртучыларны» Туруханх краена җибәрүне сорый. Ул бу документа Чәчкаб ишаны Габделлатыйф Алкинны Тәтеш, Зөя, Чар өязләрендә «халыкны котыртучы эшлекле кеше» дип атый. Алкин бу максаты өчен һәр авылда диярлек үз агентын тота, диелә. Гади крестьян гына булып саналса да, зур акчаларга ия, үз хисабына Төрек солтанына ике ышанычлы кеше җибәреп, барлык Русия татарларын үз канаты астына алуны үтенә, дип гаепли. 1871 нче елның 26 нче апрелендә Алкин эшчәнлеге буенча император Александр II Казаннан аңлатма сората. Губернатор исә үз җавабында аның халык арасында абруйлы булуын, шуңа күрә, аны Казан губернасына кайтарырга ярамаганлыгын хәбәр итә. Керәшеннәр арасында коткы тарату һәм аларны күтәрүдә, башка авылларда да «исламга кайту хәрәкәтенең» җитәкчеләрен булдыруда да аның зур роле була. Императорга хат яза, «исламга кайту» эшен өчен халык арасында акча җыя. 1867 елда Г. Алкин Җангилде һәм Чүкри Алан керәшен татарларыннан 40 тиен, Салтыган авылы мулласы Таҗетдин Мөхәммәдьяров, керәшен татарлары Степан Иванов, Алексей Петров, Семен Иванов ярдәме белән керәшеннәрдән 30 ар сум акча җыйган.

Габделлатыйф Алкинның 1865–1867 еллар арасындагы эшчәнлеге нәтиҗәсе булып, 1721 керәшен христиан диненнән читләшә, әлбәттә инде мондый зур сан, керәшеннәрнең санын болай зур югалту Казан губернаторын да битараф калдыра алмый. Лидер Алкинны губерна буйлап эзләүләр башлана. Бу хәлдән соң Алкин өстенә әләкләр дә җитәрлек ява, аның белән бергә хәрәкәт иткән кайбер муллалар эзәрлекләүләр башланудан куркып калалар. Шундый бер әләк хатында «…керәшеннәрне яңадан мөселманлыкка кайтуга әйдәүче Кошман волостендагы Чәчкаб авылының моннан 30 еллар элек азанчысы булган Габделлатыйф булуы беленде, расланды. Аның тәгълиматы гади халыкка гына түгел, муллаларга да бик көчле тәэсир итә. Нигездә ул, Латыйф, сектант – мөселман дине белән христиан динен берләштереп, халыкларга яңа тәгълимат тарата һәм урындагы полициядә берничә мәртәбә булса да, ничектер котылып кала. Үзенең көрәштәшләрен арттыра», дип языла. Алкинның көрәштәшләре, ярдәмчеләре халыкны котыртуда, киредән исламга кайтуга каршылык күрсәтелсә, Төрек солтанына илче җибәрү ихтималында гаепләнеләләр. Казан губернаторы шымчылары императорга һәм төрек солтанына хат язу, киңәшләшү вакытында тугыз кешедән торган төркемне кулга ала. Бу төркемнең башлыклары Алкин, Гыйззәтулла Абдюшев, Галим Сәмигуллин да кулга алыналар. Алар арасында Төркиядән килгән сәүдәгәр Ногман Кушаев та була, соңрак ул гаепсез дип табылып, азат ителә.

Алкин хакында мәгълүмат җыюлар башлана. Архив документларыннан күренгәнчә, шул төбәкнең татарларыннан сораулар алынган, аның хәрәкәт юнәлеше ачыкланган, әмма гади халык аны сатмый. Хакимият органнары

әгәр Алкин кулга алынса, авылдашлары зур гауга куптару ихтималыннан куркалар. 1867 нче елның 30 нчы апрелендә Алкинны икенче стан приставы аша Зөя өязенә чакыртып алалар һәм Зөя төрмәсенә ябып куялар. Халык арасында коткы таратучы аерым кешеләрне берәмләп кулга алулар инде башланган була. 1867 нче елның 28 нче гыйнварында 47 мулладан торган төркемне Туруханга сөргенгә сөрәләр, бу хәлләрдән соң, Г. Алкин туган авылына кайтмыйча, Спас, Лаеш, Чистай якларында йөри, бары тик язга гына Тау ягына кайтып төшә дә, кулга да алына. Губернаторның 1867 нче ел 4 нче май боерыгында «христиан диненнән мөселманлыкка кайтаруда гаепле ишан Габделлатыйф Алкинны халык арасында хурга төшереп, икенче телен ачмаслык итеп, керәшеннәрнең каршылыкларын тәмам бетереп, зур җыен үткәргәннән соң, Турухан ягына олактыру өчен Казанга озатыгыз!», диелә. Аның гамәлләре җәзасыз кала алмаганны һәм башкаларга да «сабак» булсын өчен тирә-як авылларының муллаларын җыеп алар алдына богауланган Габделлатыйфны хурлыклы рәвештә халык арасыннан уздыралар. Җыелган халык хозурында полиция башлыгы, аның ярдәмчесе, төрмә сакчысы Алкинның Себергә сөреләчәге, әгәр дә керәшенлектән кайту шул рәвештә дәвам итсә, аларны да шул рәвешле Турухан якларына олактырачакларын җиткерәләр. 1867 нче елның 6 нчы май хаты белән боерыкның үтәлүен, халыкның шау-шусыз гына таралуын Казан губернаторына хәбәр итәләр.

Кызганычка каршы, Алкин белән бергә хәрәкәт иткән кайбер муллалар аның өстеннән әләкләр дә язалар, аның кулга алынуына шатланучылар да була, ә кайберләре соңгы көнгә кадәр аны сатмыйлар, хәтта кайбер рус кешеләре дә Алкинга сүз тидертмиләр. Мисал өчен, Колангы чиркәве побы Виктор Охотин керәшеннәрнең балаларын чукындырмауларын Алкинның эшчәнлеге белән бәйләмичә, ул керәшеннәрнең мөселманлыкка кайту сәбәбен аларның үз ата-бабалары диненә тугрыклы булулары белән аңлата[28].

Г. Алкинның ирешкән уңышлары, әлбәттә беренчедән, халык ярдәме белән булса, икенчедән, татар байларының аңа хәер-хаклыгы, кирәк чакта алар аны яклап та калганнар. Аңа Юнысовлар, Апанаевлар, Сәйдәшевләр ярдәм кулы сузалар. Себергә сөргенгә җибәргәндә дә ул, алар киңәше белән, чирлегә сабышып хастаханәгә эләгергә тиеш була, ә шул арада Императорга хат язып, Себергә китүдән саклап калырга да вәгъдә итәләр. Әмма Г. Алкин барыбер сөргенгә озатыла, аны Казан губернасына кайтарырга тырышалар, 1871 елда Казан губернаторына хат та җибәреп карыйлар. Бу хатка җавап буларак: «Габделлатыйф Алкин бик тырыш кеше. Православиедән мөселманлыкка кайтуда ул гына гаепле. Аның һәрбер өяздә, волостьта, авылда көрәштәшләре бар. Аны кайтару мөселманлыкка күчүне тагын да көчәйтәячәк һәм безнең христианлыкны ныгыту урыннардагы администрациянең генә эше икән дигән агитациягә юл ачу булыр иде», дигән җавап алына.

[28] Галимов К. Эзле Чәчкаб. – Казан, 2004. – Б. 119–121.

Тарихчы, язучы Фәүзия Бәйрәмова дин, иман өчен көрәшкән хәзрәтнең язмышы белән кызыксынып, тикшеренүләр, эзләнүләрне инде күптән башлый. 2011 елда ук Габделлатыйф хәзрәтнең туган якларында калган нәсел тамырларын барлап, аның дәвамчылары табып, алар белән очраша. Хәзерге Кайбыч районына карый торган Иске Чәчкаб авылында Рива абыйның улы Ленар 2007 елларда ук ерак бабасы Габделлатыйф хәзрәт язмышына ачыклык кертү өмете белән Красноярск төбәге архивына мөрәҗәгать итә. Аннан алынган җаваптан аңлашылганча, Габделлатыйф 1872 елда Енисейск губернасының Ялан волостеның Гәр дигән авылына китерелгән. Ни өчен хөкем ителгәне хакында архив документларында мәгълүматлар юк, була да алмый, чөнки аңа суд ясап та тормаганнар. Сөргенгә җибәрелгән Габделлатыйф хәзрәт олы яшьтә булса да, шунда татар хатынына өйләнә, чөнки гаиләлеләр «поселение»гә чыгарылган, 1881 елда «поселение»гә чыкканда инде хәзрәт 66 яшендә була. 2022 елда Ф. Бәйрәмева Туруханга сөрелгән муллаларның язмышы хакында архивта эзләнү материалларын бастырып чыгарды[29]. Кызганычка каршы, бу кешеләрнең язмышын ачыкларлык материаллар юк диярлек, сакланган архив материаллары да бик аз гына мәгълүмат бирә.

Сөрелгән имамнар арасында Апас районына караган Салтыган авылы мулласы Мөхәммәдьяров Таҗетдин хәзрәт тә була. Аңа мәчеттә намаз укырга рөхсәт иткәне, христиан диненә үз мөнәсәбәтен белдергән өчен яла ягыла. 1867 елны гает намазыннан соң кулга алалар, башкаларга да сабак булсын диптер инде, аны җәзалауны карау өчен тирә-як авыллары керәшеннәреннәрен дә китерәләр. Ф. Бәйрәмева Т. Вафин хезмәтләренә таянып, бу хәлне түбәндәгечә сурәтли: «Кул-аяклары богауланган Таҗетдин мулланы халык каршына өстерәп чыгаралар, ул чалмадан, уң кулында Коръән, сулында мәчет таягы була. Рус исправнигы аның кулыннан Коръәне белән таягын тартып ала, аларны чокырга томырырга омтыла, әмма халыкның урман кебек гүләвеннән, ярсуыннан куркып, аларны Таҗетдин хәзрәтнең хатынына бирә. Мәкрүһ татарларның башларыннан түбәтәйләрен йолкып җиргә бәрәләр, кайберләре куркудан түбәтәен үзе үк салып ташлый, чөнки ул мөселманлык билгесе була»[30].

Себергә сөрүләр 1867 елның язында башлана, җәй ае дәвамында бара. Татар тарихындагы бу трагик вакыйга әлегә кадәр галимнәр тарафыннан тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Иң беренче булып бу темага игътибар иткән кеше – ул халык тарихчысы Т. Вафин, чөнки аның бабасы хәзерге Апас районына карый торган Янгелде авылының Мөхәммәдсабит бине Шәрәфетдин Себергә 11 кешелек этап белән озатылган кеше. Аның олы хатыны дүрт баласы белән туган авылында кала, ә яшь хатыны авырлы көе ире артыннан

---

[29] Бәйрәмова Ф. Дин өчен сөрелгән татарлар // Мәдәни җомга. – 2022. – 18 февраль, 25 февраль.

[30] Шунда ук.

сөргенгә чыгып китә. Ирләре артыннан сөргенгә киткән Декабрист хатыннарының батырлыкларын тарих белсә дә, иман өчен сөрелгән ирләренә теләктәш итеп, алар артыннан җәяү билгесезлеккә чыгып киткән татар хатыннарының батырлыклары турында мәгълүматыбыз юк диярлек. Хатыннары килгән тоткыннар төрмәдән чыгарылып «поселение»га урнаштырылганнар, бу иреккә чыгу түгел, ә шул ук тоткын буларак гаилә белән яшәү, әмма анысы да тоткын өчен кечкенә генә җиңеллек. Бу тоткыннар беркайчан да киредән туган якларына да кайта алмаганнар, башка бернинди ирекләре дә булмаган.

Туруханга сөрелгән имамнарның нәсел дәвамчылары хакында бөтенләй мәгълүмат юк дисәк тә ялгыш булмас, бары тик китмичә, туган җирендә калган балаларыннан Таҗетдин Мөхәммәдьяров, Габделлатыйф Алкин дәвамчылары гына билгеле.

Кызганычка каршы, архив документларында да алар хакында мәгълүмат аз очрый. Чөнки халык күтәрелешеннән курыккан хөкүмәт аларны рәсми рәвештә суд белән хөкем итәргә курка, бары тик кечерәк төркемнәр белән суд ясамый гына Себергә сөреп барганнар. Икенчедән, булган документларда да алар еш кына, керәшен буларак, рус исемнәре белән аталганнар. Иман өчен сөргенгә сөрелгән татарлар тарихы аерым бер комплекслы өйрәнүне таләп итә. Кызганычка каршы, татар тарихының бу трагик сәхифәсе әле ачылмаган. Керәшен ителгән татарларның зур корбаннар биреп булса да, киредән исламга кайту хәрәкәте үзенчәлекле бер күренеш. Монда халыкның эчке халәте, көче, киләчәккә баглаган өметләренең ныклыгы чагыла.

Керәшеннәрнең ислам диненнән аерыла алмавы, керәшеннәргә исламның зур йогынтысы аркасында була. 200 ир-аты булган мәхәлләдә мәчет төзелгән, бөтен авылда да мәчет эшләп килгән, мәдрәсәләрдә укытканнар, имамнар вәзгазьләр сөйләгәннәр. Керәшен татарларына христиан дине руханиларының йогынтысы мөселман руханилары йогынтысыннан күпкә азрак булган. Шулай ук, тел аермалыгы – бу сәясәтне тоткарлаучы төп фактор. Христиан руханиларының үз эшләренә формаль каравы, ришвәт алып, үз вазыйфаларына салкын каравы да үз ролен уйнаган. Моннан кала руханиларның үз-үзләрен тотышлары, тормыш рәвеше халык арасында аларны авторитет итә алмаган: «... священник села Бишево Алексей Рождественский, как видно из клировой ведомости за 1864 г., был неоднократно штрафован за неодобрительное поведение и никаких инородных языков не знает, а между тем в приходе его состоит крещенных чуваш 237 душ обоего пола и татар 498 душ обоего пола, то на основании Высочайше утвержденных правил (пр. 1) о наставлении и утверждении новокрещенных в вере христианской, изложенных в Указе Святейшего Синода от 23 мая 1830 г. за № 4699, священника села Бишево Алексея Рождественского, как незнающего иностранных языков, и неоднократно штрафованного за неодобрительное поведение, ныне же удалить от прихода села Бишево с представлением, впрочем, права искать

себе места в таком приходе, где нет новокрещенных татар, чуваш и черемис и уклонившихся в раскол, о чем для объявления священнику Рождественскому предписать местному Благочинному Указом с тем, чтобы приход Бишевский опредь до определения нового священника, вместо Рождественского, был поручен ближайшему священнику. С прописанием рапорта священноцерковнослужителей села Бишева от лица Его Высокопреосвященства сообщить Г[осподину] начальнику Казанской губернии и просить о причине уклонения почти всех новокрещенных татар Бишевского прихода от провославия к магометанству... »[31].

Тау ягындагы чукындыру, иманнан яздыру хәрәкәте аерым тикшерү объекты буларак каралырга тиешле проблемаларның берсе, аның үз үзенчәлеге, үзенең игътибарга лаеклы вакыйгалары бар. Бу төбәк иман өчен көрәштә батырларча барган кешеләре, аларның трагик язмышлары белән тарихта үз урынын алган.

[31] РДТА, 821 ф., 8 тасв., 777 эш.

## § 2. Чуашларның исламга килүе

Тау ягында татарлар һәм чуашлар күп гасырлар дәвамында бер җирлектә, күршеләр булып гомер итәләр. Хәтта бер-берсенең тормыш рәвеше, гадәтләре, кайбер урыннарда тел үзенчәлекләрен, сүзләрне кабул итүләре күренә. Мәҗүсилекләрен озак вакыт саклап килгән чуашлар, татарлар белән янәшәдә яшәү аркасында, ислам гадәтләре белән танышып киләләр, әмма аларны көчләп исламга кертү дигән күренеш булмый. Шулай да, чуашлар арасыннан кайберләренең нәкъ шушы якынлык аркасында тора-бара татарлашып китү очраклары да бар. Хәтта православие динендә булганда да чуашларның «Бисмилла» әйтүен, матур итеп татарча сөйләшүен олырак буын әле дә хәтерли.

К. Насыйри Зөя өязендәге Шигали авылында тулысы белән мөселман булган чуашлар яшәгәнлеген яза, чукындыру сәясәте башлангач, авылның бер өлеше чукындырылган. Шул ук вакытта Тәтеш ягыннан килеп Чабаксар өязендәге Кармыш авылын нигезләгән Кармыш баба улларын мәҗүсилектәге чуаш кызларына өйләндерә[1]. К. Насыйриның бу мисалы да, чуашлар чукындырылганга кадәр татарлар белән бергәлектә, тыгыз тормышта яшәгәнлеген күрсәтә.

XIX гасыр ахырында 307 ир-ат, 311 хатын-кыз гомер иткән Тәтеш өязенең Избахтино дигән авылында татар мөселман исемнәре белән аталган чуашлар яшәгән. Көчләп чукындыру сәясәте узган дәвердә бу чуашлар чукындырыла, ягъни алар «яңа керәшеннәр» булып санала башлый. Киредән үз диннәренә кайту мөмкинлеге чыккач, 1865–1866 елларда, берничә гаилә исламга кайта, чиркәүгә йөрүдән туктый, өйләреннән иконаларны да ала, үзләренең татарча куелган исемнәрен кайтаралар. Туганнан бирле ислам гадәтләре белән яшәгән чуашлар хокук ягыннан киредән үз диннәренә кайткан бар керәшеннәргә хас булган авырлыклар белән очрашалар. Алар мөселман метрика кенәгәләренә теркәлә алмаган, балалары законсыз туган балалар булып исәпләнгән. 1897 елда алар 7 гаилә күршедәге Исәк авылының (Буа районы) Камалетдин Хәбибуллин җитәкчелек иткән мәчетенә теркәүгә рөхсәт сорап властьларга мөрәҗәгать итәләр. Бу вакытта 118 йорттан торган авылда 582 ир-ат яшәгән Исәк авылында ике мәчет эшләп торган. Алар мөрәҗәгатьләрендә үзләре туганнан бирле мөселман булсалар да, муллалары булмауга, бабаларын метрика дәфтәрләренә терки алмаганнарына зарланалар. Үзләренең мөселманча тормыш рәвеше алып баруларын, бабаларын белем алу өчен күрше Исәк авылы мәдрәсәсенә йөртүләрен язалар. Бу мөрәҗәгатькә кул куйган Вахит Илмәтев керәшен булганда Степан Васильев (48 яшь) исемен йөрткән, Габдулла Вахитов (65 яшь) чукындырылмаган чуаш, шуңа русча исеме юк, Калмәмәт Карманаев (Михаил Семенов) гаиләсе чукындырылган, ата-бабасы, үзе, хатыны 1865 елда киредән исламга кайта. Хәмидулла Калмәмәтев гаиләсе кешеләре дә мөселман исемнәре йөрткән, чукындырылгач

[1] Насыйри К. Избранные произведения. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1977. – С. 60–63.

Константин Михайлов исеме бирелгән, аннан 1865 елда киредән исламга кайткан. Сабит Илмәтевнең (Николай Васильев) гаиләсе дә 1865 елда христианлыктан китә, Халит Сабитов – чукындырылмаган чуаш, Сәмит Илмәтев (Осип Васильев) исламга кире кайткан чуаш кешесе[2].

Е. Малов та Тәтеш өязе авыллары буйлап йөргән вакытта Чепкас-Әлмәт авылындагы (Чүпрәле районы) керәшен чуашларның кайберләре мөселманнарның уразаларын тотулары хакында әйтә. Бер чуаш карты мөселманча китаплар укый, ә христиан руханиеның үгетләренә җавап кайтармый, дип яза. Татарча киенеп йөрүче бу чуаш картын ул «башы-аягы белән мөселманлыкка бирелгән», дип бәяли[3]. Бу авылда Шыгырдан бае (хәзерге Чуашстан) тарафыннан төзелгән мәчет эшләп килгән, шулай ук татар мәктәбе булган. Болар – барысы да бу авылда мөселманлыкның көчәюенә генә китерәчәк, дип борчыла Е. Малов.

Шулай ук Тәтеш өязенең Өч Балтай авылында да XVIII гасырда ук та, XIX гасырда да мөселманлашкан чуашлар булган, бу авылда керәшен татары да, мөселман чуаш та, керәшен чуаш та хәтта туганлык җепләре белән бәйләнештә торган[4].

1857–1858 елларда Шемурша авылының мәҗүси чуашлары көчләп чукындырыла башлагач, алар Казан губернасы буенча качып китә башлыйлар. Е. Малов аларның христиан булганчы мөселман булуга әзер торуларын яза, алар кыяфәтләре белән дә татарларга охшаган, ди ул[5]. Гасырлар буе татарлар белән күрше, бердәм булып яшәгән чуашларның тел ягыннан да, гадәт ягыннан да христианнарга караганда, татарларга якынлыгы зуррак, чуашларга ислам дине, аларның бу дин белән танышлыгы, аларның тормышында исламның роле күпкә тирәнрәк була.

Төбәкче Г. А. Николаев язуы буенча да, татар авыллары янындагы чуаш авылы кешеләрен тышкы кыяфәтләре ягыннан татар кешеләреннән бер караш белән аерып та булмый. Укытучы Михаил Максимов үзенең этнографик язмаларында чуашлар турында язганда алар тун, чапаннарын бер үк тегүчедән тектерүләре, шул ук татар бүреген киюләре хакында яза. Бәйрәм көннәрендә алар бәйрәм киеме буларак татар бишмәте кия торган булганнар. Күлмәкләре озын, әмма алар, татарлардан аермалы буларак, бары билбау бумаганнар, ир атлары озын чәч йөрткән.

Чуашларның ислам гадәтләрен кабул итеп, акрынлап татар составына кереп киткән очраклар булуын М. Госманов 1960 елларда Тау ягындагы археографик экспедиция күзәтүләреннән дә чыгып яза. Буа, Апас якларында

[2] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 5618 эш. 1–10 б кгз.

[3] Миссионерство среди мухаммедан и крещенных татар. Сборник статей кафедрального протоиерия Е. А. Малова. – Казань: Типо-литография Императорского Университета, 1892. – С.196.

[4] Шунда ук. – С. 196.

[5] Шунда ук. – С. 197.

йөргән вакытынында ул андагы кешеләр ак йөзле булсалар да, «европеид» дигән антропологик типка туры килеп бетмәгәннәренә игътибар итә: «яңак сөякләре чыгыбрак торган озынча йөздә, үзләренә генә характерлы ачык төсле күзләрдә, кабакларда «классик» мишәрләргә дә, «типик» Казан арты халкына да туры килеп җитмәгән сыйфатлар шактый»[6], дип яза. Авыл картларының «элек бу авылның бер очы чуашлар иде», яисә «белмим, аларда китап булыр микән, аларның бабалары чуаш иде», дип сөйләүләр бу хәлгә беркүпмедер ачыклык кертә. Кая китте соң ул чуашлар, дип сораганга – «Кая дип, үлеп беткәннәрдер, калганнары шушындадыр инде...»[7], дип елмаялар иде дию дә, татарлар белән чуашларның бергә гомер итеп, аралашып, чуашларның исламга килеп, татар составына кушылып китүенә бер ишарә. Бабаларының чуаш булулары хакында, гадәттә, белгертмәскә, ул хакта искә алмаска тырышалар, татар булу, исламга килү – алар өчен зур мәртәбә итеп кабул ителә. Әмма шул ук вакытта, М. Госманов аларның үз өйләрендә сакланган гарәп язулы татарча китапларны «Без үлгәч әрәм булмасыннар», дип галимнәргә кызганмый бирүләрен искәртә. Татарлардан китап алып китү шактый авыр, алар ата-бабадан килгән китапларны, галимнәр сораса да, читтән килгән кешеләргә бирергә ашыгып тормыйлар. Әмма ләкин, татарлашкан чуашларда китапның булуы, татар әсәрләренә хөрмәтләре, әлбәттә ихтирамга лаек. Бу – ике халыкның тыгыз мәдәни бәйләнеше һәм татарларның мәгърифәтчел хезмәтчәнлеге нәтиҗәсе.

Зөя өязе Акъегет авылының тирә-якка билгеле хәйрияче, мәгърифәтчесе, үзенең курыкмас нык характеры белән халык авторитетын яулап алган Заһидулла Шәфигуллин чуашларны да исламга якынайтуда гаять зур роль уйный. Тирә-якта бик күп мәчетләр салдырган, мәдрәсәләр ачтырган Заһидулла бай күпчелек халкы чуаш булган Байморза авылында үз акчасына мәчет салдыра. Гомумән, ул мәҗүсилектәге чуашлар арасында ислам пропагандасына күп көч куйган кеше. Тикшерүче дәүләт кешеләре тарафыннан бу гамәле өчен дә ул күзалдында тотылган кеше була, әмма Заһидулла байның авторитетына, аның куәтенә каршы чыгарлык, аңа бу гамәлләре өчен җәза бирерлек көч булмый[8].

Әлеге проблема шактый четерекле, дискуссия тудыра торган проблема. Шулай булса да, чуашларның татарга булган мөнәсәбәте, аларның озак гасырлар буе бер дәүләт кысаларында гомер кичерүе, күрше булып яшәве бу вакыйгаларның сәбәбе.Мондый хәлләрнең булуы табигый күренеш һәм бу процессны сәясәт белән бәйләп карарга кирәкми. Бер тирәлектә яшәгән халыклар арасында мәдәни багланышлар да, шул ук вакытта ассимиляция күренеше дә була. Тау ягы халкы тормышында бу чагыла, әлеге күренеш язма, этнографик, лингвистик чыганаклар һәм халык авыз иҗаты аша раслана.

---

[6] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1994. – Б. 78.

[7] Шунда ук. – Б. 78.

[8] ТР ДА, 102 ф., 148 тасв., 10 бүл., 149 эш. 2–13 б кгз.

## § 3. Халык санын алу вакыйгасы белән бәйле хәрәкәтләр

1896 елның 27 нче июнендә патша Николай II Указы белән Россиядә беренче тапкыр гомумхалык саны алу вакыты 1897 елның гыйнварына билгеләнә. Бу эшне гамәлгә кую өчен өязләр халык санын алу участокларына бүленә. Халык 30000 кешедән артса, яисә этник яктан төрле булса, аерым участоклар оешкан. Тәтеш өязе буенча шундый 6 участок, ә шәһәрдә бер участок булдырыла. Халык исәбен алучы буларак өязгә 111 кеше, шәһәр буенча 10 кеше билгеләнә. Участок белән җитәкчелек итүчеләр итеп төрле дәрәҗәдәге чиновниклар билгеләнгән, аларга ярдәмгә 2–3 урынбасар урыны бирелгән. Татар-мөселманнар яшәгән өлешләрдә татар булмаган рус телле чиновникларны халык исәбе алуга кую тискәре нәтиҗәләргә китерү ихтималы зур булганлыгын властьлар аңлый. Бу вакытта Казан губернасының 29,1 % халкын мөселманнар тәшкил иткән. Безнең өйрәнү җирлеге булган Тәтеш өязендә алар бар халыкның 13,39 %ын алып торганнар. Шунлыктан, халык санын алучылар турында да, халык санын алу кәгазьләре хакында да бу үзенчәлекне истә тотарга туры килә. Татар-мөселманнар яшәгән төбәккә татар телендә язылган кушымта кәгазьләре җибәрелә. Губерна күләмендә халык санын алу комиссиясенә татарлар да кертелә, әмма алар бары тик Казан шәһәре комиссияләрендә генә булалар. Алар – ахун Мөхәммәдйосыф Сәгыйтев, 2 нче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәдҗан Ибнияминович Галеев, Татар укытучылар мәктәбе инспекторы Ш. И. Әхмәрев. Казанда участок җитәкчелегендә дә татарларны күрергә була: 1 нче гильдия сәүдәгәр Сөләйман Мөхәммәдҗанович Аитов, Саитшаһи Әхмәд улы Алкин, Татар укытучылар мәктәбе мөгаллиме Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов. Ә өяз комиссияләрендә бер генә татар фамилиясен дә очратып булмый[1]. Әмма татар авылларына халык санын алу өчен татар кешеләрен билгеләү, я булмаса татар телен аңларлык кешеләрне кую кирәклегенә басым ясала, һич булмаса, халык санын алучы чиновникны мулла ияртеп йөрергә тиеш була. Муллалар да бу эштә ярдәмче булырга ашкынып тормаганнар, чөнки халыкның бу чарага карата мөнәсәбәтен белгән хәлдә, халыкның нәфрәтеннән куркып, башка төбәкләргә китеп барырга мәҗбүр булганнар[2]. Авыл халык мондый муллаларның өен яндырырга да, хәтта үзен үтерергә дә күп сорап тормаган. Рус армиясендә хезмәт иткән имамнар, теоретик яктан, халык санын алучы буларак хезмәт

---

[1] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 19–50.

[2] Загидуллин И. К. Участие мусульманских духовных лиц Казанской губернии в бойкотировании Первой Всеобщей переписи населения 1897 г. // Научный Татарстан. 2014. – № 3. – С.27–36.

куярга хокуклы булганнар. Мисал өчен, И. Заһидуллин 1904 елга өчен шундый 17 мулла булуы билгеле, ә чынлыкта исә аларның күбрәк тә булуы ихтимал, дип яза[3]. Халык санын алучы рус телен белергә, белемле һәм телдән әйтелгән мәгълүматны тиз тотып алып кәгазьгә теркәргә тиеш, әмма бу шартларга тулысынча туры килә торган муллалар юк дәрәҗәсендә булган.

Хакимият органнары бу эшкә бик сак карарга кирәклеген һәм шулай ук киеренкелек килеп чыгасын алдан ук чамалыйлар. Ничек кенә саклык чаралары күрергә тырышсалар да, бу кампания мөселман татарларында сагаю уята. Гасырлар буе чукындырудан куркып яшәгән татар кешесе һәрбер гамәлдә шушы куркынычны күрә. Әлбәттә, бу хәлгә ачыклык кертү, ниндидер авторитетлы фикер ишетү өчен гади авыл кешесе үзләренең имамнарына мөрәҗәгать итә, бергә җыелган урыннарда, базар, ярминкәләрдә фикерләшә, башкаларның сүзен тыңлый, алга таба ни гамәл кылырга кирәклеген уйлый. Халык өчен бу вакыйга иманнан яздыру максаты, чукындыру өчен исәп алыну итеп кабул итә. Иң куркыткан нәрсә – ул иманнан яздыру, мөселманнар һәр шикле нәрсәдә шуның төсмерләрен күргәннәр.

Халык санын алу кампаниясенә каршы көчле хәрәкәт Казан артында Арча шәһәре базарыннан башланса, Тау ягында 1897 елның гыйнвар ае башында ук Буа шәһәрендәге ярминкәдән кайтучылар бу эшкә зур каршылык күрсәтә башлыйлар[4]. Тау ягының тагын бер мөһим урыны – ул татарлар бик күп җыела торган Каратун базары. Бу каршылыкта базарларның хәлиткеч ролен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Базар, ярминкәләр һәрвакыт халыкны бергә җыеп, сөйләшеп, аралашып, карар кабул итә торган урыны булган. Аннан кайткан хәлле, маллырак кешеләрнең сүзе халык арасында үткән, санланган.

Халык санын алуга каршы көрәш төрле формада бара: аның берсе тыныч юл белән, прошенияләр язып, закон гаделлегенә ышаныч белдереп эшләнсә, икенче юлы инде физик көч кулланып күрсәтелгән каршылык, ягъни башкүтәрүләр, кыйнаулар һ.б. Казан губернасында халык санын алу вакыйгаларын тикшергән галим И. К. Заһидуллин санавы буенча Казан губернасындагы 10 өязнең мөселманнар яшәгән 230 авыл җәмгыяте прошения бирә. Шулар арасында активлык күрсәтүче өяләрдән, Тәтеш, Спас, Казан, Лаеш, Зөя, Чар өязе авыллары. Казан шәһәренә үз вәкилләрен җибәргән татар җәмгыятьләренең якынча 60 %ы хакимияткә буйсынмауларын ачыктан-ачык күрсәтәләр[5]. 1897 елгы халык санын алуга каршылык күрсәтүчеләр арасыннан, әлбәттә, Казан өязе аерылып торган, каршылык өяз буенча процентлар белән караганда,

---

[3] Загидуллин И. К. Участие мусульманских духовных лиц Казанской губернии в бойкотировании Первой Всеобщей переписи населения 1897 г. // Научный Татарстан. 2014. – № 3. – С.28.

[4] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 176–177.

[5] Шунда ук. – С. 184.

30,8 % татар авылларында уза, ә Тәтеш өязе Казан белән чагыштырганда үзен тыйнаграк тота, аларда бу күрсәткеч 6,9 % ны тәшкил итә[6].

Тәтеш өязендә бу елларда барган хәлләр Казан губернасының башка өязләреннән әллә ни аерылмый. Тәтеш өязе татар авыллары да бу хәбәрне җиңел генә кабул итмәгәннәр. Муллалар бу чараның ни өчен үткәрелүен, халык арасында күтәрелеш булмасын өчен, аңлатырга тиеш булалар, әмма халык санын алуның иң җаваплы вакытында – 1896 елның декабре – 1897 елның январь аенда Иске Барыш волостена (хәзерге Апас районы) кергән 11 авылның мулласы бу чарага катнашудан тыелып калалар, чөнки үзләре халыкның аларга ябырылуы, зыян салуыннан куркулары белән аңлаталар. Властьларга булышкан очракта, мәхәллә халкы аларны хыянәтче итеп санаган. Авылларда хәрбиләр күренгәч кенә, бары аларны озатып йөрергә ризалык кына бирәләр[7]. Болар: хәзерге Апас районына керә торган Олы Күкүздән – Гобәйдулла Хәбибуллин, Иске Барыштан – Сафиулла Фәтхуллин, Әҗемнән – Гыймадетдин Сәгъдетдинев, Казыево-Картападан – Ярулла Хәбибуллин, Иске Казыйдан – Һидиятулла Абдуллин, Әҗем-Күрлебаштан – Садретдин Габделҗәлилев, Балчыклыдан – Сөнгәтулла Фәтхуллиннар[8].

Халык санын алу башланганчы ук, бу хәбәрне ишетеп, үз кешеләрен татарның авторитетлы шәхесләре белән киңәшләшү өчен Казанга җибәргәннәр, ә алар үз чиратында, губернатордан бу гамәлнең максатын, асылын белешергә тиеш булалар. Тәтеш, Спас, Зөя, Лаеш, Казан, Мамадыш өязләреннән шул максат белән Казанга ышанычлы кешеләр җибәрелү шактый еш күзәтелә[9]. Әмма барган кешеләр күп очракта, кайтып халыкны тынычландыручылар түгел, ә киресенчә, бу хәлләргә каршы тору, ышанмау кирәклеген күрсәтүчеләр була. Мисал өчен, Тәтеш өязе Иске Барыш волосте Әҗем авылының (Апас районы) Габделхәким Габделгаффаров белән Галим Ибатуллин авылдашларыннан 18 сум акча җыеп Казанга барып кайталар, кайткач, халык санын алуга каршы торырга чакыралар. Бигрәк тә, элек солдат булган Гафаров халык сходлары җыя башлый. Х. Гафуров, шулай ук Казанга барып белешеп кайткан, Олы Күккүз авылы (Апас районы) кешесе Сабит Сәгыйтев белән тирә-як авылларны йөреп чыгалар. Алар Әлмәндәр, Иске Барыш (Апас районы), Каратал (Кама Тамагы) авылларында булып, 9 авыл исеменнән губернатор исеменә прошения бирүләрен, әмма ул игътибарсыз калдырылуын сөйлиләр. Алар сөйләве буенча, Казанда аларга бер җирбиләүче «фран-

---

[6] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 185.

[7] Загидуллин И. К. Участие мусульманских духовных лиц Казанской губернии в бойкотировании Первой Всеобщей переписи населения 1897 г. // Научный Татарстан. 2014. – № 3. – С.30.

[8] ТР ДА, 2 ф., 3 тасв., 2316 эш, 8 кгз.

[9] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 154–155.

цуз, немец, мөселман телендә» прошение язарга киңәш итә. Мөселман телендә дигәне, татар телендә булырга тиеш, анысын төрек консулына җиткерергә, ә Европа телләрендә язылганы аша мөселманнар беләнниләр булып ятканны Европа да беледерү өчен эшләнә. Бу эш өчен 25 сум акча кирәк булачак диләр. Волость күләмендә үткән судта да алар бу сүзләрен раслыйлар. Аларның бу планнарын тормышка ашыруга сәүдәгәр Гали Арсланов ярдәм итәргә риза булуы хакында сөйлиләр. Аларга Казанда консультация биргән җирбиләүче дә шул кеше булган булырга тиеш[10]. Беренче карашка, бу вакыйга буржуазия вәкилләре гади халык күтәрелешен үз максатларында кулланырга теләгәннәр кебек тоелса да, икенче яктан, дин, иманны саклауда бай катлам белән гади халыкка аерылу булмаган, ә халык уртак куркынычка каршы бердәм хәрәкәт иткән дигән фикер бәлки өстенлек аладыр. Мал белән халык бергә бердәм көч булганда уңышлар булганлыгын инде тарихтагы күп вакыйгалар раслап килә.

Тәтеш өязенең отставной солдаты Кәрим Мөхәммәдрәхимов бу вакыйгадан соң исламга карата дәүләт реформасы булу ихтималы турында жандармерия офицерына үз шөбһәләрен белдерә. Ул «Муллалар да православие руханилары кебек үк билгеле күләмдә акча ала башлаячаклар, аларга 4 дисәтинә җир бүлеп биреләчәк, ә мәчет янына 4 багана куеп чаң куячаклар. Татарлар да, руслар кебек үк балалары тугач исем куштырырга мәчеткә алып килә торган булачаклар»[11], дип сөйли. Татарларда мулла авторитетлы кеше саналганын, башкалар аның сүзен тыңлаганнарын, хөрмәт иткәннәрен исәпкә алсак, бу вакытта муллаларга карата да шик-шөбһә барлыкка килгәнен, аларга да ышанып бетмәгәнлекләре дә күренә.

1896 елның 19 нче декабрендә чыгарылган патша Указын халык беркатлы гына кабул итмәгәненә мисал булып, Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостена караган Кужак авылында (Буа районы) 1897 елның 11 нче гыйнварында үткән авыл җыены күрсәтә. Анда волость старшинасы Җамалетдин Мифтахетдинов һәм халык исәбен алучы А. Планкин үгетләвенә карамастан, хәтта алар патша Указын укып бирсәләр дә, халык аларга ышанырга теләми. Крестьян Сәлимҗан Бикмуллин «Патша Указы булса, кәгазьдә мөһере булыр иде, ә бу ниндидер жулик тарафыннан гына язылган булуы ихтимал», дип белдерә[12].

Тәтеш өязе Олы Яңа Сала волостена караган 9 авыл да халык санын алучыларны кертүдән баш тартканлыгы хакында полициягә 1897 елның 1 нче

[10] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 161.

[11] Шунда ук. – С. 158.

[12] Шунда ук. – С. 120–121.

гыйнварында билгеле була[13]. Шундый ук хәлләр татарлар яшәгән башка өязләрдә дә күренә.

Халыкның читтән килгән чиновниклар тарафыннан исәп алуга ышанычы булмый, ачуы кабара, шунлыктан, җанисәбе алу өчен җирле кадрларны кулланырга тырышып карыйлар. Халык ышанган, аларның сүзләрен тыңлый торган кешеләрдән, әлбәттә авыл муллалары икәне мәгълүм. Муллалар дәүләткә бәйле, алардан Указ алган кешеләр, хакимият кушкан эштән баш тарта алмыйлар. Бер өлеш мулла бу хәлгә байкот белдерсә дә, бер өлеш муллалар халык санын алганда актив эш итүчеләр була. Тәтеш өязенең Иске Барыш авылы мулласы (Кама Тамагы районы) Габделгазиз Шәйхелзаманов гади халыкка халык санын алу максатын аңлатуын, каршы килергә кирәкмәгәнен, киресенчә, халыкны тынычландыруын белдерсә дә, ул җанисәбен алуга каршы котыртучы буларак гаепләнә. Имеш, ул туганы Әҗем авылы (Апас районы) кешесе Габделхәким Габделгаффаровка «халык саны чукындыру өчен алына, бу хәлдән хәер көтмәгез, санны алырга бирмәгез» дигән сүзләр сөйләгән, дип яла ягалар. Иске Барыш мулласының фикере буенча, староста Насыров Габделхәким бу гайбәтне Габделгаффаровтан үч алу өчен тараткан. Габделхәким Габделгаффаровның бу юнәлештәге эш-гамәлләре хакында югарыда әйтелгән иде. Әлеге кеше үз фикердәшләре белән, Тәтеш өязенең берничә авылында күтәрелеш оештыра, прошение бирергә тырыша. Бу хәлләрнең ахыр нәтиҗәсе булып оештыручылары төрле дәрәҗәдәге җәзаларга тартыла. Алар – Әҗем авылыннан Тимергали Вахитов, Хәлиулла Мәһдиев, Мөхәммәтулла Һиббәтуллиннарны 10 ар тапкыр суктырылалар, Тимербатыр Вахитов, Бикморза Биктимеров, Габделхәким Габделгаффаров, Галим Һиббәтуллин, Пулат Бикмөхәммәтев, Галәветдин Сәйфетдинев 4 тәүлектән 20 тәүлеккә кадәр тоткынлыкка алыналар. Төхвәтулла Әхтәмев, Иске Барышның указлы мулласы Габделгазиз Шәйхелзаманов 10 сум штраф түләргә тиеш була[14].

Тәтеш өязенең Бик-Үти авылы (Буа районы) халкы җанисәп алучыны куып җибәргәннән соң, волость старшинасы ярдәмчесе авыл старостасына килеп мулланы чакырырга куша. Мулла чиновник янына үзе генә түгел, ә авыл кешеләрен җыеп килә. Халык староста йортына килеп капкасын йодрык белән төеп, старшина ярдәмчесенең халык янына чыгуын таләп итә башлыйлар. Халык исәп алуга каршы торачак, кирәк мәгълүматны мулладан алыгыз дип ярсый. Халыкның каршылыгын күргән старшина ярдәмчесе тизарада авылдан чыгып китә. Тагын килгән очракта, авылга бүтән аяк басмаслык итеп озатырга «вәгъдә итеп» калалар[15].

Халык санын алучыларга булган каршылыкның төп максаты – иманны саклап калу, чукындырылудан курку. Татар-мөселманнар шул лозунг астын-

[13] Шунда ук. – С. 167.
[14] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 5604 эш, 1–8 б кгз.
[15] ТР ДА, 1 ф., 3 тасв., 10165 эш, 47 кгз.

да каршылык күрсәткәннәр дибез, шул ук вакытта бу көрәштә кайчандыр чукындырылган, әмма яңадан исламга кайткан керәшен татарлары да татар-мөселманнар белән бер үк дәрәҗәдә активлык күрсәткәннәрнәрен дә билгеләү кирәк. Чиркәү документларына теркәлгән керәшеннәр, нинди генә контроль булуга да карамастан, электән килгән иманнарына тугры булып, шәригать кануннары буенча яшәгәннәр һәм бу вакыйгаларда да нәкъ мөселман татарлары белән бердәм булып бу кампаниягә каршылык күрсәткәннәр. Зөя, Чуел, Казан, Чабаксар һәм дә Тәтеш өязе керәшеннәре бу активлыклары белән аерылып торганнар[16].

Ни өчен дәүләтнең гадәти генә бер гамәле шулкадәр каршылыклар китереп чыгарган соң? Тәтеш өязе белән идарә итә торган земство начальнигы А. М. Кудрявцев фикере буенча, халык арасындагы мондый аңлашылмаучанлыклар ризасызлыклар бу мероприятиягә кирәгеннән артык рәсми төсмер бирүдә. Әгәр дә волость писарьлары бары тик волость мәгълүматлары җыйган кебек кенә эшләсәләр, бу хәл килеп чыкмас иде, дип аңлата[17]. Рәсмилек бирелгән булса да, халык саны алу мәшәкатьләре, нигездә, волость писарьлары өстенә кайтып кала, һәрхәлдә бу хакта Тәтеш өязенең халык саны алу комиссиясе шулай күрсәтә[18]. Халык санын алучы җирле чиновникларның еш кына эш вакытында аек булмавы да халыкта бу гамәлгә карата булган ризасызлыгын көчәйтә генә. Халык санын вакытында алу, бу эшне дәвам итү максатыннан, халыкны «тынычландыру өчен» Лаеш, Спас һәм Тәтеш өязләренә хәрби отрядлар кертелгәнен Казан губернаторы халык санын алучыларны «За труды по Первой всеобщей переписи населения 1897 г.» медале белән бүләкләгән вакытта белдерә[19]. Халык күтәрелешләрен гаскәриләр белән бастыру очраклары, бигрәк тә, Казан өязендә күп була. 1897 елның 9 нчы гыйнварында ук 3 рота солдат Себер тракты буенча Арчага, 10 нчы гыйнварда 2 рота солдат Мамадыш һәм Лаеш өязләренә юнәлергә тиеш була. 12 нче гыйнварда Чистай өязенә вице-губернатор үзе килә. Хәрби отрядларларның авылларга килүеннән халык әлләни куркып калмый, каршылык күрсәтүләрен дәвам итәләр. Гаскәрнең булуыннан гына шүрләмәгән халыкны кыйнау, суктырулар белән куркыту, җәзалаулар башлана. Мондый хәлләр Казан артында шактый авылларда бара. Тәтеш өязендә мондый ук куркыныч күренешләргә кадәр үк килеп җитмәсә дә, аерым очраклар, әлбәттә булган[20]. 1897 елның 29 нчы гыйнварында вице-губернатор А.Г. Левченко бер рота солдаты белән хәзерге Кама Тамагы районына карый торган Бәрлегуҗа авылына килә. Килү сәбәбе, әлбәттә, бу авыл крестьяннары арасында булган ризасызлыклар, бу каршы-

[16] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 180.

[17] Шунда ук. – С. 125.

[18] Шунда ук. – С. 138.

[19] Шунда ук. – С. 195.

[20] Шунда ук. – С. 199.

лыкларны оештыруда шикләнелгән ике крестьянны – берсен 40 мәртәбә, икенчесен 20 мәртәбә суктыралар. Калган халык бу хәлләрне күреп, каршылык күрсәтеп тә тормыйча исәп алуга ризалаша[21].

Казан вице-губернаторы Спас, Лаеш өзләрендә эшләгән офицерлар эшен күрсәтеп, Мамадыш, Лаеш, Спас һәм Тәтеш өязләрендә булган батальоннарның җәзалау экспедициясен «татар халкына патша властьларына берсүзсез буйсынырга кирәклеген күрсәтте», дип бәяли[22].

Кызганычка каршы, рәсми документларда Тау ягында барган әлеге вакыйгаларга бәйле материал аз сакланган, шунлыктан, картинаны торгызу авыр. Шулай булса да, Тау ягында халык санын алу, татарлар яшәгән башка төбәкләрдәге кебек үк, каршылык белән барганлыгы күренә. Чукындыру сәясәтенең бар авырлыгын татыган халыкның бу вакыйгага булган реакциясе катлаулы була. Проблеманы өйрәнү дәвамында бу төбәкнең үз лидерларын ачыклау мөмкинлеге туды. Халык санын алудагы бар каршылыкны үтеп, бу тарихи вакыйга үз максатына ирешә, шуның нәтиҗәсе буларак, төбәк халкы хакында җыелган статистик мәгълүмат тарихны күзаллауда җитди чыганак туа.

---

[21] Загидуллин И. К. Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. – Казань: Татарское книжное изд-во, 2000. – С. 199.

[22] Шунда ук. – С. 202.

## § 4. *Күчеш хәрәкәте һәм Тәтеш ягы халкының башка төбәкләр белән тарихи бәйләнеше*

Тәтеш ягы Болгар дәүләтенең бер өлеше генә түгел, ә мөһим өлеше була. Иделнең ике ягында урнашкан бердәм дәүләт халкы бер-берсе белән аралашып яшәгән. Тарихчы Г. Әхмәрев Тәтеш ягының Шонгаты авылы халкы кыз алышкан-кыз бирешкән, дип яза. Ул фактларны шул заманда яшәгән кешеләрнең хәтер сөйләмнәренә таянып әйтә. Димәк, бу Шонгатының Болгар шәһәре белән бер дәрәҗәдә булуына да бер ишарә. Моннан кала, элекке Шонгаты шәһәрлеге булган урыннарда яшәгән җирле халык Шонгатыдан Болгарга бара торган юлның урынын XX йөз башында да хәтерләгәннәр. Дәүләт халкының бер-берсе белән аралашу даирәсе, хәтта ки никахлашу даирәсе шул дәүләт кысаларында бара. Болгар шәһәре туздырылганнан соң дәүләтнең Иделдәге икенче як өлеше – Тәтеш ягы, беркүпмедер тынычрак як булуы белән дәүләт халкының бер күпмесендер үзенә сыендыра.

1552 елда Казан ханлыгы дәүләт буларак мөстәкыйльлеген югалткач, көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәте башлана. Иманны югалту куркынычы килеп тугач, халык үз-үзен саклап калу, иманын югалмас өчен ата-бабалары яшәгән җирлектән күчеп тә китәргә мәҗбүр була. Күчешнең сәбәпләре алга таба бу гына булмыйча, башкалары да өстәлә. Шулардан, Тәтеш ягы татарлары мәгариф-агарту миссиясе белән дә башка төбәкләргә барып чыгып авыллар нигезлиләр, җир азлыгы да китәргә сәбәп булган. Вакытлы эшкә китеп, аннан башка төбәкләрдә яшәп калып, якташларын да үз яннарына алып, торак пунктлары булдырулары да күзәтелә. Бу очракта күчеш дигәндә зур төркем халыкның күчеп китүен түгел, ә аерым кешеләр, аерым нәселләрнең күчүен күзалдына китерергә кирәк[1].

Тәтеш төбәгенең атаклы нәселе булган Алиш бәк нәселенең башы Касыйм шәһәреннән башлана. С. М. Шпилевский аларның мишәр кабиләсеннән булуын В. В. Вельяминов-Зернов һәм И. Н. Березин сүзләренә таянып аңлата. В. В. Вельяминов-Зернов «В ауле Ширдан были: Сулейман сын Касбулатов, Ульган сын Утканов и Темир-пулат, сын Недер-шахов. В ауле Тетюш был Бадам сын Шах Селимов. Они были из племени мишерского. Могилы их находятся там же», дип яза, И. Н. Березин да «В ауле Ширдан, в ауле Тетюш из пелемени мещерского известны последователи, которых могилы ныне там находятся» дип шушы ук сүзләрне раслый. Шырдан авылы хәзерге Яшел Үзән районына карый торан авыл, Тәтеш авылы исеме астында хәзерге

---

[1] Сәлахова Э. К. «Тәтеш ягы татарларында миграцион күренешләр: юнәлешләре, сәбәпләре һәм нәтиҗәләре (XVI гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы)» // Историческая этнология. – 2021. – Т. 6. – № 2. – С. 290–301.

Тәтеш шәһәре җирләре күзалдында тотыла. С. М. Шпилевский Тау ягында мишәр нәселенең таралуын Алиш бәк дәвамчылары белән бәйли[2]. Алиш бәк нәселе дәвамчылары Тау ягының бик күп җирләрен биләгәннәр. Чабаксар өязенә кергән Кармыш авылы[3] тарихы да Тәтеш төбәге белән тыгыз бәйләнештә булган, чөнки аны нигезләүче һәм авылга исем бирүче Тәтеш төбәгеннән булган – Кармыш баба. Кармыш бабаның тарихы Тау ягының Тәтеш, Олы Тархан, Буа якларын үз эченә алган «Чирүче шәҗәрәсе» белән бәйле, дип саный М. Әхмәтҗанов[4]. Риваятьләрдә Чирүче нәселенә нигез салучы буларак Казан алынганда алтын бишектә табылган ятим баланы атыйлар. Ятим бала ул хан баласы булган, имеш. Табып алучылар аңа Чирүче исеме бирәләр, бала галим булып үсеп җитә. М. Әхмәтҗанов язуынча, бу шәҗәрәнең төрле вариантлары бар. Мисал өчен, Татар Танае авылында табылган иске кулъязма китапта шул шәҗәрәнең күчермәсе ачыклана. Анда «...Кармыш бине Нурыш. Бу Нурыш падишаһ баласы, алтын бишектә табылган»[5], дип язылган.

К. Насыйри язуынча, Кармыш баба Чынчас авылы чуашларыннан җир сорап алып, шунда йорт салып, хуҗалык корып җибәрә. Бу җирләрдә иген чәчсә дә, Тәтеш белән арасын өзми, гаиләсе шунда яшәгән. Шулай ук бу җирләргә аның ике улы Җангилде һәм Сәид тә килеп төпләнәләр[6]. Хәзерге Кайбыч районына кергән Кошман авылында Кармыш бабаның Сәед исемле улыннан булган дәвамчылар яши дип санаган К. Насыйри[7].

Р. Фәхретдиннең дә бу нәселгә кагылышы бар. М. Әхмәтҗанов Ризаэтдин Фәхретдиннең Санкт-Петербургтагы архивында аның Тау ягында кардәшләре тормышыннан кечкенә күләмле бер русча шәҗәрә саклана, ул үзенең «Шәҗәрәләр җыентыгы»на кергән үз нәсел язмасында бу русча текстны татарчага тәрҗемә итеп биргәнен күрсәтә[8]. Димәк, Р. Фәхретдиннең нәсел башлангычы Тәтештә һәм Кармыш авылында яшәгән мөселман казак, йомышлы татар Кармыш бабага тоташа.

Р. Фәхретдиндә Кармыш бабаның уллары Җангилде белән Җанегет биләгән җирләргә руслар Сембер каласы (1648 нче ел) корганнар дигән хәбәр китерелә[9]. Моннан кала, бу нәсел Тау ягының бик күп төбәкләрендә җир би-

[2] Шпилевский С. М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники Казанской губернии. – Казань: Университетская типография, 1877. – С. 98.

[3] Кармыш – Чуаш республикасы, Козловка районындагы татар авылы.

[4] Әхмәтҗанов М. И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 289.

[5] Шунда ук.

[6] Насыйри К. Избранные произведения. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1977. – С. 63.

[7] Шунда ук. – С. 63

[8] Әхмәтҗанов М. И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 292.

[9] Әхмәтҗанов М. Риза Фәхретдинев шәҗәрәсе // Казан утлары. – 1984. – № 4. – Б. 165.

ләгәннәр: аларның Шырдан ягында да, хәзерге Чуашстан ягында да җир биләмәләре булган[10].

Бу ике төбәкнең үзара аралашуы ике яклы барган: К Насыйри язуынча, Зөя буендагы Борнаш бабай нигезләгән Борнаш авылы мөселманнары Казанны рус гаскәрләре яулап алгач, авылны калдырып китеп, хәзерге Апас районына карый торган Борнаш авылын нигезләгәннәр, Апас районының Бакырчы авылы да хәзерге Яшел Үзән районының Бакырчы авылы кешеләре тарафыннан нигезләнгән[11].

Аралар ерак булса да, Тәтеш төбәге нәселләренең Самара губернасы Бөгелмә өязе, Уфа губернасы Уфа, Минзәлә өязендәге кайбер авыллар тарихы белән бәйлелеге күренә. Алиш бәк нәселе Тәтеш төбәгенең билгеле зур нәселе. Ш. Мәрҗани Алиш бәк нәселе борынгы Болгар шәһәре җирлеге – Мең өйле Шонгаты җиреннән күчеп килеп, Иске Әлмәт авылына нигез салалар дип яза. Марсель Әхмәтҗанов Иске Әлмәт җирлегенә Алиш бәкнең кече улы Әлмөхәммәд (Әлмәт) 1650 елдан соң килеп төпләнгән булса кирәк дип күрсәтә. Хәзерге Нурлат районына карый торган Иске Әлмәт авылы турында сүз бара, әмма бу авылның нигезләнү датасы буларак энциклопедик сүзлек 1730 нчы елларны гына атый[12]. Мондый төр сүзлекләрдә авылларның нигезләнү датасы итеп, гадәттә, исемнәренең беренче тапкыр рәсми документларда теркәлү вакыты гына алына. Шуңа да, авылларның нигезләнү датасын хакында сүз алып барганда, халыкның үзе тарафыннан тудырылган чыганакларга да игътибар бирү кирәк.

Алиш бәк нәселенең Гобәйдулла бине Җәгъфәр 1822 елга кадәр Иске Әлмәттә имамлык итә[13], аның вафатыннан соң Гобәйдулла хәзрәтнең уллары, аның нәсел дәвамчылары Әлмәтнең рухи тормышында, халкының аң-белем үсешендә зур роль уйнаган шәхесләр.

Әлбәттә, таза тормышлы морза гаиләсе бирегә үз биләмәләрен арттыру максаты белән килә. 1670 елларда Әлмөхәммәд инде Әлмәт төбәгенең хәлле, маллы морзасы булган. Тәтеш ягында исә Алиш бәкнең Чирмешән елгасы буйларында улы Багдан һәм аның уллары утарлар тотканнар. Апас төбәгенең бөтен көньяк авылларында Алиш бәкнең улы Багдан нәселе таралган.

Шушы ук нәсел хәзерге Спас районына карый торган авыллар тарихы белән дә бәйле. Югарыда әйтелгән Гобәйдулла хәзрәтнең нәсел дәвамчысы Нигъмәтулла улы Нурулла Иске Әлмәттән Спас өязенең Көек авылына килеп гомер итә. Ул Алишбәк нәселенең сигезенче буыны булса, шушы нәселәдән

[10] Әхмәтҗанов М. И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 289.

[11] Насыйри К. Избранные произведения. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1977. – С. 54.

[12] Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1997. – С. 218.

[13] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 293–294.

чыккан балалар язучысы Габделбарый углы Абдулла Алиш (1908–1944) бу нәселнең унынчы буыны[14].

Әлбәттә, кайчандыр бер дәүләт җирләре булган Иделнең ике як яры халкы Болгар дәүләте беткәннән соң да, нәсел җепләрен саклап килгәннәр. Шуңа мисал итеп, хәзерге Иске Баллы Күл авылын китерү мөмкин. Заманында археограф Сәед Вахиди Иске Баллы Күл авылының борынгы Болгар шәһәре урынындагы авыл икәнен картлар сөйләменнән язып алган. Авыл кешеләренең хәтере буенча, Казан ханлыгы җимерелеп, авыр чорлар башлангач, шушы авылга Тәтеш өязенең Күккүз авылыннан берничә нәсел күчеп утыра. Халык хәтере буенча, Бәйкә баба, Боерган баба һәм тагын бер нәсел – барысы өч нәсел күчеп килгәнннәр[15]. Алга таба Болгар чорыннан ук килгән Баллы Күллеләр белән Күккүз нәселләре бербөтен булып яшәп китәләр. Бирегә күченүнең сәбәбен халык үзе түбәндәгечә аңлаткан: «Чукынмаган мөселманнарны авыллардан сөреп, икенче җирләргә таратканнар. Шулай итеп, бик күп мөселман авыллары әрәм булып беткәннәр. Менә монда авыр заманнар, безнең әби-бабайлар өчен дә караңгы вә кайгы чоры булып, озак еллар шулай дәвам иткәннәр. Менә шундый дингә кыстау чакларында безнең бабайлар Тәтеш өязеннән күчеп килеп, Ыспас өязенең кап-кара куе урман белән чорналган бер почмагына, шәһре Болгар заманасыннан бирле дине исламны тотып килә торган бер авылга, әлеге Баллы Күл авылына килеп утырганнар»[16]. Археограф Сәед Вахиди фәнни экспедициясендә бу авылның кешеләренең тышкы кыяфәтләренә игътибар итеп: «Баллы Күлдә минем белән мосахабәдә булган бабалар, гомумән ул авылда мин күргән кешеләр, ире һәм хатыны озын буйлы, мәһабәт кыяфәтле, үткен кара күзле, төреклек канын, төреклекнең җисмани җәһәттән булган бик күп хосусиятләрен саклап килгән кешеләр иде. Әгәр боларга яхшы мәктәп тәрбиясе бирелгән булса, боларның эчендән уйламаган эшлекле адәмнәр чыккан булыр иде дигән фикер килде»[17]. Тәтеш нәселләре килгәнче үк бу Баллы Күл халкы куркусыз, баш бирмәс булулары белән аерылып торган, халык хәтеренә алар шәригать кануннары үзләре хөкем чыгара белүләре белән кереп калганнар.

Баллы Күл авылы тарихы борынгы Болгар чорыннан ук килә. Аның тәүге халкы Баллы Күл нәселләре һәм дә Тәтеш төбәге татарлары белән кушылган нәселләр. Әмма аның нигезләнү датасы итеп тә белешмәлектә бары тик XVII йөзнең икенче яртысы күрсәтелә. Иске Баллы Күлдән аерылып чыккан Яңа Баллы Күл тарихы белешмәлекләрдә XVIII гасырдан башлана дип бирелә[18].

---

[14] Ахметзянов М.И. Родословная Алиша // Ахметзянов М. И., Шарифуллина Ф. Л. Касимовские татары. – Казань: Магариф, 2010. – С. 11–14.

[15] Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар. 4 нче чыгарылыш. – Казан, 2017. – Б. 62.

[16] Шунда ук. – Б. 60.

[17] Шунда ук. – Б. 62.

[18] Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1997. – С. 45–46.

Тәтеш кешеләренең Спас ягына күчеп утыруларының башка сәбәпләре дә бар. Тарихы борынгы Болгар чорыннан ук килгән Ташбилге авылында да Тәтеш өязеннән чыккан нәсел булган. Авылда аларны Ишем җәвере (нәселе) дип йөрткәннәр. Ташбилге халкы үзенең шәҗәрәсен Болгардан килгән Мөслим бабага нисбәт иткән, ә Ишемнекеләрне килгән халык буларак бик яратып бетермәгәннәр. Алар монда сөргенгә җибәрелгән кешеләр булса кирәк. Сәед Вахиди авыл кешеләре сүзләреннән «авылдагы җыртлач, усал куштаннар әнә шул Ишем җәверләреннән чыгып килгән, югыйсә Ташбилгенең үз халкы юаш, мәрхәмәтле, кешегә ярдәмче халыклар»[19], дип язган. Бәлки килүчеләр гамәлләре белән авыл кешеләреннән аерылып та торганнардыр, ә бәлки килгән кешеләрне сак кабул итү, кайбер очракта өнәп бетермәү аркасында гына туган фикер булуы да ихтимал. Энциклопедик белешмәлектә авылның нигезләнү вакыты итеп XVII–XVIII йөзләр күрсәтелә.

Спас районына керә торган Иске Рәҗәп, Чәчәкле авылларының тарихы да Тау ягындагы Бигеш дигән кеше белән бәйле. Тау ягы мирзасы Бигеш XVII йөздә рус хөкүмәтендә яллы хезмәттә була, билгеле булганча, яллы хезмәт мирзалары хезмәт итү өчен башка төбәкләргә дә җибәрелгәннәр, Бигеш исә Кама аръягы зонасына күчерелә. Спас төбәгендәге Рәҗәп авыллары Бигеш нәселеннән булган Рәҗәп баба тарафыннан нигезләнә. Рәҗәп баба үзе Тәтеш янындагы Олы Тархан кешесе. Аның нәсел шәҗәрәсе Ризаэддин Фәхреддиннең Санкт-Петербургта «Шәҗәрәләр мәҗмугасы»нда сакланган[20]. Бу нәсел Болгар шәһәрлеге җирләреннән алып, хәзерге Әлмәт шәһәренә кадәр булган җирләрдә яшәп калганнар. Бу зур нәселнең тарихы шушы җирлектә дәвам итә.

Казан яуланып алынганнан соң, XVI йөзнең икенче яртысыннан башлап, бигрәк тә XVII–XVIII йөзләрдәге чукындырудан качып, шулай ук җир азлыгыннан арып татарларда тынычрак, җир дә мулрак булган җирләргә күчеп китү күзәтелә. Уфа губернасына караган Минзәлә, Самара губернасының Бөгелмә өязләренә караган җирләргә, бу җирләр белән чиктәш булган хәзерге Башкортостан җирләренә килеп урнаша башлыйлар. Алар, нигездә, бу җирләргә Казанга якын булган төбәкләрдән күчкәннәр. Китүчеләр арасында татарлар кала башка халыклар: марилар, чуашлар, удмуртлар да була. Килеп җир алган, шунда яшәп калган күчеп килүчеләр «типтәр», «башкорт» дип аталган сословияләр тәшкил итәләр. Башкортостан җирлегендә типтәрләр тарафыннан нигезләнгән авылларның исемнәре бу төбәккә халыкның кайдан күчеп килүе хакында фикерләргә мөмкинлек бирә. Тарихчы Г. Әхмәрев тә типтәрләр турында «Тептяри и их происхождение» дигән хезмәтендә охшашлык булган 28 авыл исемен атый[21]. Шулар арасында Тәтеш өязендә дә

---

[19] Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар. 4 нче чыгарылыш. – Казан, 2017. – Б. 45–47.

[20] Әхмәтҗанов М. И. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 121.

[21] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык / Төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан: Хәтер, 2000. – С.301–320.

очрый торган Апас, Бәйрәш, Балтач, Бик, Дәүеш, Ишеево, Ишем, Ишле, Карабай, Курмыш, Келәнче, Кләш, Тинкәш, Турай, Чаллы исемнәре Минзәлә, Бәләбәй, Бирск, Уфа, Стәрлетамак өязләрендә дә бар. Галим фикере буенча, бу авылларның тарихында, аларның нигезләнүендә, шул исәптән, Тәтеш ягы халкының да роле бар. Борынгы шәҗәрәләр дә, халык хатирәләре дә бу бәйләнешне раслыйлар. Мондый күчеш XX йөз башында да дәвам иткән, мисал өчен Тәтеш өязенә кергән Бикмораз авылыннан (хәзерге Буа районы) Әлмәт ягыннан киткән нәсел шәҗәрәсе автор башкаруында кушымтада бирелә.

*Тәтеш кешеләренең Әстерхан, Урал, Себер якларына китүләре.* Тәтеш өязенә кергән авыл кешеләреннән хәзерге көнгә кадәр «безнең Әстерхан ягында туганнарыбыз бар», яисә «балачагымда Әстерханнан туганнар кайтып йөри иде», дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Хәтта «әти безне Әстерханга алып китмәде, ачлыктан монда да исән калдык», дигән сүзләрне дә ишеткән булды. Димәк, Әстерхан якларына барып чыгуның берничә дулкыны һәм сәбәбе булган. Шул ук Казан ханлыгы яуланганнан соң да әле руслар кулына күчмәгән татар дәүләтенә сыеныр өчен киткәннәр, аннары руслаштыру, чукындырудан качып та китүләр булган. Әлбәттә, Идел елгасының югары агымындагы татарлар Әстерхан якларына күпләп сәүдә итү өчен дә килгән. Белүебезчә, Әстерхан сәүдә өчен бик уңайлы урында, Әстерхан аша Кытай, Һиндстан, Иран һ.б илләрдән товар агылган. Бу шәһәр элек-электән көнчыгыш, көньякта тышкы сәүдәдә Русиянең үзәге булып торган. Моннан кала, кышкы сезонда вакытлы эшкә китүчеләр, балык тоту, яисә Иделдә төрле авыр хезмәтләргә ялланып эшләүчеләр дә, тора-бара тамак туйдыру өчен мөмкинлек зуррак, табигать шартлары белән дә уңайлырак булган Әстерхан җирлегендә төпләнеп калалар. Бу якка китүнең тагын бер сәбәбе – ул ачлык, аннан репрессия, мал-мөлкәтне тартып алган чорда бу якларга Казан тирәсендәге бик күп татар гаиләләре белән күчеп китә. Әстерхан җирлегенә килеп урнашкан Югары Идел татарлары, нигездә, Әстерхан шәһәренең татар бистәсе – Тияктә төпләнеп калганнар. Килүчеләр арасында Пенза, Нижгар, Самара губернасы татарлары күп була. Казан губернасы, хәзерге Татарстан җирлегеннән дә Әстерхан якларына күчеп килүчеләр һәрвакытта да шактый булган. Шунысы кызыклы, Казан арты татарларына караганда, хәзерге Татарстан җирлеген карасак, тамырлары белән Тау ягыннан булучылар күпчелекне тәшкил итә. Әстерхан шәһәренең метрика дәфтәрләрендәге язмалар бу хәлне раслый[22]. Мисал өчен, Тәтеш районына керә торган Коллар авылы (Кызыл Тау), Коштау, Табар Черкене, Бакырчы, Урта Балтай, Түбән Балтай, Колгана, Буа районының Бәбки, Әхмәт, Ташкичү, Кабалан, Күзби, һәм башка авылларның кешеләрен күрергә була,

[22] Салахова Э. К. Метрические книги как источник изучения татарской общины г.Астрахани (вторая половина XIX – начало XX вв.) // Историческая этнология. – 2016. – Т.1. – № 1. – С. 86–95.

аларның күбесе зур гаиләләре, туганнары белән Әстерханга килеп төпләнгән. Әстерханның Татар бистәсендә яшәүчеләрне теркәгән 1744 елгы документтан да Тау ягыннан килгән гаиләләр булуы күренә, аларның килү сәбәбе эшкә килү итеп күрсәтелгән. Мисал өчен, Бәке Йомралысы, Яңа Сала, Әхмәт, Балтай, Алабирде, Келәш, Зөябаш һ.б. авыл кешеләре теркәлгән[23]. Әстерханга Урта Идел ягыннан килгән кешеләрнең бу регион халкы ничек кабул иткән соң, аларның мөнәсәбәтләре ничек булган дигән сорауга болай җавап бирергә була. Әстерханда яшәүче татарлар Иделнең югары агымыннан килгән кешеләрне үз җәмәгатьчелегенә бик җиңел кабул итә, чөнки болар бербөтен татар халкы, гомумән, Әстерхан төбәгенә башка җирләрдән килүчеләр, шул ук Кырым, Себер якларыннан да даим күчеп килүчеләр булып торган, шуңа алар моңа гадәти күренешкә караган кебек кенә карыйлар. Әмма Казан татарлары беренче вакытларда җирле татарлар белән бик үк еш никахлашмаганнар, аларның никахлары күбрәк үз арасында барган, яисә килүчеләрнең үз кызларын җирле байларга кияүгә бирү очраклары гына булган. Соңрак җирле халык белән килүчеләр арасында никахлар ешая, моны Әстерхан шәһәренең метрика язмалары раслый. Килүчеләр, нигездә, Әстерхан шәһәренең Татар бистәсендә төпләнгәннәр. Сату-алу белән эш итмәгәннәр, яисә һөнәрчелек белән шөгыльләнмәгәннәр, җиргә якынрак – әстерхан татарлары яшәгән татар авылларын сайлаганнар. Урта Иделдән Әстерханга күчеп килүнең сәбәбе – Урта Идел буендагы ачлык. XIX йөзнең 70–90 нчы елларында Әстерхан төбәгенә ачлыктан һәм эпидемиядән качып атаклы рухани, Коръәнне яттан белүче, үләннәр белән дәвалаучы Исмәгыйль Искәндәрев гаиләсе белән Яңа Болгар авылына килеп төпләнә. Болгар авылының нигезләүчеләр, аның беренче яшәүчеләре Казан ягыннан чыккан кешеләр, алар арасында чыгышлары белән Тәтеш ягыннан булган кешеләрнең күп булуы да билгеле. Бу авылны нигезләп, беренче яшәүче гаилә башлыкларының уртача яшьләре 33 яшь һәм алар, нигездә XIX йөзнең 80–90 елларында туган кешеләр. Шулар арасында Шәмәк авылыннан (Апас районы) Нәҗметдинов Габделхак, Мәҗитов Хәлиулла, Тәтешнең үзеннән Хөсәенев Мөхәммәдьяр (1905 елны туган), Әмиров Сираҗетдин шулай ук чыгышы белән Тәтеш өязе авылыннан, Фәхреддинев Шәйдулла, Мөгарипова Мәрфуга, Бакиев Гайнулла һ.б. Тау ягыннан килеп төпләнгән кешеләр. Алар арасында шулай ук Спас өязе авыллары кешеләре дә, Югары Иделнең башка төбәкләреннән килгән кешеләр дә бар. Бу кешеләрнең зур күпчелеге алдан Әстерхан төбәгенең башка авылларында яшәгәннәр. Яңа Болгар авылы җирле Әстерхан татарлары авылы түгел, ул Югары Иделдән күчеп утырган кешеләр авылы, монда гомер итүчеләр үзләренең нәселләренең чыгышлары Югары Идел белән бәйле икәнен белсәләр дә, аларның инде күбесе нәсел тамыры булган авылларының исемнәрен инде хәтерләмиләр.

[23] ӘӨ ДА, 394 ф., 1 тасв., 1021 эш, 1–34 б кгз.

1918 елда нигезләнгән бу авылга ни өчен шундый исем сайланганы әлләни шаккаттырырга тиеш түгел кебек. Идел буенда яшәгән халыклар дәүләтләре туздырылса да, үз дәүләтләрен сагынганнар, аны хәтерләгәннәр. Күчеп китеп башка төбәкләрдә нигезләгән торакларына дәүләт исемен кушып аның мәңгеләштерергә тырышканнар. Шулай да, Әстерхан төбәгендә Урта Иделдән килгән татарлар нигезләгән, алар яшәгән башка авыллар, мәхәлләләр дә бар. Габделхак Мәҗитов Комаровка авылында кибет тоткан, Сәлимҗан Хәбибуллин Малявка авылында төпләнә (хәзер Волгоград өлкәсенә керә), аннан Әстерхан губернасының Тишково авылына күченә, аннан инде якташлары нигезләгән Яңа Болгар авылына килеп гомер кичерә. Сираҗетдин Әмиров та 1918 елда Тишково авылыннан Яңа Болгарга күчә. Казан ягыннан килүчеләр Майлы Күл, Каргалык, Кызан һ.б авылларда гомер иткәннәр, аларның нәселләре әлеге җирдә дәвам итә[24].

XIX гасыр азагы мәгълүматларына караганда, Тәтеш өязе авылларыннан читкә китүчеләр булган, әлбәттә алар эш эзләп киткәннәр, тора-бара шунда төпләнеп тә калганнар. Казан губернасыннан Оренбург ягына китүчеләр күп була, шул исәптән, Тәтеш ягыннан да Оренбург губернасына китеп урнашучылар күпчелекне тәшкил итә. 1890–1896 еллар аралыгында Оренбургка күчеп китүчеләр: Энәле авылыннан Габделгаффаров Мозаффар һәм Вәлишин Гобәйдулла, Хәбибуллин Әхмәдҗан һәм Мөхәммәдҗан гаиләләре белән, Шәмәк авылыннан Габделнасыров Бикчәнтәй, Биктаһиров Хисаметдин һәм Җәмалетдин, Насыров Бикчәнтәй Габдулла улы, Сабитов Хәбибулла гаиләләре белән, Тимергалиев Зариф, ир туганы Боһанетдин һәм энисе Фәхрениса белән, Тимергалиев Нургали гаиләсе белән, Иске Энәледән Габделгаффаров Хәламат, Дәүеш авылыннан Габделҗәлилев Габделсаттар, хәзерге Кыр Тәүгелдесе авылыннан Биккенин Мөхәммәди үзенең бертуганнары Гали, Вәли, сеңелесе, энисе белән, Олы Фроловодан Степанов Василий Степанович, Ябалак авылыннан Касыймов Нәҗметдин, Касыймов Сәлахетдин Низаметдин улы гаиләсе белән, Коллар авылыннан Мөхәммәдрәхимев Габитҗан, Бикбулатов Миңнегали гаиләсе белән, Сәйфуллин Мөхәммәдрәхим гаиләсе һәм кыз туганы Фәхрениса белән, Шонгатыдан Килькиново Просковья Васильевна улы Василий белән, Кече Болгаер авылыннан Нурмөхәммәтев Җәләлетдин, Дәүләкидән Биктаһиров Етмухан[25], Балтай авылыннан Баязитов Шакир, Урта Балтай авылыннан Батыршин Бикмулла, Әхмәт авылыннан Динмөхәммәтева Хаерниса гаиләсе белән, Олы Болгаердан Рәхмәтуллин Мөхәммәднури гаиләсе белән, Чиремшән авылыннан Саипколов Нигъмәтҗан, Үгез Куагыннан Садыков Әхмәтҗан һәм ир туганы Закирҗан, Олы Тормыдан Сиражетдинев Гыймадетдин гаиләсе белән, Олы Яңасаладан Токтаров

---

[24] Сиражетдинов Ш.К. История села Новые Булгары. – Астрахань, 2001. – С. 7–18.

[25] Исемнәр документларда язылганча бирелә, рус телле документларда татар исемнәре еш кына бозып бирелгәнне истә тотарга кирәк.

Ишмөхәммәд гаиләсе белән, Олы Ындырчы авылыннан Таһиров Фәхретдин, Әхмәт авылының Тимербулатов Ибраһим гаиләсе белән, Каенлык авылының Хәбибуллин Габдулла гаиләсе белән[26].

Уфа губернасына китүчеләр: Танай Турай авылыннан Алешина Елизавета Тимофьевна, Абызово авылыннан Миннишев Фәйзрахман Габдрахман углы үзенең бертуганнары Хәбибрахман һәм Хәбибулла белән, Нәҗметдинев Мөхәммәдзариф Сабирҗан улы, Кужак авылыннан Төхвәтуллина Гөлчирә. Ташкичүдән Нәҗметдинев Мөхәммәдзариф Сабирҗан улы. Олы Яңасала авылыннан Аксаков Әхмәтҗан, Урта Лашчы авылыннан Салихов Халит гаиләләре белән Омск губернасына, Шәмәк авылыннан анасы һәм кыз туганы белән Билялетдинев Саттар Томск губернасына, Коллар авылыннан Сәгъдетдинов Ибраһим Әстерхан губернасына, Аксу авылыннан Тимерпулатов Платон, Абдуллин Хәмидулла гаиләләре белән, Коллар авылыннан Таҗетдинев, Тутай авылыннан Нурмөхәммәтев гаиләсе белән Самара губернасына, Урта Балтай авылыннан Габделнафиков Габденнасыйр Пермь губернасына, Өченче Чиремшән авылыннан Бәхтияров Баһаветдин гаиләсе белән Төркестан губернасына, Олы Күккүз авылыннан Әхтәмев Габделкадыйр Кострома губернасына күченәләр. Моннан кала, аерым кешеләрнең Тобол, Санкт-Петербургка һ.б. җирләргә күченеп китүләре билгеле[27].

Тәтеш төбәгеннән Себер ягына күчеп китүчеләр турында тумышы белән хәзерге Тәтеш районына карый торган Аллабирде авылы кешесе 1875 елда туган Ризаэтдин Сафиулла улы Хәмидов көндәлекләрендә чагылган. Кызганычка каршы, көндәлекнең төп нөсхәсе сакланып калмаган. Бу хакта матбугатта аның нәсел дәвамчысы Наилә Галиева язган иде[28]. Шул көндәлектән өзек: «Без Себергә 1912 елның көзендә килеп тора башладык. Шул көздә 6 аршынлы ызба салып, башын үлән белән ябып та куйдык. Без килгәндә бу авылга һичбер исем бирелмәгән иде. Авыл халкы бу авылга Казан авылы исеме куйды. Чөнки бу авылда гел Казан халкы җыелган иде. Тәтеш өязеннән Күккүз дигән авыл кешеләре – болар Себергә башлап килеп, бу авыл утырган участокны биләгәннәр һәм шунда утырганнар. Янә Тургай дигән авыл, янә Аллабирде дигән авыл кешеләре, янә Әҗем авылы, янә ике йорт Чистай өязеннән, янә бер йорт Мамадыштан бар иде. Бу Казан авылы Иртышның сул ягында, Иртыштан 15 чакырым эчтә, элекке Такмык волостеның Тара өязендә иде. Казан халкы биредә 1930 елга кадәр торды. 1930 елда бу авылның җирен совхоз алып, авылны таратырга мәҗбүр итә. Авылның күбесе 20 чакырым җиргә – Тозказан дигән авылга барып, колхозга керде. Бер генә йорт, Үләнкүл дигән авылга барып, колхозга кердек. Үләнкүлдә бер ел торгач, иген булмау сәбәпле, түбән таба Иртыш белән 1932 ел 1 майда Усть-Ишим дигән

[26] ТР ДА, 3 ф., 1 тасв., 13161 эш, 5–187 кгз.

[27] Шунда ук.

[28] Галиева Н. Себернең югалган Казаны // Безнең мирас. – 2021. – № 8. – Б. 13–15.

авылга килдек. Усть-Ишимбер җәй торып, аннан Ире дигән авылга – Кип-Кулларга килдек.

Казан авылында беренче землянка казып тора башлаган кеше – Миңлевәли Насыйбулла углы, Күккүз авылыннан; 2 нче – Кәлимулла Хәмзә угылы; 3 нче – Һидиятулла Ибраһим угылы; 4 нче – Ибнеҗан Ибраһим угылы; 5 нче – Миңдулла Гыйбадулла угылы; 6 нчы – Гарифулла Ибраһим угылы; 7 нче – Гарифулла Гыйбадулла угылы; 8 нче – Дәүләтша Тимергали угылы; янә Әҗем авылыннан Мөсәллим карт; Дәүләтша Хәмит угылы; (?) Мәхмүт угылы; янә Барыш авылының Ярулла Мостафа угылы; янә Тургай авылыннан Ганибулла Фәхреддин угылы; Баһаветдин Фәхреддин угылы; Мәхмүдт Фәхреддин угылы; Җамалетдин Котмәт угылы; Мәхмүтсадыйк Җамалетдин угылы; Сәгыйдулла Динмөхәммәд угылы; Аллабирде авылының Ганикулла Гарифулла угылы; Ризаэддин Сафиулла угылы; янә Әҗем авылының Вахит Бәхтияр угылы; Дүртөйленең Гыйлаҗетдин Сираҗетдин угылы; Габделҗәббар Габделгариф (?) угылы; Чистай өязе Мәхмүт Кәрим угылы; янә Тәрҗемән карт; янә Мамадыш өязенең Хәмидулла Сәгыйдулла угылы. Болар – төп Казаннан күчеп килгән кешеләр. Казан авылында 1909 елдан башлап 1931 елга кадәр торганнар»[29]. Халыкның Себер якларына күчеп китергән сәбәп – җир азлыгы, гомере буе игенчелек белән яшәгән халык эшләү өчен бераз булса да җирен арттыруга өмет иткән. Аннан Идел буенда 1921 елгы коточкыч ачлык елларында да туганнары, якташлары алар янына сыеналар.

Читкә китәргә этәргән сәбәпләр Россия тарихында аз булмаган. Шул ук Столыпин аграр реформалары да, ачлыклар да, чукындыру сәясәте дә, җир азлыгы да һ.б. Коллективлаштыру еллары да миграциягә этәрә, гомер буе бөртекләп җыелган мөлкәтен тартып алгач гомер иткән ата-баба нигезен ташлап китәргә мәҗбүр иткән. Туган ягыннан аерылып чит җирдә тормыш корып җибәргән татарның тормышында башка афәтләр дә булмый тормаган. Ризаэддин Хәмидовның оныгы Наилә Галиева язуы буенча, Казан авылының беренче нигезләүчеләре булган кешеләрнең репрессия корбаннары булуы да, Ватан сугышы ачыларын татулары да билгеле. Аларның тире тамган, алар нигезләгән, җирен сөргән Казан авылы инде җир йөзендә дә юк, бу авыл беткән.

Тәтеш төбәгендә яшәгән нәселләрнең нәсел тамырлары башка якларга таралу сәбәпләре ил тарихындагы вакыйгалар белән бәйле, аерым төбәк мисалында тарихи вакыйгалар китереп чыгарган миграцияне өйрәнү – халыкның «җанлы» тарихын күрсәтү өчен гаять кирәкле юнәлеш. Бу мисаллардан күренгәнчә, күчеш, аралашу хаотик рәвештә бара торган агым түгел, ә аның нигезендә тарих ята, хәтта генетик бәйләнешләрнең дә бу очракта зур роль уйнаганы күренә.

[29] Галиева Н. Себернең югалган Казаны // Безнең мирас. – 2021. – № 8. – Б. 13–15.

# VI бүлек

# ТАУ ЯГЫНЫҢ АТАКЛЫ НӘСЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ШӘХЕСЛӘРЕ

## § 1. *Галишаһ морза нәселе*

Тау ягының атаклы нәселләреннән – Галишаһ (Алиш бәк) нәселе. Бу нәсел тарихы тулы бер Тау ягы белән генә дә чикләнмичә, элекке Чистай өязе җирләрендә дә дәвам итә. Бу нәселнең башы Касыйм җирләреннән килә.

Ш. Мәрҗани үзенең атаклы «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында бу шәҗәрәне Нигъмәтулла хәзрәттән башлый һәм аны Галишаһ – Галиш – Алиш морза белән тәмамлый. Галишаһны Тау ягындагы (Дагстан, яисә Җәбәлстан дип тә атаганнар) Шонгаты – Олы Әтрәч авылыннан, дип күрсәтә[1].

«Галикәй аталык васыятнамәсе»ндә сакланган имзалары буенча аларның 1639 елда Касыймда яшәгәнлекләре билгеле. Аннан соң бу нәсел эзләре Тау ягындагы, хәзерге Апас районына карый торган җирләрдә – борынгы болгар шәһәрлеге Мең өйле Шонгаты дигән урында күренә. Галишаһ морза Идел буена чик сакчысы вазыйфаларын башкаручы дәүләт крестьяннарының җитәкчесе буларак килеп утырган булырга тиеш. XVII гасырда Рус дәүләтенең чиге Урта Иделгә кадәр сузылган, Алатыр, Тәтеш нугай татарлары, калмыклардан саклану торагы булып хезмәт иткән. Ш. Мәрҗани Романовлар патшалык иткән чорда, ханлыкның дәүләтчелегенә һәм аның асыл затларына каршы аяусыз көрәш башлап җибәрә. 1650 еллар тирәсендә Галишаһ морза үзенең уллары белән Тау ягындагы (Җәбәлстан) «Мең өйле Шонгат» (Тәтеш районының хәзерге Олы Әтрәч җирләре) дип аталган борынгы болгар-татар авылына килеп урнаша һәм морзалык итә башлый, дип яза. XIV–XVII гасырларда бу урыннарны Иске Шонгат дип тә атап йөргәннәр. С. Алишев роман-хроникасында Галишаһка авыру этисе белән тарихи ватаны – Олы Әтрәчкә кайтырга Ф. И. Шереметьев рөхсәт итә, дип яза[2]. Аңа хезмәте өчен

---

[1] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 414 б.

[2] Алишев С. Галишаһ морза нәселе. Роман-хроника. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. – 559 б.

500 дисәтинә җир биләргә хокук бирелә. Галишаһ морзаның утары төбәк хакимиятенең филиалына әйләнеп, аңа караган авылларның 500 йомышлысы хезмәт иткән[3].

Галишаһ дәрәҗәле морза булган. Тарихи чыганакларда 1650 елларда Шонгаты елгасы буенда Шонгаты авылы булганлыгы искә алына, ул вакытта авылда унбер хуҗалык булып игенчеләр көн күргән[4]. Әмма алар арасында Галишаһ морза исеме күренми. Галишаһ морза кече улы Әлмөхәммәд (Әлмәт) белән бераз соңрак – 1650 елдан соң күчеп утырган булырга тиеш. Аларның килеп утырган урыннары Шонгаты булса да, бу нәселнең җир биләмәләре, шулай ук нәселләре бу яктагы башка җирлекләргә дә тарала. Галишаһ морза бирегә килеп урнашкач, дәүләт хезмәткәре буларак зур җир кишәрлекләренә дә ия булган, хезмәте өчен дә җир белән бүләкләнеп торган. Бу төбәктә аның улларының җирләре дә була. Апас, Тәтеш төбәгендәге авыллар тарихы бу нәсел җирбиләүчеләре белән бәйле. Галишаһ морзаның олы улы Багдан һәм аның уллары Василий, Симәнәй, Уразмәмәт Алишевлар Дәүләки авылы янында утар биләгәннәр. Чирмешән елгасы буенда аларның су тегермәннәре дә булган. Башка туганнарының җирләре Тутай, Колчык, Яңа Симәнәй авылларында да була, анда да аларның нәселләре гомер иткән. Галишаһ морзаның улы Багдан балалары бу дәвердә Апас төбәгенең Карабай, Сәүтек, Йомралы авылларында да гомер кичергәннәр. Бу авыл кешеләренең нәсел башы Багданнан башлана. Бу урыннар морза нәселе җирләре булуга топонимик атамалар да сылтама бирә. Апас районына карый торган Морзалар авылының нигезләнүе XVI гасырның икенче яртысы буларак билгеләнә, авыл морзаның утар җирендә нигезләнгән булса кирәк. Шулай ук Апас төбәгендәге Коллар (1940 елларга кадәр шул исемне йөртә, хәзерге вакытта Кызыл Тау авылы буларак билгеле, әмма халык аны үзарасында барыбер Коллар авылы дип атый) авылының исеме дә дәүләт крестьяннары яшәгән авылга әйтелгән булырга тиеш. Энциклопедия мәгълүматы буенча, бу авыл XVIII йөздә нигезләнгән[5]. Тау ягында Багдан нәселләре таралса, Галишаһ морзаның кече улы Әлмөхәммәд (Әлмәт) улының нәселе Болын ягында дәвам итә. Әлмәт шул якка күчеп хәзерге Норлат районына карый торган Әлмәт исемле авылга нигез сала. Спас районындагы Җамбакты, Иске һәм Яңа Рәҗәп, Көек, Чәчәкле авыллары шушы күченүләр нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Шушы нәсел дәвамчысы булган галим-тарихчы С. Алишев сүзләренә караганда, Әлмәтулла «болгар бабаларыбызның урынын яңадан үзләштерәм», дип

---

[3] Заһидуллин И. К. Алишев С. Х. Галишаһ морза нәселе // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 4. – Б. 172.

[4] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 76.

[5] Населенные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник, 1997. – Казань: Академия наук РТ, Институт татарской энциклопедии. – С. 58.

Кама аръягына чыгып, Мораса елгасына Гәрәй суы кушылган җиргә каршы, хәзерге Иске Әлмәт авылын төзи. Балалары: Сөрмәт, Килка, Өрмәмеш, Нурмый була. Шулардан, улы Сөрмәт (1620 елда туган) Сәмәрканд шәһәрендә белем ала, Коръән хафиз дәрәҗәсенә җитә. Аның улы Ибраһим (1670–1780) исемле булган, ә Ибраһимнан Хөсәен, Җәгъфәр, Зәйни исемле балалар туган. Җәгъфәр исә галим, китаплар авторы[6].

Алиш нәселе шәҗәрәсенең ике варианты сакланып калган. Беренче варианты балалар язучы Абдулла Алишның олы апасы – Закирә Яруллинада (Әлки районы Иске Сәлмән авылы), 1974 елда М. Әхмәтҗанов аның күчермәсен ала. Икенче вариант XIX йөзнең икенче яртысына караган кульязма китап битләрендә язып калдырылган. Ул «Мирасханә» дә кол. 99, 1 тасв., 138 саклау берәмлеге шифры астында саклана. Шәҗәрәләр белгече М. Әхмәтҗанов бу ике вариантны да үз хезмәтләрендә бастырып чыгарды. Ике вариантта да Галишаһ нәселенең шәҗәрәсе Әлмәт (Әлмөхәммәд) улы ягыннан булганы сакланган. Кызганычка каршы, Тау ягында яшәп калган, олы улы Багдан ягыннан булган шәҗәрә варианты юк. М. Әхмәтҗанов «Нугай Урдасы» дигән китабында Багдан ыруы турында бу шәҗәрәдәгеләрнең килү тарихы да, кемнәр килүе дә мәгълүм түгел, асылы Богайз дигән карьядән [авылдан] килгән имеш, дип яза. М. Әхмәтҗанов күзәтүе буенча, Багдан исеме Татарстанның Буа ягындагы шәҗәрәләрдә генә очрый. Ахун авылы шәҗәрәсендә Багдан исеме дә, аларның Буа ягы татарлары белән кардәшлеге дә күренә. Тора-бара Багдан нәселенекеләр дә Болын ягына күчә, XX гасыр башында ул тарафка киткән Алиш нәселе тармагы белән якынлаша. Маһисәрвәр Богданова Көек авылы мулласы Нурулла хәзрәтнең улы Гаяз Алишевка кияүгә чыга. Нәселнең Богданов тармагы да халыкка атаклы шәхесләр биргән. Шулардан, күренекле педагог Гариф Богдановны атый алабыз[7].

Галишаһ морзаның Болын ягындагы нәсел тармагы да бик күп атаклы шәхесләр биргән. Мәсәлән, Алиш бәкнең алтынчы буын вәкиле мелла Гобәйдулла бине Җәгъфәр бине Ибраһим бине Сөрмәт бине Әлмәт бине Алыш әл-Казани әл-Әлмәти. Ш. Мәрҗани аның бабалары Тәтеш өязенең Шонгаты авылыннан күчеп килеп, Иске Әлмәт карьясенә нигез салганнар, дип яза. Гобәйдулла ишан Каргалый Вәлид ишанлыкка рөхсәт алып, Кизләү авылына имам, хатыйб һәм мөдәррис булып килә, гомере бу авылда үтә. Бу хәзрәт үзе дә татар дөньясына билгеле булган шәкертләр тәрбияләгән. Алар Габделҗәлил бине Җәгъфәр әл-Пәрави, Коръән укучы Габделҗәббар бине Габделкәрим әл-Әлмәти, Габделваһаб бине Иманколый бине Мансур бине Морад-

[6] Заһидуллин И. К. Алишев С. Х. Галишаһ морза нәселе // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 4. – Б. 169–172.

[7] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: персоналия. Т. 3. – Казань: Школа, 2014. – С.16–17.

гали әр-Рәҗәби һәм башкалар. Хәзрәт Кизләүдә 1822 елда вафат. Гобәйдулла хәзрәтнең Нигъмәтулла, Рәхмәтулла, Мөхәммәд исемле уллары булган. Хәзрәтнең эшен анын икенче улы Рәхмәтулла дәвам итә. Ул да укымышлы кеше булган, атаклы Габдерахман әл-Каргалыйдан гыйлем алган, хаҗи Вәлиэддин әл-Багдадидан Коръәнне яттан уку серен өйрәнгән. Ул 1844 елда бакыйлыкка күчкәннән соң, Кизләү авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе булып кече энеләре Мөхәммәд хәзрәт кала. Мөхәммәд хәзрәт шәехлек белән дә шөгыльләнгән.

Гобәйдулла хәзрәтнең олы улы Нигъмәтулла хәзрәт исә, Яңа Әлмәт авылында имам-хатыйб, мөдәррис булып тора, шулай ук шәехлек итә. Халык арасында ул Әлмәт ишан буларак таныла. Ул гыйлем алуын атасы Гобәйдулла хәзрәттән башлый, аннан Габдрахман Каргалый, мелла Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытида дәвам итә. Абыйсы кебек үк Вәлиэддин әл-Багдадидан Коръән уку серләрен өйрәнә. Үзеннән соң хөрмәтле муллалар булырлык шәкертләр тәрбияләп калдыра[8]. 1852 елда Әлмәт авылында вафат була[9]. Ш. Мәрҗани Нигъмәтулла хәзрәтнең мелла Хәйрулла, мелла Сибгатулла, мелла Сөнгатулла исемле уллары булуы турында яза. Мелла Сибгатулла хәзрәтнең үзеннән алда вафат булган. Ә Р. Фәхреддин балалары буларак Гатаулла һәм Хәйрулланы күрсәтә[10]. Аның тагын бер улы Нурулла исемле булган, ул Иске Әлмәттән хәзерге Спас районына караган Көек авылына күчеп килә һәм анда имамлык итә. Сакланып калган шәҗәрә нәкъ менә Нурулла исемле улы тармагы белән дәвам итә. Нурулла хәзрәтнең улы Габделбарый, ә Габделбарыйның улы балалар язучысы Абдулла Алиш (1908–1944). *Габделбарый Нурулла улы* мулла баласы буларак белемле кеше, газета-журналлар яздырып укыган, татар һәм көнчыгыш әдәбияты белән яхшы таныш булган. Әмма мәдрәсәдә белем алып мулла дәрәҗәсенә ирешә алмый кала. Патша армиясендә денщик булып хезмәт итә, аннан гарипләнеп кайта, 1934 елга кадәр яши. Абдулла Алишның әнисе дә иҗади кеше булган, ул да шигырьләр язган. *Абдулла Алиш* (*1908–1944*) хәзерге Спас районына караган Көек авылында туа, укырга Янбахты авылы мәдрәсәсенә китә, 1917 елда инкыйлаб башлангач, мәдрәсә ябыла. Беркүпмедер авылында торгач әтисе аны укырга Спас шәһәрендәге педагогик техникумга илтә. 1923–1927 еллар аралыгында анда белем ала, аннан укуын Казанда дәвам итә. Талантлы егет журналистикага кереп китеп үзен балалар язучысы буларак таныта. Сугышта җәлилчеләр белән бергә фашистлар тарафыннан җәзалана.

---

[8] Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б 293–294.

[9] Ш. Мәрҗани вафат булуын 1852 ел дип күрсәтсә, Р. Фәхреддиндә 1853 ел күрсәтелә. Һиҗри ел исәбе белән вафат булу елы 1269.

[10] Фәхреддин Р. Асар. Икенче том. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 56.

XIX гасырның урталарыннан алып Колбай Мораса[11] авылының беренче мәхәлләсе белән дә Алишевләр нәселеннән чыккан имамнар җитәкчелек иткән. Тарихчы Р. Г. Насыйров санавы буенча, XVIII гасыр ахырыннан алып 1920 елларга кадәр Алишевлар нәселе кырыктан артык дин әһеле биргән.

М. Әхмәтҗанов китапларында Алиш бәк шәҗәрәсенең икенче тармагының башында Көмәч баба бирелә, бу линия хәзерге Кайбыч районына караган Кече Кайбыч авылы имамы Төхвәтулла хәзрәткә барып тоташа.

*Төхвәтулла хәзрәт* Зөя өязе Кече Кайбыч авылында имамлык итә. Тирәякта хөрмәтле имам булган кеше, Хаҗ сәфәренә киткән җиреннән вафат була. Аның өч улы – кечкенә сабыйлары ятим кала. Төхвәтулла хәзрәтне яхшы белгән, аны хөрмәтләгән бер мулла бу сабыйларны үзенә сыендыра. Мотыйгулла кечкенәдән мәчет каршында тәрбияләнгән бала буларак, балачактан Коръән сүрәләрен өйрәнә.

*Мотыйгулла хәзрәт (1846–1920)* Зөя өязенә караган Кече Кайбыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылында мәдрәсәдә укыганнан соң укуын дәвам итү өчен заманының атаклы уку йортларының берсе – Кышкар мәдрәсәсенә укырга китә, аннан Каһирәдә белем ала. Каһирәдә укуын тәмамлап, туган ягы – Кайбычка кайтып барганда, Казакъстан ягындагы Җаек шәһәрендә яшәүче апасына кунакка кергән җиреннән аны шунда мулла итеп калдыралар. Мәдрәсә оештыра, аннан бу мәдрәсәне аның исеме белән «Мотыйгия» дип атыйлар. «Мотыйгыя» мәдрәсәсе шул заманда татар дөньясында данлыклы уку йорты буларак билгеле. Шунда калып, гаилә корып, 7 бала тәрбияли. Хәтта бер баласына Кышкарда бергә укыган Мөхәммәдгариф Тукай истәлегенә Мөхәммәдгариф исеме бирә. Дусты вафатын ишеткәч, аның улы – булачак бөек шагыйрь Г. Тукайны үз куенына сыендыра[12]. Габдулла Тукай бу гаиләдә Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил белән бертуганнардай үсә.

Ул әле музыкаль хәзрәт буларак та билгеле, кызлар хоры булдырган, җырлар язган. Аның музыкальлелеге балаларында ачылыш ала. Кызы Галия Кайбицкая татар музыка сәнгатендә танылган шәхес.

*Камил Мотыйги (1883–1941).* Камил Мотыйгулла улы Төхвәтуллин Җаек шәһәрендә мулла гаиләсендә дөньяга килә. Кечкенәдән үк яхшы гыйлем алырга омтыла. Алдан әтисенең «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый, аннан атаклы «Касыймия» мәдрәсәсендә, ә укуын алга таба Каһирәдәге атаклы уку йорты «Әл-Әзһәр»дә дәвам итә. 1902 елда туган ягына әйләнеп кайтып, әтисе мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшли башлый. Гарәп теле, мантыйк, Коръән тәфсире, хәдис, фикһ һәм башка предметларны укыта, хәтта Г. Тукай да аңар-

[11] Татарстан Республикасының Нурлат районы.
[12] Туган җирем – Кайбычым. – Казан: Идел-пресс, 2007.

дан белем алган. Мәдрәсәдә фикердәшләре белән бергә «Мәгариф», «Әлгасрелҗәдид» исемендә кулъязма газеталар чыгара. Г. Тукай белән якынлашуы да шуннан башлана. Табигатьтән бирелгән таланты аны музыка юлына китерә. 1909 елда Саратов шәһәренә барып, вокал дәресләре ала. К. Мотыйги ике дистәләп татар җырын нотага салып яздыра[13].

*Галия Кайбицкая (1906–1993)* Җаекта дөньяга килә. Көнчыгыш музыка техникумына укырга керә, Салих Сәйдәшевтән дәресләр ала. Алга таба татар сәнгатенең күренекле шәхесләре: Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, Хәлил Әбҗәлилев, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская белән белән иҗат юлын үтә. 1934 елда Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршында *Хәмит Төхвәтуллин* (бертуган абыйсы) җитәкчелегендә ачылган беренче татар опера студиясендә бер төркем татарның талантлы яшьләре: Ситдыйк Айдаров, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатова, Усман Әлмиев, Сара Садыйкова, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Асия Измайлова, Зөһрә Байрашева белән бергәләп белем алып кайтып, труппа составында Казанга кайта. Озак еллар Опера театрында татарга хезмәт итә. «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», К. Тинчуринның «Кандыр буе», Т. Гыйззәтнең «Наемщиг»ында, Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» музыкаль спектакльләрендә уйный.

Кайбыч районында якташлары аның истәлеген мәңгеләштереп музей ачалар.

*Сәлам Алишев (1929–2015).* Алишлар нәселенең тагын бер тармагы Чистай өязе булган җирләрдә дәвам иткән, ул тармагыннан да атаклы шәхесләр чыккан. Шундыйлардан, тарихчы-галим Сәлам Хатыйп улы Алишев. Ул нәселдәге Алиш бабаның исемен фамилиясендә ерак чорга кадәр алып килгән. С.Х. Алишев Чистай районының Шәрбән авылында дөньяга килә. Татар халкының урта гасыр тарихы буенча зур белгеч-галим булып җитешә. Ул 17 монография, 250 дән артык фәнни хезмәт авторы. Алишлар нәселенә багышлап «Галишаһ морза нәселе» дип исемләнгән роман-хроника авторы[14]. Ул бу хезмәттә Алишлар нәселенең илдәге болганчык чор вакытыннан алып аларның имамлык итүләре, халыкка аң-белем бирүләренә кадәр тарихи-әдәби тел белән кызыклы мәгълүмат биргән хезмәт.

*Азат Сөнкишев (1944)* – танылган журналист. Ул Әлки районы Иске Сәлмән авылында дөньяга килгән. 1968 елда Апас районының «Йолдыз» («Звезда») исемле газетасына эшкә килә, шул еллардан башлап Апас төбәгенең

[13] Мәһдиев М. Революция дулкыны белән // Мәһдиев М. Әдәбият һәм чынбарлык. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – Б. 298–303.

[14] Алишев С. Галишаһ морза нәселе. Роман-хроника. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. – 559 б.

тарихын, аның атаклы шәхесләрен өйрәнеп күпсанлы китаплар авторы буларак таныла. Ул Алиш бәк нәселенең күренекле әгъзасы[15].

Алиш нәселенең исемен фамилия итеп Алишбәкнең җиденче буын дәвамчысы – Көек авылының имам-хатыйбы Нурулла хәзрәтнең улы, язучы Абдулла Алишның әтисе Габделбарый (1871–1935) йөртә башлый. Белүебезчә, татарлар элекке заманнарда фамилия йөртмәгәннәр, аңа ихтыяҗ да булмаган. Кирәк булган очракта фамилия итеп бабаларының исемнәрен алганнар. Ихтыяҗ туу сәбәпле, хәрби хезмәт үткән Габделбарый Алиш бабасы исемен фамилия итеп ала[16].

Төбәк тарихын өйрәнүдә нигез итеп нәсел шәҗәрәләрен алу, нәсел таралуын күрсәтү отышлы юлларның берсе дип саныйбыз. Әлеге нәсел мисалында гына да тарихның эзлекле вакыйгалардан торуы, нәселнең ныклыгы тарихның тулы бер этабында зур роль уйнаганы күренә. Затлы нәсел ничә гасырлар дәвамында да җәмгыять өчен файдалы, күренекле шәхесләр бирә ала. Бу нәсел дә шуңа мисал. Галишаһ нәселе илнең икътисадый, иҗтимагый, мәдәни тормышында да үзенең эзен калдырган. Тау ягының затлы нәселенең берсе – Галишаһ дәвамчылары ил тарихында билгеле шәхесләр.

[15] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: персоналия Т. 3. – Казань: Школа, 2014. – С.188–189.

[16] Сункишев А. Апастовская историко-краеведческая энциклопедия: персоналия. Т. 3. – Казань: Школа, 2014. – С.16–17.

## § 2. Мортазиннар – имамнар һәм галимнәр биргән нәсел

Гап-гади авылның гап-гади имамы Мортазиннар нәселе мисалында бу төбәкнең рухи тормышын, кешеләренең катлаулы, хәтта ачы язмышын һәм авырлыкларны җиңеп чыгып, татар тарихына биргән күренекле шәхесләре турында хикаять итү мөмкин.

Казан губернасының Тәтеш өязенә караган Яңа Чәчкап (хәзерге Буа районына керә) авылы тирә-як авыллардан берни белән дә аерылып тормый, гомер-гомергә игенчелек белән көн күргән, халкы бик күп татар авылларына хас булганча, гади, тыйнак тормыш иткән. Әмма бу авыл совет чорында да тирә-якта рухи тотрыклыгы белән аерылып торган. Әлбәттә, рухи тотрыклык булсын өчен аның ныклы нигезе булу кирәк. Әлеге авылның рухи нигезе борынгы заманнардан ук салынган, бу авылда имамлык иткән муллалар нәселе һәм аларның рухи тормыш үсешенә керткән өлеше бихисап. Бу авыл үз тарихында, безгә мәгълүм документларның хәбәре буенча, шундый ике династия бирә. Озак вакытлар авыл бер мәхәлләле булган, халык саны артып ике мәхәллә төзү мөмкинлеге булгач, авылның ике мәчетендә дә Мортазиннар имамлык иткән.

Бикмулла мулла авылда хәзрәт булган вакытта тирә-якта бу авылның даны тарала, шәкертләр хәзрәт оештырган мәдрәсәгә ерак-еракладан җыелып килеп белем алганнар. Заманы өчен бу мәдрәсә шактый зур була, архив документлары биредә 80 нән артык шәкерт укыганын күрсәтә[1]. Мәдрәсә остаз булган җирдә, халыкның рухи үзәге саналган авылларда гына ачыла алганны исәпкә алсак, бу – игътибарга лаеклы күренеш. Тау ягындагы зур мәдрәсәләр тарихы хакында, кызганычка каршы, мәгълүматлар юк диярлек, бары тик аерым искәрмәләр аша гына аларның булуы хакында фикер йөртә алабыз. Шуңа бер мисал итеп, түбәндәге вакыйганы китерергә була.

М.Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедиция тарафыннан Буа районы Түбән Наратбаш авылында бер кульязма табыла. Әлеге кульязманың авторы болай дип яза: «Ошбу китап мартның егерме өченче көнендә [елы күрсәтелмәгән – иск. авторныкы] кече җомга көнендә аш вакытында тәмам булды. Язгучы Фәхретдин Биккол дип белерсез. Хәер-дога кыласызлар. Ошбу китапны Яңа Чәчкап авылының дамелла Бикмулла мәдрәсәсендә яздым, мин Фәхретдин Түбән Наратбашның Биккол угылы»[2]. Түбән Наратбашы Буа шәһәренә бик якын урнашкан авыл, шәкерт Буада күпме танылган мәдрәсәләр була торып та, Буаны узып, аның аргы ягына китеп, Яңа Чәчкап

---

[1] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 9255 эш, 3 кгз.

[2] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – 2 нче басма, тулыл. Казан: Татар. кит.нәшр., 1994. – 463 б.

мәдрәсәсенә белем алырга килгән икән – бу инде Бикмулла дамелланың авторитеты, аның остазлык дәрәҗәсен күрсәтә торган фактор. Бикмулла хәзрәтнең кайчан бу мәхәлләгә билгеләнүе, аның хәлфәлек елларын раслар-лык документлар сакланмаган. Ул якынча XIX йөзнең 20 елларыннан 1845 елга кадәр мәхәлләгә халкына хезмәт иткән булырга тиеш.

Бикмулла дамелла нигезләгән мәдрәсә, ул мәчетнең көнчыгышында урнашкан бина, заманының мәгърифәт учагы булып Бикмулла мулладан соң да ул бик озак еллар халыкка хезмәт итә, 1933 елга кадәр совет мәктәбе буларак эшли[3]. Бу мәктәпнең беренче укытучысы танылган педагог Шәриф Сайкин, аның белән бергә 1919 елның 14 февраленнән Шәрәфетдин Сәхипов укытучылык иткән[4].

1845 елда аның урынына хәзрәтнең улы Рәхмәтула билгеләнә. Рәхмәтулла хәзрәт 1874 елның 12 февралендә 57 яшендә дөнья куя[5]. Рәхмәтулланың улы Мирзаҗан (1872 елның 9 июлендә туган)[6] хәзерге Югары Ослан районына керә торган Татар Макылы авылына мулла итеп куелган[7]. Шулай итеп, әлеге династия үз эшчәнлеген бу авылга күчереп, бу авыл халкының да хөрмәтен казана[8]. Мирзаҗан имам соңгы көннәренә кадәр шул авылда яшәп, 1910 елда дөнья куя. Макыл авылы зиратында ташлы язуы да сакланган. Миржан хәзрәтнең шәхси китаплары мирас буенча энесе Хәнәфигә күчә, алга таба әлеге китаплар Хәнәфинең оныгы Сәяр Айдаровка – атаклы артист Ситдыйк Айдаров һәм Галия Кайбицкаяның улына мирас булып килепирешә. Сакланып калган китапның беренчел хуҗасы Яңа Чәчкап авылының Бикмулла хәзрәт булуы, аннан кемнәргә күчүе әйтелгән. Бикмулла хәзрәт вакытыннан ук эшләп килгән мәдрәсә бинасы 1930 нчы елларда да әле сакланган була.

Яңа Чәчкап авылы тарихында хөрмәтле урын биләгән, авыр елларда аларның терәге булган, хәзерге көнгә кадәр «мулла абзый» дип ихтирам белән искә алынучы мулла нәселенең башлангычы – Мортаза Фәтхулла улы Фәизев. Ул тумышы белән хәзерге Арча районына керә торган Сөрде авылыннан. Билгеле булганча, гадәттә хезмәт өчен имамнар туган авылыннан читтәге җирләргә билгеләнгән. Шулай итеп, Мортаза Фәтхулла улы, ул заман өчен шактый ерак булган Буа төбәгенә хезмәткә җибәрелә. Гаиләнең терәге булган Мортаза үзе белән олы яшьтәге әти-әнисен дә бирегә алып килә. Әнисе Мәхүбҗәмал Баязид кызы 1878 елда[9], әтисе Фәтхулла Нигъмәтулла

---

[3] Туган туфрак җылысы /Төз. Н.Бикмуллин. – Казан: Матбугат йорты, 2000. – 326 б.
[4] ТР ДА, Р 1348 ф., 1 тасв., 11 эш, 194 б, 195 кгз.
[5] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 52 эш.
[6] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 7498 эш, 13 кгз.
[7] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 7498 эш.
[8] Галимов К. Макулово авылы тарихы. – Казан: Алма-мет, 2006. – 186 б.
[9] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 60 эш, 60 кгз.

улы 1887 елда[10] Яңа Чәчкапта гүр ияләре булалар. 1881 елда бала тапканда үлгән 32 яшьлек хатынын да биредә җирли ул[11].

Мортаза Фәтхулла улы килгәндә авылның 1818 елда төзелгән мәчете шактый искергән була, 1887 елда мулла һәм мәхәллә халкының тырышлыгы белән 390 ир-аты булган авылга яңа мәчет салырга рөхсәт алына[12]. Авыл халкының бу нияте бик тиз тормышка ашырыла, һәм 1888 елда авылда инде заманы өчен шактый зур һәм нык булган мәчет эшли башлый, бу мәчеткә 1908 елда төзекләндерү эшләре үткәрелә[13]. Бу мәчет совет заманында барлык мәчетләргә төшкән афәтне – манарасы киселүне дә кичерә, клуб булып хезмәт иткәндә дә ул авыл кешеләренең җанын сыкрата. Совет заманының соңгы елларында, әле күп төбәктә халык мәчеттә гамәл кылырга җөрәәт итмәгән вакытта, авыл мулласы Габдулла Сәлахетдин улы авылдашлары белән аны сүтеп, зират территориясенә күчереп салып, бинаны үз вазифасына кайтаруга ирешә, шулай итеп тарихи бина хәзерге көннәргә кадәр сакланып кала.

1908 елда 64 яшен тутырган Мортаза мулла инде үзенә ярдәмче итеп 1884 елда туган улы Ибраһимны ала[14]. Ибраһим Мортазин 1908 елның 4 апрелендә, атасы исән вакытта ук, Диния нәзарәтеннән имамлыкка Указ алып мәхәлләгә икенче мулла буларак билгеләнә. Имам булырга рус теле таләп ителгәнлектән, Ибраһим хәзрәт Буада өчьеллык училище да тәмамлый[15]. Ибраһим мулла имамлык иткән елларны татар тарихы авыр вакыйгалар кичерә: татар тарихының иң фаҗигале вакыйгасы – чукындыру дигән афәт бу мәхәллә халкын да кызганмый. Авылның бәхетенә каршы, керәшен дигән катламы бары тик кәгазьдә генә булса да, бердәм яшәгән мәхәллә халкын икегә бүлеп уза. Чынлыкта исә, чукындырылган саналып та ислам гадәтләрен тоткан гаиләләр мәчеткә йөрү хокукыннан мәхрүм була, аларны авылның мөселман зиратына да җирләми башлыйлар. Шушы килеп туган күңелсез хәлдә мулла абзый үз сүзен әйтергә, мәхәллә халкы арасында тынычлык сакчысы булырга тиеш була. Бу авыл хәтерендә нәселләргә «чукынган», дигән ярлык тагылып калмаган, халык бу караңгы елларны искә төшерергә яратмый, хәтта аның турында сөйләшергә кирәкмәгәнлеген күңелендә аңлый икән – бу, һичшиксез, авыл мулласының акыллы сәясәт нәтиҗәсе[16].

---

[10] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 377 эш, 146 кгз.

[11] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 182 эш, 137 кгз.

[12] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 3477 эш, 1–4 кгз.

[13] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 9255 эш, 7 кгз.

[14] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 245 эш, 150 б. кгз.; 2 ф., 2 тасв., 8138 эш, 1–7 кгз.

[15] ТР ДА, 2 ф., 2 тасв., 520 эш.

[16] Сәлахова Э. К. Мулласы нинди-мәхәлләсе шундый //Мусульманские духовные лица в социальном и духовном развитии татарского народа (XVII – начала XIX вв.). Сб. статей. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ; Изд-во: Яз, 2014. – 139–147 бб.

XX йөз башында авыл халкы санының артуын һәм дә яз көннәрендә авылны икегә бүлеп аккан елганың ташуыннан юл эзелеп, авылның 78 йорттан торган өлеше озак вакытка мәчеткә йөрүдән мәхрүм калуын күрсәтеп, 1913 елда икенче мәхәллә оештырырга рөхсәт алына[17]. Бу мәчеткә мулла итеп Мортаза хәзрәтнең кече улы – 1886 елда туган Габделвәли билгеләнә[18]. Бу мулланы Коръәнне яттан белгәнгә авыл халкы «Коръән хафиз» дип атап йөргән. Габделвәли абыйсы Ибраһимнан аермалы буларак, һәм XX йөз башы татар яшьләре рухында тәрбияләнгәнлектән, шактый прогрессив, яңалыкка омтылучы мулла була. Бабаларыннан килгән традицияне дәвам итеп, мәхәллә халкына дини тәрбия дә бирә, укыта да, шул ук вакытта әле дә аның авыл халкын шаккаттырып, балаларны ияртеп, авыл буйлап велосипедта җилдерергә яратуын да искә алып сөйлиләр[19]. Габделвәли хәзрәт иртә вафат булган, 1932 елда бакыйлыкка күчкән мулла туган авылы зиратында җиргә иңдерелә. 1930 еллар афәтен аның хатыны, балалары кичерә. Хатыны Хәлимә абыстай хәзерге Чуашия республикасына карый торган Урмай авылыннан булган. Гаиләне өйләреннән куып чыгаралар, өен сезонлы бабалар бакчасы итәләр, аннан йортын яңа урынга сүтеп күчереп салалар. Йорт озак еллар авыл советы бинасы булып тора. Ул имамлык иткән мәчет 1918 елда салынып бетеп, 20 ел эшләп кала әле, 1938 елда манарасы киселә һәм җидееллык мәктәп итеп үзгәртелә, бина бу функцияне бик озак үти, бары тик 1990 еллар ахырында гына ул сүтелә.

Әлбәттә, Яңа Чәчкап авылының ике мәхәлләсендә имам булып торган Ибраһим хәзрәт Мортазинның ике улы да совет вакытындагы аяныч язмыштан читтә кала алмый, ул язмышны хәтта трагедия дип тә бәяли алабыз.

Татар тарихында киләчәктә көтелгән фаҗигале хәлләр дулкыны авылның терәге булган «мулла абзые»нда читләтеп үтми, 1940 елда контрреволюцион эш алып баруда гаепләнеп, кулга алына, һәм шуннан авылга башка әйләнеп кайтмый. Мулланың кечкенә генә йортын да тартып алалар. Балалары читкә – Урта Азия якларына чыгып китәргә мәҗбүр була. Бу вакыйгаларның нәтиҗәсен үзе күреп белгән шагыйрь Әхмәт Рәшитов «Өзек чылбыр» дигән шигырендә болай дип яза:

«... Ике мәхәлләдән ике туган –  
Мортазиннар читтә үлделәр.  
Бер гаепсез. Гәрчә икесе дә  
Ярлылардан да ярлы иделәр.  
Иман бар да, ләкин имана юк –  
Асрап булмый хәтта сарык та...

[17] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 9255 эш, 1–13 кгз.  
[18] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 249 эш, 135 б. кгз.  
[19] Туган туфрак җылысы /Төз.Н.Бикмуллин. – Казан: Матбугат йорты, 2000. – Б.57.

Бөтен керем – аз-маз садакадан –
Ни аласың гидай халыктан...
НКВД зинданнары илнең
Ак уйларын йота торганда,
Мулла Ибраһимның карт карчыгы
Хәер эстәп йөрде урамда... »[20].

Мортазин муллаларның авылдашы, шулвакытта бу гаиләне хәтерләп белгән Әхмәт Рәшитев шигырендә үзенең генә хисләрен түгел, ә авыл халкының авыр кайгысын чагылдыра. Шигырьдә искә алынган фаҗигале язмыш – абыстай Мирател Каимәтел Бибинур, ул Кошман (Апас районы) авылы мулласының кызы. Улы Фоат әтисен эзләп берничә тапкыр Пләтән төрмәсенә дә барып карый, әмма мулла абзыйны башка беркем дә күрми. Авылдашлары аны «үтә дә беркатлы, фәкыйрьлекнең чигенә җиткән кеше»[21] буларак хәтерләрендә саклыйлар.

*Мортазиннар нәселенең дәвамчылар.*

Мортаза хәзрәт Фәтхулла улының (1843–1908) ике никахыннан билгеле имамнар Ибраһим (1884 елда туган) белән Миңлегабделвәлидән (1886 елның 10 октябрендә дөньяга килгән, туганда кушылган тулы исеме) тыш, тагын 13 баласы туган, шуларның күбесе балачакта ук вафат булган. Мортаза хәзрәтнең 1903 елда туган иң кече кызы 18 яшьлек Бибигайшә 1923 елның 30 ноябрендә Тәтеш өязе Күзби авылы (Буа районы) Габделхак хәзрәт улы 22 яшьлек Хөҗәтуллага никахландырыла. Яшьләргә Кужак (Буа районы) мулласы Шакирҗан Бикмөхәммәтев никах укый, кияү ягыннан вәли вәкил булып кияүнең атасы Габделхак Габдрахманов, килен ягыннан Яңа Чәчкап авылының икенче мәхәллә имамы, киленнең бертуган абыйсы – Габделвәли Мортаза улы катнаша. Ризалык шаһидләре Сәлахетдин Сәгъдетдин улы һәм Гыймран Ибраһим улы булалар, ризалык шаһидләренең исемнәреннән аңлашылганча, алар Габделвәли Мортаза улының күршеләре, димәк никах Габделвәли хәзрәт өендә узган дип уйларга нигез бар[22]. Әлеге никахтан 1926 елда Буа районы Күби авылында *Вахит Хөҗҗәт улы Хаков (1926–2008)* дөньяга килә. Тел белеме өлкәсендә атаклы галим, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны, профессор, бик күп фәнни хезмәтләр авторы. Ике яклап мулла нәселе дәвамчысы булган В. Хаковның язмышы гади генә булмый. Яңа Чәчкап муллалары Мортазиннарны өйләреннән куып чыгарып сөргенгә сөргәч, алар сеңелләре Бибигайшәне дә куркыныч язмыштан саклап калу өчендер инде, үзләре белән Урта Азия ягына алып китәләр. Әмма 9 айлык кына булган Вахит атасы белән кала, бәлки әнисе аны вакытлыча гына калдырып торган булгандыр, ә язмыш

[20] Рәшит Ә. Язмыш җилләре. – Казан: Татар.кит.нәшр, 2006. – Б 132–134.
[21] Бикмуллин Н. Яңа Чәчкап авылы: ата-баба нигезе. – Казан, 2021. – 148 б.
[22] ТР МА, Р-2780 ф., 1 тасв., 369 эш, 87 кгз.

үзенчә хәл итә. Вахит ага үги ана белән үсә, ә үз анасы белән дә бик соңлап кына очраша. Әнисе инде башка үз туган җиренә кайта алмый, Үзбәкстан ягында яңа гаилә кора, ул никахтан 3 ир бала дөньяга килә. Бу никахтан туган балалары да танылган шәхесләр булып җитешәләр – алар математика белгечләре, фән докторлары. Вахит аганы язмыш әнисенең туган авылы – Яңа Чәчкапка китерә, ул сугыштан кайткач бу авылда беркүпмедер укытучылык итә, аннан күрше авыл – Бик Үтидә завуч булып эшли. В. Хаков биографиясендәге бу елларны бик искә алырга яратмый иде, чөнки күңелендә соңгы көннәргә кадәр язмышның бу тирән ярасы төзәтелеп бетмәгән, күрәсең. Метрика дәфтәрләреннән бөртекләп җыелган Мортазиннарның нәсел шәҗәрәсәсен дә, Вахит ага аңа үзенең мөнәсәбәтен дә холкына нисбәтле итеп бик тыныч кына кабул иткән иде, моны төпченеп шәрехләүне дә кирәк санамады. Аның күңел халәте, әлбәттә, аңлашыла.

Ибраһим хәзрәтнең улы *Фуад Мортазин* (1924 елда туган) татар журналисты буларак билгеле. Ул Казан шәһәрендә техникум тәмамлый, аннан соң педагогика университетында белем ала, педагогика фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешә, аннан туган төбәге Алших, Норлат авылларында укытучылык итә. Соңгы елларда Ялта шәһәрендә яшәде, актив журналистик хезмәт алып барды. Матбугатта мәкаләләләре, шигырьләре басылып торды. Авыл аның фаҗигале язмышы белән бәйле булса да, туган авылына кайтып йөрде, Бөек җиңүнең 70 еллыгында да катнашып, мәктәп музеена китапларын да бүләк итте. Авылдашлары хәтерендә ул, «искиткеч белемле һәм эрудицияле кеше» буларак саклана[23].

*Марат Фәхреислам улы Мортазин* (1957 елның 26 декабрендә туган) – икенче мәхәллә имамы булган Габделвәли хәзрәт оныгы, Казан шәһәрендә дөньяга килгән. М. Мортазин фәлсәфә фәннәре докторы, имам бабаларының эшен дәвам итеп, ислам тарихын өйрәнгән белгеч. «Гарәп филологиясе» белгечлеге буенча Ленинград дәүләт университетының көнчыгыш факультетын тәмамлый, тәрҗемәчелек, мөгаллимлек итә. Мәскәүдә ислам колледжы (1994–1999), Мәскәү ислам университеты (1999–2012) ректоры була. Авыл белән аралар фаҗигале рәвештә эзелгән булса да, М. Мортазин имам бабаларының нәсел нигезен зыярәт итте, каберлекләрне тәртипкә китереп, чардуганнарын яңартты.

Марат Мортазинның атасы – мулла баласы *Фәхреислам* атасыннан иртә ятим калып, Хәлимә абыстай тәрбиясендә үсә. Ул Казанда механика техникумында белем алып, сугыш вакытында авиация частьларында хезмәт итә, авылга кайтып атасы нигезенә йорт сала, аннан өйләнеп, Ашхабад якларына китеп бара, аннан киредән Казанга әйләнеп кайта. Йортсыз калуны да, 1930 елларның башка фаҗигаләрен дә үз җаны аша уздырган *Хәлимә абыстай* рухы беркайчан да сынмый. Авылда да абыстай вазыйфаларын үти, аннан

[23] Бикмуллин Н. Яңа Чәчкап авылы: ата-баба нигезе. – Казан, 2021. – 148 б.

улы Казанга алып киткәч тә, бу миссиясен дәвам итә. Ул Казанда җирләнгән. Имам нәселе дәвамчысы – *Фәхреислам Мортазин* матбугат эшчәнлеге дә алып бара. Аның олы улы *Мәрван ага* да техник белемле белгеч булып җитешә.

Мортазиннар нәселенең бер өлеше мәгълүм сәбәпләр аркасында, Урта Азия якларына чыгып китәргә мәҗбүр була, шунда гомер итәләр дә. Ибраһим мулланың олы кызы – Фәһимә (1918 елда туган) Ташкентка китеп урнаша, кече улы Һарун Бохарада югары белем алып, авыл хуҗалыгы техникумында уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли, фәннәр кандидаты. Кызганычка каршы, пенсия яшенә барып та җитмичә, вафат була. Ибраһим мулланың Исмәгыйль исемле улы туган ягында кала, аннан сугышка алынып, фронт кырларында һәлак, әмма аны Ватан сугышы елларында Мәскәүдә атып үтергәннәр дигән версия дә бар.

Җәдиди карашлы Габделвәли мулланың олы кызы Фәхирә (1918–1940) концертларда җырлап, авыл җирендә беренче булып куела торган спектакльләрдә төп рольләрне башкаручы чәчрәп торган бер кыз булып үсә, очучы егеткә кияүгә чыгып, Мурманск шәһәренә яшәргә китә, әмма беренче баласын тапканда бакыйлыкка күчә.

Хәзерге вакытта авылда Мортазиннар нәселе дәвамчылары калмаса да, алар нигезләгән рухи ныклык калган, авыр елларда да рухи түбәнлеккә юл куелмады. Рәсми имамлык итә алмаган елларда да, дини гадәтләр үтәлде. Мортазиннардан соң муллалык иткән Кәлимулла Ибраһимов – атаклы Акъегет мәдрәсәсен тәмамлаган шәкерт була. Тау ягының гына түгел, ә татар дөньясында билгеле булган бу уку йортында белем алган шул авыл кешесе булган икән, бу инде, үз чиратында, авылның рухи дәрәҗәсен күрсәтә торган билге.

Җәмгыятьнең рухи тормышында һәр авылның муллалары, имамнарының роле бихисап. Алар үзләренең мәхәлләләре, авыллары кысасында эш итеп тә татар җәмгыятенең сыйфатлы үсешен, белемен, әхлагын булдыручы төп көчләр. Авыл имамы салган нигез гасырлар дәвамында авыл халкының йөзен билгели торган күренеш. Шуңа да, татар җәмгыятен өйрәнгәндә, мәхәллә, авыл тормышы, аның әйдәүче көчләренең ролен билгеләү мөһим.

## § 3. *Тәтеш төбәгенең мәшһүр хатын-кызлары*

Тәтеш татар дөньясына танылган хатын-кыз шәхесләрне дә биргән төбәк. Танылган мәгърифәтчеләр, мөгаллимнәр, галимнәр бар икән, аларның уңышлары артында һичшиксез, аларны тудырган, аларга башлангыч нигез салган, тугры юнәлеш биргән аналары тора. Без аларның күбесенең исемнәрен дә белмибез, әмма аларның гамәлләре аларның уллары-кызларында чагыла, халык тарихында урын тота.

Әлбәттә, беренче чиратта Тәтеш төбәгенең мәшһүр хатын-кызларыннан дин өчен, иман өчен көрәшкән, ирләренә, балаларына бу авыр сынауда терәк булган, иман ныклыгы өчен бар көчен куйган аналарны атарга тиешбез. Гадәти тормышта да игенче гаиләсенең хатын-кызы батырлык кыла, тормыш авырлыгының бар булганы белән ир кеше белән тигез тарта. Ә килеп туган рухи авырлыкларда ныклык күрсәткән, карар кабул итә алган хатын-кызлар батырлыгы аерым бер тарих. Шундыйлардан, Тәтеш өязенең бик күп санлы имамнарын гомерлеккә дип Турухан төрмәсенә сөргәннән соң алардан сабый балалары белән ятим калган хатыннар, ирләре артыннан җәяүләп, гомергә китәселәрен белеп, ялгызлары чыгып киткән аналар да аерым ихтирамга лаек.

Кызларны укытуда, белемле итүдә бер тиен алмыйча, үз ихтыяры, үз мөмкинлекләре белән укыткан абыстайлар батырлыгын күрсәтми мөмкин түгел. Бәлки аларның белем бирүе дөнья таләпләренә җавап та бирмәгәндер, әмма аларның булуы – халыкның дәрәҗәсен күрсәтүче билге. Тәтеш мулласы – Хәсәнгата Бикташевның үзгәрешләргә, рус телен укытуга каршы булуы, моны яклаган, моңа матди яктан ярдәм иткән сәүдәгәрләр белән каршылыкка керүен тәнкыйтьләү берьяклы булыр иде. Гасыр дәвамында формалашкан укыту системасы, аның гадәтләре, инде ниндидер нәтиҗәләре булганнарга каршы чыгу, аны тамырыннан җимерүне, әлбәттә мулла кабул итә алмый, билгесез яңалыкны берсүзсез кабул итү аның өчен ул мөмкин дә түгел. Мулланың абыстае ире белән бер үк караштa торып, традицияне сакларга, аңа бу эштә ярдәм итәргә тырыша. Мулланы сөргенгә сөргәч тә, аның янына сөргенгә китеп, Тәтеш халкы белән мулла арасындагы арадашчы булып хатлар йөртә[1]. Бу да аларның дөньяга карашы, дөньядагы үзгәрешләрне кабул итү формасы, бу да үз чоры өчен батырлык таләп итә торган гамәл. Озак еллар буе татар җәмгыятендәге кадимчелек белән җәдидчелекне кара-каршы куеп, яхшы һәм начарга бүлеп карау, шул ракурста өйрәнү яшәп килде. Монда бу – яхшы, бусы – начар дигән бүленеш була алмый, булырга тиеш тә түгел, икесе дә халыкның күзаллавы, икесе дә аның фикере, икесенең дә уңай яклары булган кебек, икесенең дә тискәре моментлары да булган. Алга таба

[1] ТР ДА, 1 ф., 3 тасв., 11384 эш.

үсеш, үзгәрештә уртак фикер, җәмгыять өчен файдалы булганнарын алып алга бару гына кирәк.

Тәтеш төбәгенең аерым хатын-кызлары, аларның тарихтагы ролен караганда берничә ханым турында аерым сөйләү, аларның тәрҗемәи хәлендәге кызыклы фактларны күрсәтү, аларның гамәлләрен хикәяләү юлы белән баруны бурыч иттек.

Шундыйлардан, Маһруй Мозаффария – мөгаллимә һәм шагыйрә буларак татар тарихындагы мәшһүр шәхес. Маһруй Мозаффария Тәтеш өязе Олы Тормы авылының имамы Габделвәли мелла Габделсаттар улы гаиләсендә дөньяга килә. Анасы Зөя өязе Кече Кайбыч авылы имамы Төхвәтулла хәзрәт кызы – Хәйрениса. Төхвәтулла хәзрәт исә Габдулла Тукайның укытучысы булган Мотыйгулла Төхвәтуллинның атасы. Бу билгеле нәсел турында хезмәтнең Галишаһ нәселенә багышланган бүлегендә тулырак мәгълүмат бирелде. Маһруй абыстайның тәрҗемәи хәлендә ул 1873 елда дөньяга килгән дип күрсәтелә. Бу хезмәттә аның туу датасына, метрика язмасына нигезләнеп, төгәллек кертеләчәк. Тәтеш өязе Олы Тормы авылының 1872 елгы метрика дәфтәрендә Маһруйбикә 2 нче номер астында 1872 елның 15 гыйнвары белән теркәлә, аның тууын атасы – шул авыл имамы Габделвәли Габделсаттар улы терки[2]. Шул ук елның 20 нче мартында Габделвәли имамның Гөлмөнәвәррә исемле башка хатыныннан Фатыйма исемле кызы да туа[3]. Маһруй Мозаффариянең туу елы буларак йөргән 1873 елда аның сеңелесе – Гайшәбикә дөньяга килгән[4]. Маһруйбикә анасыннан бик иртә ятим кала. Маһруйбикә бик тырыш кыз булып үсә, апасына ияреп хәреф таный башлагач, аңа белем бирүне атасы үз кулына ала, аңа гарәп, фарсы, төрки телләр, дин гыйлеме буенча да дәресләр бирә. 15–16 яшендә инде өйдә үзе кызларны укыта башлый. Маһруй авылдашы – Күл буе мәдрәсәсендә белем алучы Зыятдин шәкерт белән дуслашып китеп, хәтта яшерен рәвештә хатлар да алыша башлый. Бу эшләр атасына килеп ирешкәч, атасы бу хәлгә каты киртә куя, Маһруйны үзенең яшьтәше булган Казан шәһәренең Печән базары мәчете Хуҗаәхмәд хәзрәт Мозаффаровка кияүгә бирә. 18 яшьлек ятим кызның икенче хатын буларак бу гаиләгә килгәч, аның вазыйфасы булып өй эшләрен алып бару да, хәзрәтнең авыру анасын, беренче хатынын, балаларын карау да, шуның өстенә мәхәллә эшләре, балалар укыту да була. Маһруй абыстай хәзрәтнең беренче хатыны вафатыннан соң аның балаларын да тәрбияли, аның үзенең дә өч баласы туа: кызлары Мәхмүдә (1893–1969), Габбаса (1898–1921) һәм улы Мансур (1902–1966)[5]. Маһруй Мозафарриянең улы Мансур Мозаффаров күренекле композитор буларак татар дөньясында билгеле шәхес.

[2] ТР ДА, 204 ф., 177 тасв., 48 эш., 164 кгз.

[3] ТР ДА, 204 ф., 177 тасв., 48 эш., 164 кгз.

[4] ТР ДА, 204 ф., 177 тасв., 50 эш., 245 кгз.

[5] Махмутова А. Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). – Казань: Татар. кн.изд-во, 2006. – С. 91–93.



Тәтеш өязе Олы Тормы авылының имамы Габделвәли мелла Габделсаттар улы (Маһруй Мозаффариянең атасы) тутырган метрика дәфтәре фрагменты.
ТР ДА, 204 ф., 177 тасв., 50 эш.



Мәһруй Мозаффариянең тууын теркәгән метрика дәфтәре. 1872 ел.
ТР ДА, 204 ф., 177 тасв., 48 эш.

Мәһруй Мозаффаррия үзенең 3 баласы, 2 үги баласы өчен генә ана булмыйча, татар җәмгыяте кызларының да анасы дип атый алабыз. Ятимлек ачысын татыган Мәһруй балаларга зур мәрхәмәт һәм мәхәббәт белән карый. Кыз балаларны үз өендә укыта башлаган Мәһруй абыстай, 1901 елдан Хәдичә Әхмәрева тырышлыгы белән ачылган мәктәптә кызларга белем бирә, татарларның мәктәпне рәсми исеменнән бигрәк, Мәһруй абыстай мәктәбе дип атап йөртүе – аның хезмәтенә бирелгән югары бәя.

Г. Тукайны үзенең кече энесе кебек яратып, аңа күңел җылысы биргән, Тукай да Мәһруй абыстайны якын икән. Мәһруй абыстай 1911 елда Кадер кичәсе уздырганда укучы балалар белән уку өчен Тукайдан шигырь язуын үтенгәч, Тукай чәчәкләр белән бизәлгән кәгазь кисәгенә язылган шигырен шул көнне үк алып килеп бирә. Г. Тукайга Мәһруй абыстайны матбугатта яклап та чыгарга туры килә, Романовлар династиясенең 300 еллыгы мөнәсәбәте белән уздырылырга тиешле мероприятиеләр буенча фикер төрлелеге килеп чыга һәм Һ. Атласи «Аң» журналында «Гимназияме, приютмы?» дигән мәкалә белән чыгыш ясый, анда ул Мәһруй абыстайга да тел тидергән була. Тукайга хас булганча, сүз белән бик оста итеп барысын да үз урынына куя. Мәһруй абыстай да Тукайга авыр вакытларында ярдәм кулы сузган, Мәһруй абыстай шагырьнең соңгы көннәрендә дә янында була. А. Мәхмутова Мәһруй абыстайның кызы – Мәхмүдә ханымның истәлекләренә таянып, Г. Тукайның вафатыннан соң калган киемнәре дә Мәһруй абыстайда сакланган, дип яза. Г. Тукай вафатыннан соң ук Мәһруй абыстай Г. Тукайның татар хатын-кызлары дөньясына тәэсире хакында «Мәктәп» журналында мәкалә язып чыга.

Мәһруй абыстайның гомеренең зур өлеше Казанда узса да, язмышы туган ягы Тәтеш белән араны өзми. Инкыйлаб елларында Казанда оешкан «Тәтеш өязе мөселман җәмгыяте» эшчәнлегенә бертуган Шәрәфләр һәм башка якташлары белән бергә шәрәфле Мәһруй абыстайны да җәлеп итәләр. Казанда Тәтеш өязе мөселманнары оешмасы рәисе, газета мөхәррире дә Гыйльметдин Шәрәф (1885–1942) булган. Ул тумышы белән Тәтеш өязенең Аксу (халык телендәге исеме – Кишер Аксуы) авылыннан.

1917 елның 15 нче маенда бергәләп «Тәтеш оешмасы» исемле газета ачып җибәрәләр, газета «Йир һәм ирек!» шигаре белән 1917 елның 22 нче декабренә кадәр 18 сан чыгып кала. Газетаны чыгаручылар арасында Мәһруй Мозаффариядән кала, Мозаффар Мөштәриев, Солтан Гарифуллин, Исхак Казаков була. Исмәгыйль Рәмиев «Тәтеш оешмасы» турында: «милли-демократия гәзитләреннән берсе һәм сулрагы. Күләме бик кечкенә: 20х13, наборы 18х11 квадрат. Замандашлары арасында җиңел, простой тел белән язган гәзитәләрнең берсе. Техникасы матур, курчактай гәзит иде. Атнага бер тапкыр чыкты. Казанда «Мәгариф» типографиясендә басыла иде. Еллык бәясе 5 сум, берәмләп 6 тиен»[6], дип язган. Бу газета, беренче чиратта, укытучыларга таян-

[6] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905–1925): альбом. – Казан: Гәжур, 1926. – Б. 65.

ган, чөнки өязнең укымышлы катламы ярдәме белән бар халык мәгърифәтле итәргә тырышу омтылышы ясала. Газета битләрендә аларга мөрәҗәгать чыга: «Тәтеш өязендә укытучы мөгаллим вә мөгаллимәләргә үтенеч. Иптәшләр! Авылыгызда һәм тирә-якта булган хәбәрләрне, вакыйгаларны «Тәтеш оешмасы»на язып йибәрегез! Өязебезнең караңгы почмакларын үзегезнең тугры каләмегез берлән бергә яктыртып бирегез! «Тәтеш оешмасы» идарәсе сездән шуны үтенә». Заман таләп иткән сәяси хәбәрләр белән бергә «Тәтеш оешмасы»ның һәрбер санында да «Ил хәбәрләре», «Казан хәбәрләре», «Тәтеш хәбәрләре», «Авылдан тавышлар» исемле сәхифәләр чыгып килә. Барыннан да бигрәк, беренче урында, өяздәге мәгариф мәсьәләләре торган. Кыска гына вакыт аралыгында гына чыкса да, халык арасында популярлык казанып өлгергән басма була. Беренчедән, аны чыгаручылар профессиональ, халыкның хөрмәтен казанган шәхесләр була, алар җирле халыкның ихтыяҗын аңлап эш итә белгәннәр. Икенчедән, газетаның үзендә бирелеп барган үтемле реклама да роль уйнамый калмаган. Кайбер нөсхәләрдә: «Гәзитәне җыелып укыгыз – үзегез укыгач, башкаларга бирегез!», диелә[7].

1917 елда илдә барган үзгәрешләр чорында халыкка аңлату, алар белән аралашу бик мөһим гамәллärдән була. Газета аша гына түгел, ә халык янына чыгып эш итәргә кирәклеге аңлашыла. 1917 елның 7 мартында Мөселман комитеты тәкъдимен кабул итеп, Маһруй Мозаффария апрель ахырында якташларына заман шартларындагы хәлне, татар халкы алдында торган бурычларны билгеләүне аңлату максаты белән чыга. Маһруй абыстай хатын-кызларны укуга өндәп, үз ирекләре өчен көрәшү кирәклеген сөйләп, өязнең кырыктан артык авылында булып чыга. Тәтеш өязендә мөгаллимнәр әзерләү өчен ачылачак ике айлык курсларның җитәкчесе итеп билгеләнә. Аңа якын булган мәгариф, уку, белем бирүдә бар көчен биреп эшли. Үзенең 1914 елда ук күтәреп чыккан белем бирү проектының 1917 елда тормышка ашыруга ирешә дию дөрес булыр. Авыл җирлегендә мөгаллимлек итәрлек кызларны укытуга бар көчен бирә. Совет власте урнашкач, Маһруй абыстай Тәтеш һәм Зөя өязләре халык мәгарифе бүлекләрендә эшли, Казан шәһәренең 5 нче мәктәбендә белем бирә. Татарларның республикасы туып кына килгән вакытта, җәмәгать эшләрен башкарырлык актив хатын-кызларны барлый, аларны җитәкли. Маһруй абыстай җитәкләгән хатын-кызлар эшче хатын-кызларның эш шартларын да кайгырткан, аларның хокуклары үтәлүне дә контрольдә тоткан, гомумән, яңа шартларда татар хатын-кызына үз урынын табу, яраклашу, хокуклы булуда юнәлешләр биргән. Курслар оештырганнар, балаларга бакчалар, ятимнәргә тору урыннарын кайгырткannar, ачлык вакытта ярдәм кулы сузганнар[8]. Гомумиләштереп әйткәндә, хатын-кыз тормышында булган бар проблемаларга йөз белән борылып, аларга авырлыктан чыгарга мөмкин булган бар

---

[7] «Тәтеш оешмасы» газетасы // Безнең мирас. – 2020. – № 2. – Б. 25–29.

[8] Махмутова А. Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). – Казань: Татар. кн.изд-во, 2006. – С. 108.

нәрсәне эшләргә тырышканнар. Ятимлектә үскән, авыр тормыш юлы узган Маһруй абыстай татар хатын-кызларының тормышында авырлыклар мөмкин кадәр азрак булсын өчен, булганнарын җиңү өчен көрәшкән. Тәтеш төбәге өчен Маһруй Моззаффариянең биредә туып-үсеп татар дөньясының бөек хатын-кызы булып җитешүе горурлык өчен иң зур мисал.

Тәтеш төбәгендә Маһруй абыстай оештырган эшне башкаручы, төбәктә хатын-кызлар хәрәкәтен җитәкләүче, Тәтеш кантонында хатын-кызлар бүлегенең беренче чорында инструкторы, аннан җитәкчесе, җәмәгать эшләрендә башлап йөрүче, спектакль, концертлар оештыручы, шул ук вакытта мөгаллимлек итүче Җиһан Бадамшина була. Ул тумышы белән Кече Әтрәч авылыннан. 1898 елгы Җиһан Бадамшина журналист Исхак Казаков җитәкчелек иткән Тәтештәге рус-татар мәктәптәбендә белем ала. Бу кызның укуына да, тормышта үз юлын табуына да инде бу елларда революционер булып җитешкән Исхак Казаков һәм аның хатыны – мөгаллимә Нәфисә ханым зур йогынты ясыйлар. Җиһан Бадамшина 1918–1919 елларда Бәби, Барыш, Тенкәш (Тәтеш районы) авылларында мөгаллимлек итә. Мөгаллимлек белән бергә хатын-кызлар иңе күтәрер өчен авыр булган йөкләрне дә бик җиңеллек белән башкара: ачлык вакытында ачларга ярдәм оештыру, ач балаларны икмәк булган төбәкләргә озату эше, Кызыл Армия өчен ярдәм йөзеннән киемсалым җыю, ачларга ашханәләр оештыру булсынмы – барысы да хатын-кызлар оешмасы белән эшләгән эшләр. Оештыру таланты белән аерылып торган Җиһан Бадамшинаны 1922 елда Казанга Берләштерелгән Бистә (Объединенный городской) районына эшче хатын-кызлар бүлегенә эшкә чакыралар[9]. Халык өчен бар мөмкинлеген кулланып, бар энергиясен биреп эшләгән Җиһан Бадамшина һәм аның тормыш иптәше Кыям Алимбәк улының (1897–1938) язмышы 1937 елда кискен борылыш ала, Җиһан Бадамшина милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаепләнә, 5 елга хөкем ителгән булса да, хөкем срогы 9 елга сузыла.

Татар җәмгыятендә барган зур үзгәрешләр вакытында ир кешеләр белән бер үк дәрәҗәгә иңнәренә иҗтимагый йөк алып эш иткән хатын-кызлар бик күп. Югарыда сөйләнгән шәхесләр шуларның кайберләре генә, моннан кала, татар тарихында үз урынын алган башка күренекле хатын-кызлар да бар. Максат барысы хакында да сөйләү түгел, ә берничә хатын-кыз мисалында җәмгытьнең тормышында, аның үсеш-үзгәрешендә татар хатын-кызының халиткеч ролен күрсәтү. Тәтеш төбәгендә хатын-кыз куллары белән шундый зур эшләнгән икән, бу да Тәтеш төбәгенең әлеге чорда иҗтимагый үзәк булганлыкка дәлилләрнең берсе. Төбәк тарихын өйрәнү кысаларында татар тарихының бөек шәхесе Маһруй Мозаффариянең төгәл туу датасын ачыклау, әлегә кадәр фәнни әдәбиятта йөргән хатаны төзәтү дә мөһим бер нәтиҗә.

---

[9] Биктимерова Т. Безнең Җиһан апа (ТАССР наркомы, репрессия корбаны Кыям Абрамов хатынының ачы язмышы) // Мәдәни җомга. 2000. – 4 март.

# ЙОМГАК

Тәтеш өязе әлегә кадәр махсус тикшерү объекты булмау сәбәпле, шактый начар өйрәнелгән, аның үзенчәлекле яклары, ил тарихындагы роле күрсәтелмәгәнлеге ачыкланды.

Тәтеш – борынгы тарихы булган төбәк. Бу җирлекнең тарихи истәлекләре Тәтеш төбәге җирендә татарның дәүләт тарихы чагыла. Археологик, эпиграфик истәлекләр Идел буе Болгар дәүләте вакытында ук бу төбәк мөһим урын булуы хакында сөйлиләр. Тәтеш районы Әтрәч авыллары тирәсендә, шулай ук Апас җирлегендә табылган нумизматик материаллар нигезендә бу урыннарда дәүләтнең акча сугу үзәге булуы хакында фикерли алабыз. Бу төбәк тарихы Идел буе Болгар дәүләте, Җүчи Олысы тарихын өйрәнгәндә үзенең тиешле бәяләмәсен алырга хаклы. Шулай ук бу төбәк туристлар өчен оештырылачак экскурсияләр маршруты өчен дә кызыклы һәм мөһим бер юнәлеш булуына шик юк.

Тәтеш өязе, нигездә, авыл хуҗалыгы белән көн күрүче, җир эше белән бәйле халык гомер итә торган төбәк. Бу җирлек XVIII йөз ахыры – XX йөз башында аерым һөнәрчелек үсеш алу белән дә аерылып тормый, әмма шулай булса да, бу төбәк халкы шул чорга хас булган һөнәрчелек төрләре белән таныш булган. Һөнәрчелек товарлары, нигездә, көндәлек тормышта куллану өчен җитештерелгән, шул ук вакытта беркүпмеседер сатуга да чыгарылган. Тәтеш шәһәре Идел буенда урнашу сәбәпле, төбәкнең сәүдә үзәге дә булган, су юлы аша Россиянең башка төбәкләре белән товар алышу мөмкинлеге булдыра. Моннан кала, зур елганың якында булуы төрле кәсепләргә юл ача: балык тоту, бурлаклыкка яллану һ.б. Тәтеш халкының Әстерхан төбәгенә барып чыгуы да, бер яктан, су юлы белән бәйле, икенче яктан, бу төбәкләрдә генетик бәйләнеш тә күзәтелә. Казан ханлыгы чорында ук Әстерхан ханлыгы, Нугай урдасыннан килгән кайбер төркемнәр нәкъ менә Тау ягында төпләнгән. Әлеге хезмәттә төбәкләр арасындагы тарихи, генетик бәйләнешләргә аерым урын бирелде һәм алар метрика дәфтәрләрендәге язмалар һәм халыкта сакланып калган шәҗәрәләр белән дәлилләнде.

Тау ягы XVIII йөз ахыры – XX йөз башында татар мәгарифе үзәкләренең берсе була. Буа мәдрәсәсе традицион дини белем үзәге булган булса, Чуел өязендә Акъегет мәдрәсәсе ачылу белән, Тау ягында һәм шул исәптән, Тәтеш өязе авылларнында да, заманы өчен прогрессив җәдид уку йортлары барлыкка килә. Тәтеш шәһәрендә эшләгән рус-татар мәктәбе татар яшьләрен киң дөнья чынбарлыгына әзерләрлек мөмкинлекләре булдыра. Татар теле белән беррәттән рус телендә дә белем алалар. Г. Әхмәрев эшләгән дәвердә

Тәтеш шәһәренең рус-татар мәктәбе Парижда узган күргәзмәдә җиңүе шуның ачык мисалы.

Тумышлары белән Тәтеш төбәгеннән булган, яисә шул җирлектә хезмәт куйган атаклы дин эшлеклеләре, мөгаллимнәр хезмәте дә төбәкнең рухи тормыш югарылыгын күрсәтү билгесе. Бу якның китаплы як булуы, халкының белемле, бай рухи югарылыгы хакында әлеге җирлектә сакланып калган һәм табылган кулъязма китаплар да хәбәр итә. Дөрестән дә, археографик экспедицияләр бу якның бай мираслы булуын раслады. Хәтта төрки дөньяның ерак төбәкләрендә язылган китапларның да Тәтеш төбәгендә табылуы – бу төбәк халкының киң мәдәни бәйләнышларда яшәвенә бер дәлил.

Тау ягы XVIII йөз ахыры – XX йөз башында ил күләмендә барган иҗтимагый вакыйгаларда иң актив төбәкләрнең берсе булган. Бу төбәк ил күләмендә, аерым алганда, татар җәмгыятендәге хәрәкәтләрнең бер өлеше булса да, аның үз үзенчәлекләре, колачы бар. Тау ягында барган исламга кайту вакыйгалары бу сәяси хәлләрнең халык тормышына салган эзе, халык тарафыннан кабул ителү-ителмәве, протест хәрәкәтләренең көче татар дөньясындагы әлеге тарихи вакыйгаларны өйрәнгәндә «җанлы» тарихтан мисал була ала. Тарихи тикшеренүләрдә әлегә кадәр тиешле игътибар бирелмәгән тема яңа тарихи чыганаклар нигезендә яктыртылды, иман өчен көрәшүчеләрнең исемнәре ачыкланды. Шулай булса да, бу вакыйгаларны өйрәнү әле тарих фәне өчен ачык кала, чөнки ул катлаулы һәм бары әлеге хезмәттә өйрәнелгән төбәк белән генә чикләнми. Бу вакыйгалар аерым тарихи тикшерү объекты булырга тиешлеге ассызыклана.

Халык саны алу вакыйгалары, шул вакытта халык арасында туган протест хәрәкәте, бу хәрәкәтнең җитәкчеләре турында Казан арты буенча мәгълүматлар булса да, Тау ягындагы хәлләр читтәрәк кала килде, тикшерү нәтиҗәсе буларак, бу төбәк әлеге вакыгаларда протест үзәкләренең берсе булуы ачыклана, үз җитәкчеләре, халыкка мәгълүмат җиткерүчеләре булган.

Халык тормышында тирән эзен калдырган вакыйгаларның берсе – ул Беренче Бөтендөнья сугышы. Тау ягы халкы да аның бар трагик сәхифәләрен үтә, әлеге төбәктән сугышка чакырылып, аның башыннан ахырына кадәр үтеп чыккан кешеләр дә, әсирлек ачысын татыганнар да, гомерлеккә яу кырында калганнар да шактый – болар барысы да халыкның тормыш рәвешендә озак елларга кадәр чагылышын таба. Халыкның матди хәле белән беррәттән бу сугыш аның мораль халәтенә дә зур зыян сала. Батырлыклары өчен сугышны төрле дәрәҗәдәге медальләр белән тәмамлаган 91 кеше ачыкланды, алар арасында Тәтеш өязе җирлегеннән чакырылган төрле халык вәкилләре бар.

Тау ягы халкының Россиянең башка төбәкләре белән булган тарихи бәйләнешләрен өйрәнү бу төбәк тарихын яктыртуның, аның аралашу даирәсен күрсәтүнең отышлы бер алымы. Халык тарихы аерым территориаль кысаларда гына бармаганы, ә бу процессның катлаулы тарихи феномен булуы

дәлилләнә. Мондый алым кулланганда халыкның үзаңындагы, тарихи хәтерендәге вакыйгаларны, үзенчәлекләрне аңлау мөмкин. Тау ягы халкы Татарстанның хәзерге Әлмәт төбәге белән дә, Иделнең аръягы – Чистай, Спас яклары белән дә, хәтта Түбән Идел регионы – Әстерхан яклары белән дә генетик һәм тарихи бәйләнештә тора.

Тау ягы татар дөньясы өчен танылган нәселләр биргән төбәк. Кызганычка каршы, бер хезмәт кысаларында аларның барысын да карап бетерү мөмкинлеге юк, әмма китапта тәкъдим ителгән мисаллар җирләр биләү, икътисадый үсешне һәм рухи тормыш югарылыгын күрсәтә. Алиш бәк нәселе гасырлар үтеп, үз вәкилләре белән икътисадта да, мәдәнияттә дә, мәгариф тә дә лаеклы урын тоттылар, алар нәселе бу як тарихы белән генә чикләнеп калмыйча, эзләрен илнең һәр төбәк тарихында күрергә була.

Тау ягының, аерым алганда, Тәтеш төбәгенең халык гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәрендә һәм шулай ук халык тормышын чагылдырган аш-су традицияләрендә дә үзенчәлекләр күренә. Беренчедән, аларда татар халкы формалашудагы катлаулы процесс чагылса, ягъни татарның Урта Идел традициясе дә, күчмәлек чалымнары да күренсә; икенчедән, күрше халык – чуашларның, шул ук вакытта фин-угорларның, русларның мәдәни тәэсире билгеләре дә чагыла. Тау ягында, мисал өчен, Казан артында булмаган бәйрәмнәр булу да күренде – Майуна бары тик Тәтеш төбәге бер авылының үзенчәлекле бер бәйрәме. Хезмәттә бу вакыйгаларны яктырту да төбәк халкының катлаулы тарихи процесс үтүен, тарихи-мәдәни бәгланышларын күрсәтү өчен кирәкле бер алым.

Тәтеш төбәге татар тарихында борынгы тарихлы, халык тормышының мөһим бер үзәге. Идел буе халыкларының тарихын өйрәнгәндә бу төбәкнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышын күрсәтү тарихи белемне тулыландыра. Аерым төбәкнең тарихы, анда барган вакыйгаларны сурәтләү зур тарихны өйрәнүгә детальләр өсти. Хезмәт әлеге юнәлештә үз максатын тугъры үтәр дигән өмет баглыйбыз.

# ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

## АРХИВ ДОКУМЕНТЛАРЫ

***Татарстан республикасының Дәүләт архивы (ТР ДА)***
***Государственный архив Республики Татарстан (ГА РТ)***

Ф.1. Канцелярия казанского губернатора.
Ф. 2. Казанское губернское правление.
Ф. 3. Казанская губернская казенная палата.
Ф. 92. Попечитель Казанского учебного округа.
Ф. 97. Казанский губернский училищный совет, г. Казань.
Ф. 102. Переписные комиссии. Казанская городская.
Ф. 160. Директор народных училищ Казанского учебного округа по Казанской губернии.
Ф. 204. Коллекция метрических книг. Метрические книги мечетей.
Ф. 244. Тетюшская городская управа.
Ф. 324. Казанская губернская чертежная.
Ф. 359.Казанский губернский статистический комитет, г. Казань.
Ф. Р–1348. Отдел народного образования исполнительного комитета Тетюшских депутатов Казанской губернии.
Ф. Р–2780. Архивная коллекция «Метрические книги мечетей».

***Россиянең дәүләт тарих архивы (РДТА)***
***Российский государственный исторический архив (РГИА)***

Ф. 58. Геологический комитет при горном департаменте МТиП.
Ф. 733. Департамент народного просвещения.
Ф. 821. Департамент длуховных дел иностранных исповеданий МВД.

***Әстерхан өлкәсенең дәүләт архивы (ӘӨ ДА)***
***Государственный архив Астраханской области (ГА АО)***

Ф. 394. Астраханская губернская канцелярия г. Астрахани.

***Башкортостан республикасының Милли архивы (БР МА)***
***Национальный архив Республики Башкортостан (НА РБ)***

Ф. И–295. Оренбургское духовное собрание.

***КФУ китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (КФУ КСКБ)***
***Отдел рукописей и редких книг Казанского (Приволжского) федерального университета (ОРРК К(П)ФУ)***

2435 т. – Беренче бөтендөнья сугышы хатлары.

***Научный фонд музея археологии Республики Татарстан Института истории Академии наук Республики Татарстан (НФ МА РТ ИА АН РТ)***

Ф.5, оп.2, д.18. Фахрутдинов Р.Г. Отчеты о работе III, IV и VI разведочных отрядов Татарской археологической экспедиции 1961 г. – Казань, 1961. – 79 л.
Ф.5, оп.2, д.207. Косменко М.Г. Дневник археологических разведок по р. Свияге, Волге и Каме в 1966 г. 27 л.
Ф.5, оп.32, д.1. Калинин Н.Ф. Отчет об археологической экспедиции КФАН СССР по западным районам Татарской Республики в 1949 г. – Казань, 1949. – 72 л.
Ф.5, оп.33, д.1. Калинин Н.Ф. Отчет о работах археологической экспедиции Казанского филиала Академии наук СССР в 1950 г. по западным районам ТАССР. – Казань, 1950. – 61 л.
Ф.5, оп.40, д.1. Халиков А.Х., Генинг В.Ф. Отчет о полевых работах археологической экспедиции КФАН СССР в 1957 г. в юго-западных районах Тат. АССР. – Казань, 1957. – 180 л.
Ф.7, оп.1, д.9. Халикова Е.А. Материалы к отчету по Тетюшам: чертежи – 158, фото – 30, фотонегативы – 3. 1970.
Ф.11, оп.2, д.9. Габяшев Р.С. Археологические памятники города Тетюши – 5 л. Машинопись.

## БАСМА ЧЫГАНАКЛАР

### *Татар телендә*

1. Авылларга школа кирәкме? // Йолдыз. – 1912. – 15 январь.
2. Әхмәрев Г. Авыл җирендә мөселманнарның тереклеге // Казан мөхбире. – 1906. – 6 февраль.
3. Әхмәрев Г. Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. – 1906. – 12, 14 апр.
4. Әхмәрев Г. Иске зиратлар хакында // Азат. – 1906 – 30 март.
5. Әхмәрев Г. Иске зиратлар хакында // Азат. – 1906 – 30 март.
6. Әхмәрев Г. Мөселманнарның җир мәсьәләсе // Казан мөхбире. – 1906. – 6, 30 гыйнвар, 1 февраль.
7. «Бәгъре Янган». Өяздә укытуга сусау// Тәтеш оешмасы. – 1917. – 10 октябрь.
8. Бикмиев Әхмәдҗан. Авылда мәктәпләр // Казан мөхбире. – 1906. – 11 сентябрь.
9. [Буа ярминкәсе] // Йолдыз. – 1912. – 21 январь.
10. Идарәдән мәктүпләр // Йолдыз. – 1912. – 31 гыйнвар.
11. Мәрҗани Ш. Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 414 б.
12. Солтан Гарифуллин. Тәтеш өязе мөселман укытучыларының җыелышы // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 7 июль.
13. Сугыш һәм солдат бәетләре / Төз. Р. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2016. – 264 б.
14. [Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре] // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 26 сентябрь.
15. Тәтештә укытучылар җыены // Тәтеш оешмасы. – 1917. – 1 ноябрь.
16. Тәшәккер // Йолдыз. – 1912. – 17 гыйнвар.
17. Угырлау // Йолдыз. – 1912. – 19 январь.
18. Фәхреддин Р. Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – 359 б.

19. Фәхреддин Р. Асар. 2 том. – Казан: Рухият, 2009. – 303 б.

20. Фәхреддин Р. Асар. 3–4 томнар. – Казан: Рухият, 2010. – 648 б.

***Рус телендә***

1. Ахмаров Г. Отчет о поездке с археологической целью летом 1909 года в Свияжский и Тетюшский уезды Казанской губернии // ИОАИЭ при Императорском университете. Т. XXVI. Вып.4. – Казань: Типография Императорского университета, 1910 – С. 398–408.

2. Зайцев И. Городище в даче села Б. Таяба // ИОАИЭ при Императорском университете. Том X. Вып. 1. – Казань: Типография Императорского университета, 1892. – С. 112–113.

3. Заметки о городищах, курганах и древних земляных насыпях в Казанской губернии. – Казань: в губернской типографии, 1874. – 33 с.

